Безнең МИРАС

05

май 2015

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ТАРИХИ, МӘДӘНИ, ПЕДАГОГИК, ДИНИ МИРАС, ТӨПЛЕ ФАРАЗ, ӘДӘБИЯТ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

Башкалабыз Казанда «Без булдыра-быз! Без бергә!» дип аталган форум булып узды. Әлеге форумда, яшьләр белән эшләүче оешмалар тәкъдиме буенча, «Президент белән бергә» дип аталган республикакүләм иҗтимагый инициативалар үзәге барлыкка килде.

Без — бергә!

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар — гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнен МИРАС 12 +
05(40)
май 2015

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ
тарафыннан гамәлгә куелды.
2012 елның май аеннан чыга.

4

ЭЧТӘЛЕК

2015 ЕЛ — РОССИЯДӘ ӘДӘБИЯТ ЕЛЫ

3 **«Соңгы тапкыр карыйм Иделгә...»** *Фатих Кәрим*

ГАМЬЛЕ ӘҢГӘМӘ

4 **«Татар әдәбияты музее булырга тиеш!»** *Гөлчәчәк Нәҗипова белән Ленар Гобәйдуллин әңгәмәсе*

ТАРИХИ МИРАС

12 **Кемнәр соң без — татарлар?** *Рабит Батулла*
20 **Нәсел шәҗәрәләре.** *Бакый Зыятдинов*
24 **Йосыф туган көн.** *Наил Таиров, Илһам Таиров*
26 **Чыңгыз Айтматовны биргән Мәчкәрә.** *Фәүзия Бәйрәмова*
34 **Милли дәүләтчелек туганда...** *Рәмзи Вәлиев*
38 **Болгарда — Ак кунакханә**

ТӨРКИ ДӨНЬЯ

40 **Төрки дөнья һәм дөньяга караш.** *Рафаэль Мөхәмәтдинов*
44 **Куңелгә якын Төркия...** *Сөмбел Таишева*
51 **Эшлекле сәфәр**

ҖИҢҮ — 70!

52 **«Тәвәккәллләп бер хат языйм...»** *Нәзирә Фәттахова, Ләйсән Харрасова*
55 **Муса Җәлил хатлары**
59 **Югалмасын җирдә эзләре...** *Әрибә Айтуганова*
64 **Әмирханнар нәселеннән.** *Зөлфәт Хәйруллин*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

66 **Сүз һәм сурәт.** *Рафаэль Ильясов*

ӘДӘБИ МИРАС

68 **Кутадгу билик (Котайткыч белем).** *Йосыф Баласагуни*
73 **«Киңәшсез сүз башлама...»** *Марсель Әхмәтҗанов*
78 **Тукай турында истәлекләр.** *Вафа Бәхтияров*
85 **Тукай энциклопедиясе.** *Зөфәр Рәмиев*

26 ЧЫҢГЫЗ АЙТМАТОВНЫ БИРГӘН МӘЧКӘРӘ. *Фәүзия Бәйрәмова*

78 ТУКАЙ ТУРЫНДА ИСТӘЛЕКЛӘР. *Вафа Бәхтияров*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб ЛЕРОН)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары-
җаваплы сәркатип
Марат Закиров
(Марат Закир)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр Комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары – ТР фән һәм мәгариф министры)
Фәрит Шаһиәхмәтов
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Данил Ибраһимов
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов

Бүлек мөхәррирләре
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
Рүзәл Мөхәммәтшин
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Гомуми мәсьәләләр буенча мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы,
2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

БЕР БӘЙЛӘМ БЕРКЕТМӘ

86 **Каләмдәшләр игътибарын тоеп...** *Ләбиб Лерон*

СӘНГАТИ МИРАС

92 **Фуат ага ядкяре.** *Наилә Гәрәева*
98 **Сәйдәшнең беренче мәхәббәте.** *Рүзәл Мөхәммәтша*
104 **«Сөйлә, Гөлгенәм...» Фатыймаи-Зөһрә истәлеге**

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

112 **Миллият сүзлеге.** *Адлер Тимергалин*

100 ЕЛ ЭЛЕК...

114 **«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1915 елның май ае.** *Ленар Гобәйдуллин*

ХӘТЕР САГЫНДА

116 **Алъяпкыч.** *Руфия Мөхетдинова*

117 **Мирасворд**

ШАЯН МИРАС

118 **Хәйрулла паёгы.** *Нәби Дәүли*

120 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Май*

Заказ №О-1308. Тираж – 1675 данә. Формат 70 X 108 1/16
Басарга кул куелды: 06.05.2015
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Бу хакта техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Ленар Гобәйдуллин төшергән, Абдулла Дубин, авторларның һәм Татарстан Милли музее архивларыннан фоторәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Тышлыкның 1 нче битендә – «Җиңү яулап кайтыгыз!» 1995 ел.
Киндер, майлы буяу. *Ш.Нигъмәтуллин рәсеме*

Фатих Кәрим
(1909-1945)

***

Соңгы тапкыр карыйм Иделгә,
Соңгы кабат күрим акканын,
Бәлки, бик тиз бире кайтмамын,
Сакланыр ул бары күңелдә.

Сакланыр ул соңгы хат кебек,
Искә алсам йөрәк сулкылдар;
Күз алдыма килер дулкыннар,
Дулкыннарда кайнар ак күбек.

Син борчылма, күңел, яз килсен,
Кыр казлары кайтыр күлләргә,
Без кайтырбыз туган илләргә,
Башлар гына исән-сау булсын.

Безне котлап, җылы яңгырлар
Шатлык сибәр Идел буенда,
Безне котлап, иркен болында
Назлы аккош моңы яңгырар.

1942

«ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ МУЗЕЕ БУЛЫРГА ТИЕШ!»

ТР Милли музееның генераль директоры, тарих фәннәре докторы, «Безнең мирас» журналының редколлегия әгъзасы **Гөлчәчәк Рәхимҗан кызы НӘҖИПОВА** белән **Ленар ГОБӘЙДУЛЛИН** әңгәмәсе.

– Татарстан Республикасы музейларга иң бай төбәкләрнең берсе. Апрель аенда шушы музейларның иң олысына – ТР Милли музее оешуга 120 ел тулды. Музейда татар халкының милли-мәдәни, археологик, этнографик, эпиграфик мирасы белән кызыксыну кайчаннан башланган?

– Әлбәттә, 1895 нче елда музей оешкан көннәрдән алып, биредә татарларны өйрәнү иң төп максат булып торган. Музейның нигезе булган А.Ф.Лихачёв коллекциясенең күп өлешен Болгар һәм Биләрдән табылган болгар чоры материаллары тәшкил итә. Музейны оештыручылар арасында Н.П.Загоскин, А.А.Штукенберг, Н.Ф.Высоцкий, Н.Ф.Катанов кебек Казан университеты профессорлары булган.

Галимнәр университет барлыкка килгән елдан ук татарны өйрәнгән, аларны төбәктә яшәүче татарларны фәнни өйрәнүгә нигез дә салган, дип әйтергә мөмкин. Университет галимнәренеке белән бергә В.И.Заусайлов, И.А.Износков, Л.О.Сиклер кебек шәхесләрнең коллекцияләре дә музейга алына. Алар тапшырган экспонатларның шактый өлеше татарларга нисбәтле. Бу коллекционерлар татарның рухи һәм матди дөньясы белән кызыксынган һәм үзләренең өйләрендә дә шушы бай мәдәниятккә караган төрле-төрле әйберләрне җыйган. Ә революциядән соң музейда татар халкы мирасын туплау эше белән Б.Ф.Адлер, Н.И.Воробьёв, М.Г.Худяков, П.М.Дульский, М.Е.Евсевьев кебек югары квалификацияле этнографлар шөгыльләнә. 1930-2000 елларда төрле фәнни оешмалар, аеруча СССР ФАнең Казан филиалы оештырган этнографик, археологик, СССР ФА Археология институтының Куйбышев археологик экспедицияләре туплаган искиткеч бай мирасның бер өлеше музейда саклана.

– Биредә татар халкы язма мирасының иң борынгы нинди ядкярләре саклана?

– Теге яки бу предметка уеп яки күпертеп язылган язмалар балдакларда, төрле бизәнү әйберләрендә бар. Идел буе Болгар дәүләтендә бронзадан коелган йозакка уелган язма бик кызыклы. Лихачёв коллекциясеннән безгә килеп ирешкән бу ядкяр 1146-1147 елларга карый. Әхмәд углы Әбүбәкер оста үзе ясаган йозакка: «Һәрвакыт дан һәм тыныч уңыш, һәм һәрьяклы бәхет, һәм дан, һәм муллык (булсын) бу йозакның хуҗасына», – дип язган.

Ташъязма мирас – халкыбызның урта гасырлар чорыннан калган иң сирәк ядкярләрнең берсе. Безнең бинабыз – элеккеге Кунак сарае (Гостиный двор) – борынгы зират урынында урнашкан. Биредә төзелеш эшләре башкарганда кабер ташлары килеп чыккан, аларны безгә китергәннәр һәм бу музей документларында да теркәлеп калган. Шулай ук Татар бистәләре биләмәсендә генә түгел, ә Казанда булган башка борынгы, хәзер юкка

Әхмәд углы Әбүбәкер оста ясаган йозак. 1147 ел

чыккан зиратларның да кабер ташлары биредә. Заманында Кремльдә табылган татар кабер ташлары да бездә саклана. Бу ташларның барысы да фондта җыйналган, әмма аларны тиешле фәнни югарылыкта өйрәнелгән, дип әйтеп булмый, бәлки киләчәктә каталогын да чыгарырбыз. Эпиграфик һәйкәлләрнең бер өлеше авыллардан җыйналган, әмма андыйлар бик сирәк.

Ә татар кульъязма китабы мирасына килгәндә, аларның музейда сакланган иң әүвәлгесе — Мөхәммәд бине Барзәнҗезадә тарафыннан 1507 елда күчерелгән Коръән тәфсире. Сәләхетдиннең 1509 елда күчерелгән «Мәлхәмә»се (дөньяның кояштан яратылышы турында китап), Сәгъди Ширазиның 1554 елгы «Гөлстан» әсәре дә кульъязма мирасның иң борынгыларыннан. Барыгызга да мәгълүм, 1523 елда язылган Сәхибгәрәй хан ярлыгы да безнең музейда саклануча кыйммәтле ядкярләрдән.

— 2015 ел — Россиядә әдәбият елы. Сезнең музейда татар әдипләренең бай мирасы сакланганын беләбез. Кайсы әдипләрнең фонды аеруча бай?

— Татар әдипләре фондының оешуы сугыштан соңгы еллар белән бәйле. Нәкъ менә 1940 еллар ахырында Бөек Ватан сугышында һәлак булган язучылар Ф.Кәрим, Г.Кутуй һәм башкаларның гаилә әгъзалары музейга беренче экспонатларны китерә. Муса Җәлил фонды аеруча бай, чөнки аның кызы Чулпан һәм хатыны Әминә ханым заманында герой шагыйрь мирасының күп өлешен безнең музейга тапшырган. Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Р.Фәхреддин, Г.Тукай, Дәрдемәнд, Ә.Хәсәни, С.Сүнчәләй, К.Тинчурин, Ш.Усманов, Һ.Такташ, К.Нәҗми, Т.Гыйззәт, Ф.Ильская, С.Хәким һәм башка күренекле шәхесләребезнең исән калган архивлары, мемориаль әйберләр комплексы, аерым предметлары бездә саклана.

Теге яки бу әдипнең мирасын туплау аерым мемориаль музейлар оешу белән бәйле. Милли музей, Татарстан Республикасының иң зур музее буларак, Казан шәһәрендә, район үзәкләрендә,



Мөхәммәд бине Барзәнҗезадә күчергән Коръән тәфсире. 1507 ел

авылларда шактый күп музейлар ачуда катнашты. Әлбәттә, район җитәкчеләре безгә музей оештыру турында мөрәҗәгать иткәч, без күп чыганакларны яңа оешкан музейга тапшырдык, аларның экспозицияләренә урнаштырдык, ә бер өлеше үзебезнең фондларда саклауга калды. Дөрес, бүгенге көндә ул музейлар төрлечә эшли, әмма барлык экспонатлары да саклана.

— *Вафат булган каләм әһеленең туган-тумачалары әдипнең язма мирасын, документларын сезнең фондларга тапшыра аламы?*

— Без хәзер документларны музейга алмаска тырышабыз, ТР Милли архивына тапшырсыннар. Чөнки анда кәгазь документлар дөрес саклана, аларның бу юнәлештә мөмкинлекләре зуррак. Кызганыч, бүген документларны, кулъязмаларны җыйнау, аны му-

«Мәлхәмә» китабы. 1509 ел

Сәхибгәрәй хан ярлыгы. 1523 ел



Сәгъди Ширази. Гөлстан. 1554 ел

зей фондларында саклау урыныбыз чикле. Дөрес, тарихи шәхесләребезнең аерым кулъязма мирасын, архивын без җыйныйбыз, бу эшне күпмедер дәрәҗәдә дәвам да итәрбез. Күптән түгел генә Г.Исхакыйның мөһаҗирлектәге мирасын үзебезнең фондка алдык. Әмма соңгы буын әдипләренең язма мирасы, архивлары ТР Милли архивына тапшырылса хәерлерәк.

Ә без исә язучыларның шәхси әйберләрен җыябыз, алар безнең өчен күпкә кызыклы. Бу әйберләрне экспозициядә күрсәтергә була. Әдип яки шагыйрьнең иҗат лабораториясен, аның көнкүрешен, заманын, яшәү шартларын халыкка күрсәтү өчен безгә шәхси әйберләр кирәк. Әдипнең киемнәре, каләмнәре, өстәл-урындыклары, шәхси шкафлары, укыган, басылып чыккан китаплары — боларны, әлбәттә, туплыйбыз. Без — музей, шулай булгач, без әдип тормышын визуализация аша күрсәтергә тиеш.

— Инде менә дистә еллар дәвамында татар җәмәгатьчелеге, зыялылар татар әдәбияты музее ачарга хыяллана. Республикабызның төп музей белгече буларак әйтегез әле, зыялыларның әлеге хыялы кайчан да булса чынга ашармы икән? Бу музейны ничек күзаллыйсыз?

— Әлбәттә, бу хыял безнең үзебездә дә бар. 1944 елда ук күренекле татар язучысы Гадел Кутуй ТАССР Югары Советының 21 июнь сессиясендә ачынып: «Мин Пушкинның каурый каләмен, аның кулъязмаларын күрдем. Аларга инде 100 елдан артык. Алар зур саклык белән музейда сакланалар. Тукай 30 ел элек үлде. Аның каләмен, кулъязмаларын кайда күрергә була? Шуны ук Мәҗит Гафури һәм Һади Такташ турында да әйтә алам. Безгә әдәби музей кирәк», — ди.

Шәриф Камал музееның безгә беркетелгән бинасы бар. Әмма анда һаман да чын мәгънәсендә музей төзи алмыйбыз, мөмкинлегебез юк, чөнки бина бик мөшкел хәлдә. Галимнәрне, әдәбият белгечләрен, язучыларны, Разил Вәлиев, Ренат Харисларны җыеп киңәшкәннән соң, шушы бәләкәй бинага, мең елдан артык мирасы булган татар әдәбияты тарихын кертә алмыйбыз, ул бинада яңадан Шәриф Камал музее булырга тиеш, дигән карарга килдек. Ә татар әдәбияты музее турында әйтсәк, бай экспонатлар, фондлар бар, әмма бина юк.

Бу музейның концепциясе дә төзелгән, ул искиткеч матур, хәтта берничә вариантта эшләнгән. Концепция буенча әлеге музей татар әдәбиятын иң борынгы чордан ук чагылдыра. Дөрес, сакланып калган борынгы, урта гасырларга нисбәтле әйберләр аз, әмма шулай да, әдәбият музее шулардан башланырга тиеш. Музейда зур урын XX гасыр татар әдәбиятына, әдипләренә биреләчәк. Вафат булган әдипләрнең туган-тумачалары, хәзер исән-сау булган каләм әһелләре белән дә тыгыз хезмәттәшлек итәргә ниятлибез.

Безгә төрле биналар тәкъдим итеп карадылар, әмма әлегә кадәр берсен дә бирмиләр. Разил Исмәгыйль улы фикеренчә, мин дә моның белән килешәм, Милли китапханә өчен зур, заманча бина төзесәләр, әлеге музей шушы бина эчендә дә булырга мөмкин. Бу бик тә яхшы идея, чөнки әдипләрнең иҗаты, тормышы, әлбәттә, китап белән тыгыз бәйләнештә. Ренат Харис исә элекке Матбугат йорты бинасы булмасмы, дип җитәкчеләргә мөрәҗәгать итте. Бу бина булса да яхшы булыр иде, чөнки биредә узган гасырның 30 елларыннан алып 2000 нче елларга кадәр татар әдипләре килеп, эшләп, иҗат итеп йөргәннәр.

Кызганыч, һаман да әдәбият музеен оештыру мәсьәләсен хәл итә алганыбыз юк. Көчебез җитмиме, әллә моның өчен хөкүмәтнең акчасы юкмы? Шунысы бәхәссез, Казан каласында татар әдәбияты музее һичшиксез булырга тиеш!

— Милли музей фондларындагы, экспозицияләрендәге тарихи ядкярләрне саклау шартлары XXI гасыр таләпләренә җавап бирәме?

— Әлбәттә, юк.

— *Казанда кыйммәтле музей экспонатларының «гомерен озынайту», реставрацияләү, консервацияләү эшләре башкарыламы?*

— Башкарылмый. Дөрес, без кулдан килгәнне эшлибез. Күпмедер дәрәҗәдә консервация, мониторинг эшләрен алып барабыз. Әмма фонд бинасын төзү мәсьәләсе дә актуаль булып кала. Консервация, реставрация эшләрен алып барыр өчен аерым, кыйммәтле җиһазлар, белгечләр кирәк. Дөрес, җиһазлары булса, белгечләр мәсьәләсен хәл итеп булыр да кебек. Аларны укытырга, музейда эшләүче кадрларны бу хезмәткә әзерләргә мөмкин. Әмма бина, остаханәләр, җиһазлар булдыру искиткеч зур мәсьәлә булып кала.

— *Димәк, саклау тиешле шартларда булмагач, борынгы экспонатларның 100, 200 елдан соңгы буыннарга барып җитмәве, киләчәк өчен сакланмавы мөмкин?*

— Без бер гасырдан артык сакладык бит, җиһазлар булмаса да. Әлбәттә, без үзебезнең кулдан килгән кадәр шартларны тудырабыз, мирасыбызны киләчәк буынга тапшырырбыз. Әмма, һичшиксез, хөкүмәт тарихи-мәдәни мирасны саклау турында уйларга тиеш. Разил Исмәгыйль улы да үзенең комитетына безне бу мәсьәлә буенча берничә мәртәбә җыйды. Ул, аеруча, гарәби язулы чыганакларны реставрацияләү, цифрлы форматка күчерү белән кызыксына. Аларны бит әле сакларга гына түгел, ә өйрәнергә, бастырып чыгарырга да кирәк. Хәтта дөньякүләмендә танылган галим Ш.Мәрҗанинең дә кулъязмалары тулаем басылмаган, хәзерге укучы ул хезмәтләрне белергә тиеш.

— *XX гасыр башында татар зыялылары Мәрҗанинең «Вафият әләсляф» исемле VI томлы биобиблиографик китабын бастырып чыгарырга карар кыла. Әмма олуг галим вафатына гасырдан артык вакыт үтсә дә, әлеге гыйльми хезмәтнең басылып чыкканы юк. Заманында Галимҗан Баруди да: «Шул китапны бастыру өчен җитәрлек батырлык һәм тырышлык һаман да Казан тирәсендә булмады. Моннан соң ни булыр?» — дип яза.*

— Әйе, аларны татар теленә тәрҗемә итеп халкыбызга җиткерү, рус һәм инглиз телләренә тәрҗемә итеп дөнья халыкларына таныту да актуаль мәсьәлә булып кала бирә. Без музейга килгән кешеләргә Мәрҗани, Курсавилар турында сөйлибез, алар белән горурланабыз. Ә аларның хәзерге буын укучысына тәкъдим итәрлек китаплары кайда? Аларны хәзерге дөньяда белмиләр, чөнки без үзебез тәрҗемә итмибез. Дөрес, хәзерге заман әдипләренең әсәрләрен рус, инглиз, төрек телләренә тәрҗемә итү мәсьәләсе берникадәр хәл ителә кебек. Ә борынгыларының биниһая күп өлеше басылып та чыкмаган, кулъязма хәлендә саклана. Аларны ничек тә булса тәрҗемә итеп дөнья халыкларына җиткерәсе иде!

Казакълар бөтендөнья буенча үзләренең кулъязмаларын, мәшһүр шәхесләренең мирасын эзли. Аларның бу юнәлештә махсус дәүләт программасы бар һәм моның өчен шактый акча тоталар. Бу максат белән, әлбәттә, безгә дә берничә мәртәбә килделәр. Ике ай чамасы Казанда яшәп, казакълар турында нинди мәгълүмат бар, аеруча кулъязмаларны ксерокстан чыгартып, цифрлы форматларга күчертеп алып киттеләр. Мондый эшне без дә башкарырга тиеш. Чөнки татар дөньяның кайсы гына почмагында яшәмәсен, аның шунда сакланып калган язма мирасы бар. Татарстандагысын гына түгел, ә бөтен илләрдә саклана торган кулъязма мирасын бер урында, электрон нөсхәдә булса да туплау — безнең изге эшебез.

— *Музей борынгылыкны сакласа да, ул заманча технологияләр белән бергә, янәшә атларга тиеш кебек, информацион дөньяга яраклашу — хәзерге заман таләбе.*

— «Бөек Ватан сугышының виртуаль музее» (www.tatfronty.ru) про-

екты турында аерым әйтеп үтәсе килә. Ул үзенә 43 район музеен берләштерә. Виртуаль музейда ТР китапханәләрендә, архивларында, музей фондларында, экспозицияләрендә саклана торган Бөек Ватан сугышына нисбәтле предметлар электрон нөсхәдә халыкка күрсәтелә. Ул сайтта фронтовик-әдипләрнең дә документлары, шәхси әйберләре бар. Шулай ук Бөек Җиңүнең 70 еллыгы уңаеннан кайда, нинди вакыйга бара, болар да әлеге сайтта яктыртыла. Кайбер районнарда шушы максатны активрак башкарыр өчен корпунктлар да ачылды.

— Җиңүнең 70 еллыгы узганнан соң, бу уңайдан оештырыла торган чаралар кимеп, әлеге сайтка игътибар кимемәсме?

— Һич кенә дә кимемәс. 70 еллыктан соң да чаралар бетәргә тиеш түгел, әле Җиңүнең 71 еллыгы, 75, 80 еллыклары буласы бар... Гомумән, авылларда, районнарда, шәһәрләрдә Бөек Ватан сугышына, ветераннарга нисбәтле кайчан, нинди вакыйга була, алар сайтта яктыртылсын иде. Ә музейлар бу эшне башкаруда төп үзәк булып торырга тиеш. Максатыбыз — бөтен мәгълүматны бер урында җыйнау.

— Бу мәгълүматны җыйнап бетерү мөмкин эшме икән?

— Юк, аны җыйнап бетерү мөмкин түгел. Хәбәрсез югалган, һәлак булган солдатларның исемнәре, яңа әйберләр елдан-ел табылып тора. Казан шәһәрендәге, Спас, Чирмешән, Апас, Арча, Чаллы, Буа районнарындагы эзтабарлар аеруча актив, даими һәм нәтиҗәле эшли. Шунысы куанычлы, тарих белән кызыксынучыларның, аеруча яшьләрнең саны көннән-көн күбәя. Хәзерге вакытта «Хәтер» китабы редакциясе хезмәт геройларына багышланган китапка мәкаләләр туплау белән шөгыльләнә. Бу хезмәт тә әлеге сайтта яктыртылыр, дип өметләнәбез.

Быел, аеруча Җиңүнең 70 еллыгы уңаеннан, кешеләр музейга өйләрендә сакланган фронт хатларын, фоторәсемнәр, документлар алып килә. Әлбәттә, болар безнең өчен бик кадерле. Бөек Ватан сугышы музееның экспозициясен яңартсак, алар анда кирәк булачак. Ә экспозициягә кертелмәгән өлеше виртуаль музейга куелачак.

— Журнал — укучысыз, театр тамашачысыз яши алмаган кебек, музейлар да аңа килүче кунаклардан, туристлардан башка яши алмый. Милли музейда халкыбызның бай мирасы саклана, дидек. Шулай да, чит ил туристлары биредә аеруча нәрсә белән кызыксына?

— Милләтебез, республикабыз тарихы, иң борынгы экспонатлар — менә алар белергә теләгән нәрсәләр. Безнең экспозициябез дә шушы ихтыяҗны канәгатьләндерүгә йөз тотарга тиеш иде. Әмма әлегә кадәр өч бүлектән торган («Татарстан тарихы борынгы чорлардан безнең көннәргә кадәр», «Кеше һәм табигать», «Мәдәният: Татарстан халыкларының мәдәни бәйләнешләре») даими экспозиция төзелмәгән. Кызганыч, музейда татар халкы тарихының аерым-аерым бүлекләре, чорлары белән генә танышырга мөмкин. Музейның хәзерге экспозицияләрендә борынгы чордан алып бүгенге көнгә кадәрге тарихыбыз хронологик эзлеклелектә яктыртыла, дип әйтеп булмый. Бинага реконструкция булмый торып, бу эшне башкарып чыгу мөмкин түгел.

— Гадәттә музейга бер килгән кеше минем анда бер булганым бар, хәзер анда кереп ни эшлим, дип әйтә. Музейга бер кешене кабат-кабат кертер өчен нәрсә эшләргә кирәк, дип саныйсыз? Аеруча район, авыл музейларына.

— Чит ил туристларыннан аермалы буларак, казанлылар безнең музеебызга даими килә. Алар күпмедер дәрәҗәдә безнең экспонатларны, фондларны белә, нигә тегене, нигә моны күрсәтмисез, диләр. Еш кына күргәзмәләргә дә киләләр. Музейларда ел дәвамында махсус календарь-план нигезендә мәдәни чаралар үтә. Районнарда да актив эшли торган музейларга халык күп йөри. Лаеш, Апас, Арча,

Чаллы, Норлат, Әлмәт музейлары бик көчле, шул сәбәпле, аларга килүче кешеләрнең дә саны күп. Әлбәттә, искиткеч дәрәҗәдә начар, пассив эшләүче музейлар да юк түгел. Шуның өчен аларның музейларына кеше дә килми, хәтта районда яшәүчеләр дә әлеге музей турында берни белми, ә инде туристлар турында әйткән дә юк. Музей җитәкчеләре, хезмәткәрләре үзләре актив эшлиләр икән, анда, әлбәттә, кеше килә.

— Якын һәм ерак киләчәктә музей кунакларны нинди проектлар белән шатландыра алачак?

— Музей бинасында реконструкция эшләре башкарылса, әлбәттә, без Казанда зур музей үзәген булдыра алачакбыз. Анда зур фондсаклагыч төзергә уйлыйбыз һәм ул ачык булыр, дип өметләнәбез. Безнең фондларда миллионга җитеп килүче экспонат шунда сакланырга тиеш, һәм аны бар кеше дә күрә алачак. Шунда ук реставрация эшләрен алып бара торган лаборатория дә булыр, дип уйлыйбыз. Менә шундый максат һәм хыяллар белән яшибез. Әлеге хыяллар гамәлгә ашса, музеебызны, димәк татар халкын, бергә яшәүче башка милләтләр тарихын дөнья күләмендә танытыр өчен зур мөмкинлек туачак.

— Сезне редакция исеменнән ТР Музее оешуның 120 еллыгы һәм Халыкара музейлар көне белән ихлас күңелдән котлыйм. Милли мирасыбызны халкыбызга җиткерүдә алга таба да бергә максатчан эшләсәк иде, дигән теләктә калам. ■

КЕМНӘР СОҢ БЕЗ – ТАТАРЛАР?

Рабит Батулла

ҮЗГӘ КАРАШ

Абруйлы галимебез Мәсгуд Гайнетдин чыгарган «Мәңге тоныкланмас көзгебез» атамалы китапта (ТКН, 2006) борынгы тарихка кагылышлы «Көнчыгыштан тәре яулары» дигән күләмле фәнни хезмәт урын алган. (Автор «хач» урынына күнегелгән «тәре» сүзен кулланган. Гәрчә «крестовые походы» гыйбарәсе «хач яулары» дип аталырга тиеш иде. Бездә «икона» — «тәре» белән «крест» — «хач» мәгънәләрен бутау канунлашкан шул инде, кызганыч.) Аурупа илләре йөзәр ел буе нәсара булмаган илләргә әледән-әле һөҗүм ясап, аларны талап көн күргән, мөселман халыкларын юк итәргә теләгән. Бусы мәгълүм. Ләкин Көнчыгыштан — будда, тәңре, ислам, шаман динле халыклар тарафыннан Аурупага хач яулары ябырылганы турында белүчеләр бик сирәктер.

Мәсгуд Гайнетдиннең бу китабы — татар мохите өчен генә түгел, бөтен Русия, бөтен Аурупа, бөтен дөнья өчен гаять әһәмиятле хезмәт. Укып чыкканнан соң аңларсыз: бөек Чыңгыз һәм Бату ханнарның яулары — Көнчыгыштан килгән хач сәфәрләре икән! Юкса, алар һич кенә дә кычкырып торган христианнарга охшамаган. Шул ук вакытта, аларның несториан юнәлешендәге (митраизм) нәсаралар икәнен дә тарихта дәлилләр юк түгел. Әлбәттә, галим Мәсгуд әфәнде бу материалларны фараз, гөман шәкелендә китерә, ләкин аның тикшеренүләрендә мантыйк аксамый. *«Гомумән алганда, Үзәк Азия күчмәләре арасында христианлык IV-V гасырларда тарала башлый»*, — дип яза ул («Көнчыгыштан тәре яулары», 8 нче бит). Элгәрерәк Л.Н. Гумилёв та шул турыдарак искәрткән: *«Бу төбәкләрдә VIII гасыр урталарына җиде епископлыкны берләштергән православ Хәзәр-Хәрәзм митрополитлыгы оетырыла»* («Древняя Русь и Великая степь», 163 бит).

Иерусәлимгә хач яулары башланган чорда Урта һәм Үзәк Азия халыклары арасында (XII-XIII йөзләрдә) нәсаралыкның киң таралганлыгы турында мәгълүмат күп.

Аурупаның берләшкән хәрби куәтләре Иерусәлимдә аерым христиан католик дәүләте коруга ирешә. Ләкин мөселманнар тарафыннан каршылык та көчле була. Идел буенда туып үскән мәмлүк баһадиры (бүгенге татар-

*Ахыры. Башы 2-4 нче саннарда.

нугайларның борынгы бабасы) Бәйбарс хач яуларына каршы аяусыз каты көрәш башлый. Күп уңышларга ирешә. Иерусәлимдәге христиан дәүләтен саклап калырга егәрләре калмаган яугирләр көнчыгыш диндәшләренә өмет баглый…

Алга таба автор Чыңгыз ханның христиан анадан тууы, шуның аркасында гаиләдән куылулары, Ясүгәй баһадурның татарлар тарафыннан түгел, үз туганнары кулыннан агулап үтерелүе, Тимучинның Чыңгызга әверелүе өчен христиан кәраитларның үҗәт рәвештә тырышканлыгы турында да ышандырырлык дәлилләр китереп яза. *«Татар-монгол яуларының Көнбатыш христиан (католик) дөньясы белән бәйләнеше Батый дәверендә тагын да калкурак чагыла. Хәтта аның маршруты да инде Рим папалары һәм герман императорлары арасындагы мөнәсәбәтләр белән турыдан-туры бәйләнгән. Мәгълүм булганча, X гасырлардан (Оттон Беренче вакытыннан) бирле, герман императорлары белән Рим папалары арасында Аурупа илләрен кул астына алу өчен каты ызгыш барган… 1230 елда Папа гаскәрләре тар-мар ителә. Ләкин моны Папаның капитуляциясе дип уйларга һич ярамый. Бу чорда Рим папалыгындагы корольләр императорларны тезләндерерлек көч-кодрәткә ия була. Икеләнерлек урын юк. Григорий IX да үзен җиңелгәнгә саный алмый, баш бирмәгән императорны ул тәре яуларының «икенче фронты» — дәһшәтле монгол яулары тоягы астында юк итәргә карар кыла. Бу яңа монгол явының оештыру «штабы» да, Чыңгыз ханныкы кебек үк, Үзәк Азия була. Анда 1235 елда гомум монгол корылтае үткәрелә, яу башлыгы итеп Җучиның олы улы Урда Ичен билгеләнә, тик бу дәрәҗәне ул энесе Батыйга тапшыра»,* — дип ташка баса Мәсгут әфәнде («Көнчыгыштан тәре яулары», 25 бит).

Шулай итеп, Чыңгыз һәм Бату яуларының Рим папасын герман императорлары дәһшәтеннән коткарырга оештырылган кампания икәненә ышана башлыйбыз. Нәтиҗәдә, Чыңгызның мөселманнарга карата кайнаган нәфрәте дә, Батуның урыс чиркәүләрен ясактан азат итүе дә гайре табигый гамәлләр сыман тоелмый.

Аксак Тимер Баязидны әсир итә. С.Хлебовский рәсеме

ТАРКАЛУ

Ярый, әлеге ике хан ярым тәңрече, ярым шаманчы, ярым нәсара булган, ди, шуңа күрә алар «көндәш» диндәгеләрнең шәһәрләрен җимергәннәр, ди. Әмма Аксак Тимер (Тимерләнг, Тимур) үзе исламда килеш тә Чыңгыздан арттырып мөселман илләрен тар-мар итә, шәһәрләрен җир белән тигезләп, ясмык чәчтерә, үзбәкләрне кыра, болгар-татарларның калаларын юкка чыгара, фарсыларны пыран-заран китерә. Моны ничек аңларга соң?

Аксак Тимер, Чыңгыз хан кебек үк, үзен Аллаһ химаясендәге хаким дип хисаплый. Дәште-Кыпчак аша узган христиан сәяхәтчеләре (җасуслары) мөселманнарны, түркләрне үзара талаштырып, Аурупаны афәттән саклап калу белән мәш килә — болары да, ихтимал, хач яуларының дәвамыдыр.

Тимерләнгнең иң куәтле чагында Аурупа илләреннән (аеруча Испаниядән) илчеләр бик еш килә башлый, алар озаклап, айлар-еллар буе әмир янында бөтерелә, сыйлана. Боларны сәяхәтче-илче дип кенә уйлау — беркатлылык, әлбәттә. Алар — Аурупаның шымчылары да була әле.

Мамай мирзаның зур чирү туплап 1380 елда Мәскәүгә һөҗүм итүендә дә нәсара җасусларының өлеше юк, дип кем әйтә ала? Тарихка «Куликово сугышы» дип кереп калган бу яу Туктамыш хан рөхсәтеннән тыш башкарыла. Мамай җиңелә, Кырымга кача. Аны хәзерге Шәехмамай авылында үзенекеләр үк үтерә. Мәскәү тарихчылары бер-берсен куәтли-куәтли «Куликово сугышыннан соң Дмитрий Донской Мәскәүне татарлар золымыннан коткарды» дип яза. Хаталаналар! Әллә тарихны белмичә, әллә белеп юри шулай эшлиләр. Беренчедән, бу бәрелеш Алтын Урда белән Мәскәвия арасындагы зур сугыш булмый. Икенчедән, аннан соң да Мәскәвия элеккечә Алтын Урдага ясак түләвен дәвам итә. Өченчедән, әйткәнемчә, Мамай үз бүлеклеге белән генә Мәскәүгә яу чаба. Аның ил исеменнән гамәл кылырга хакы булмый. Чынлыкта, Дмитрий Донской Туктамышка булыша, ул «террорист» Мамайны акылга утырта! Дүртенчедән... әлеге яу булганмы әле, булмаганмы — билгесез! Урыс тарихчылары үзләре дә бу сорауга тәгаен җавап таба алмый изалана. Һәрхәлдә, булса да, мәмләкәт эчендәге кечкенә низаг була ул. Артыгы түгел!

Шушы заманда Аурaзиядә кодрәтле өч дәүләт барлыкка килә: Алтын Урда, Әмир Тимер солтанаты, Төркия. Алтын Урда эчке каршылыклардан тетри башлый, Идегәй мирза белән Туктамыш ханның аралары бозыла, алар икегә аерыла, икесенең дә икешәр йөз мең кылычы була. Төркия куәтләнә. Әгәр дә түркнең шушы дүрт баһадиры, дүрт йодрыгы берләшеп, Аурупага бәреп керсә, бүген Аурупа татарча сөйләшеп яшәр иде. Ләкин дүрт түрк, дүрт йодрык, дүрт кодрәт берләшә алмый, дошманлаша. Аларның дошманлашуында, үзара орышуында чит ил җасусларының да кулы уйный. Аксак Тимер Туктамышны пыран-заран китерә, Төркияне җиңеп, Баязид солтанны әсир итә. Аурупа түрк-татарлар явыннан котылып кала һәм... Аксак Тимер янында утырган испан илчесе Клавихо дүрт Аурупа иленең ордены белән бүләкләнә. Алтын Урда таркала, вакланып бетә: Себер ханлыгы, Әстерхан ханлыгы, Кырым ханлыгы, Казан ханлыгы, Касыйм ханлыгы... Ләкин хәтта бу ханлыклар егылгач та, татар халкы кул кушырып утырмаган, көрәшкән, сугышкан, тартышкан!

ЕЛЛАР НИ СӨЙЛИ?

Әйдәгез, тарих җәдвәленә багыйк. Бу җәдвәлне мин НКВДның дымлы базында атып үтерелгән атаклы тарихчыларыбыз Һади Атласи, Михаил Худяков һәм төрек галиме, татар кешесе Надир Дәүләтнең (аның атасы да Ежов-Ягода-Берия җитәкләгән «оеш-

ма» тарафыннан «фаш ителә») фәнни хезмәтләренә таянып төзедем.

1229. Урыс ушкуйникларының Казанны өзлексез талауларыннан туеп, Казан кешеләре кенәз Юрий Васильевичка илчеләр юллый, бер-берсенә яу чапмаска килешү төзиләр.

1230. Элгәреге килешүне бозып, урыслар Казанга сугыш башлый. Әмма Казан талаучыларга каршы тора. Бу сугышта урыс яугире Авра Авралин һәлак була. Татарлар аның мәетен Владимир шәһәренә алып китәргә рөхсәт итә.

1374. Дошманнар туксан сугыш көймәсендә («ладья» дип аталган бу көймәгә алтмыш сугышчы сыйган, димәк, җәмгысе биш мең дүрт йөз сугышчы) Казанга һөҗүм итә. Казан түрәсе юлбасар-ушкуйникларның башлыгына 300 тәңкә биреп, Казанны җимерелүдән саклап кала. Акчаны алгач, юлбасарлар икегә бүленә һәм яр буендагы татар калаларын таларга китә. Илле көймә елганың бер ягын, кырык көймә елганың икенче ягын «кырып» барырга килешәләр, Сарай шәһәрен, Идел-Чулман буендагы тыныч халыкны талыйлар.

1375. Кострома каласындагы урыс гаскәре Казанга яу чаба, шәһәргә бәреп керә һәм бөтен байлыкны талап алып китә.

1376. Бу кышта бөек кенәз Дмитрий Суздальский ике улын — Василий белән Иванны — Дмитрий Волынский җитәкчелегендә Казанны таларга җибәрә. Ул чакта Казан Хөсәен белән Мөхәммәт атлы ханзадәләр идарәсендә була. Алар урысларга контрибуция түләү мәҗбүриятендә кала.

1391. Ушкуйниклар Казанга һөҗүм итә.

1395. Кенәз Юрий Дмитриевич Казанны хәрабә хәленә җиткергәнче җимерә, талый. Бу яудан соң Казан 40 ел буе мантый алмый.

1398. Бөек кенәз Василий Дмитриевичның энесе Юрий Казанга яу чаба.

1399. Кенәз Василий Казанга һөҗүм итә. Бик күп кешеләрне коллыкка алып китә.

1408. Гыясетдин Казан тәхетенә хан булып утыра. Аның идарәсе **1425** елгача дәвам итә. Күптән түгел генә Казаннан 50 чакрым ераклыктагы Хәерби авылында яшереп күмелгән хәзинә таптылар. Хәзинәдә алтын-көмеш акчалар. Алар **1408-1420** елларда Гыясетдин исеме белән сугылган. Бу хәзинә хуҗасы тарафыннан беркайчан да кузгатылмаган. Димәк, Казан һәрвакыт юлбасарлар талавыннан куркып яшәгән.

1425. Казан тәхетендә — Тимерләнг тарафыннан тереләй яндырып үтерелгән Габдулланың (Болгарның соңгы ханы) улы Алибәк. Бу чорда Мәскәү белән Новгород өзлексез рәвештә Казанга һөҗүм итеп тора.

1429. Ул вакытның иң куркыныч явы шушы елда була. Ләкин дошман җиңелә һәм кача башлый. Алибәк урысларны Костромага кадәр куа китә.

1445. Алибәк Алтын Урда кешеләре тарафыннан үтерелә. Мәскәү гаскәре кенәз Василий җитәкчелегендә Казан туфрагына басып керә. Ләкин Казан ханы Олуг Мөхәммәт яуга каты каршы тора, татарлар дошманны тар-мар китереп ташлыйлар. Василий яралана, әсир төшә. Олуг Мөхәммәт хан аны дәвалап Мәскәүгә кайтарып җибәрә.

1468. Мәскәү кенәзе Иван Өченче Казанга яу белән килә.

1469. Иван Өченче кенәз Константин Беззубов җитәкчелегендә Казанга яу чаба.

1477. Мәскәү кенәзе Иван Казанга һөҗүм итә. Ибраһим хан дошман гаскәрен куып тарата.

1487. Мәскәү Казанга һөҗүм итә. Дошман гаскәре Казанны ала, талый, яндыра, күп кешеләрне коллыкка алып китә.

1489. Мәскәү Казанга яу чаба.

1497. Урыс гаскәре, Мәскәүдә тәрбияләнгән Мөхәммәт Әминне Казан тәхетенә утырту сылтавы белән, Казанга керә.

1500. Нугай гаскәрләре Казанга һөҗүм итә.

Югалган Казаныбыз.
Фиринат Халиков
рәсеме

1502. Мөхәммәт Әминне яңадан Казан тәхетенә утырту сылтавы белән Мәскәү гаскәре кабат Казанга керә.

1506. Бөек кенәз Василий Казанга һөҗүм итә. Ләкин Казанны саклаучылар каты тора, дошман кире чигенә.

1521. Урыс гаскәрләре белән Казан капкасы янында сугыш.

1523. Урыс гаскәрләре белән Казан капкасы янында сугыш.

1524. Урыс гаскәрләре белән Казан капкасы янында сугыш.

1530. Урыс гаскәрләре белән Казан капкасы янында сугыш. Дошман явы капкаларны җимереп кала эченә уза. Талау-кыйнау, коллыкка алу башлана.

1546. Мәскәү илбасарлары Казан туфрагына басып керә.

1548. Кансыз Иванның Казанга һөҗүме.

1549. Кансыз Иванның Казанга һөҗүме.

1550. Кансыз Иванның Казанга һөҗүме.

1551. Кансыз Иванның Казанга һөҗүме.

1552. Кансыз Иванның Казанга һөҗүме. Башкалабыз алына. Шәһәрләр, мәһабәт биналар җимерелә, ир-атлар кырыла, йөзәрләгән, меңәрләгән затлы хатын-кызлар әсир төшә, Сөембикә китапханәсе юкка чыгарыла, гөлбакчалар тар-мар ителә. Казан ханлыгы хәзинәсе уналты корабта Мәскәүгә озатыла.

1553. Сөембикәнең энесе Гали Әкрам ханзадә җитәкчелегендә баскыннарга каршы сугыш. Бу сугышта Гали Әкрам һәлак була.

1554. Мәмеш Бирде җитәкчелегендә баскыннарга каршы баш күтәрү, аның рәхимсез рәвештә бастырылуы.

1555. Баһадирлар Кәнәбәк белән Курман Али, Колай һәм Чәбәк мирзалар җитәкчелегендәге гыйсьян (баш күтәрү). Боларның барысы да азатлык өчен көрәштә һәлак була.

1556. Дәүләкәй мирза җитәкчелегендәге гыйсьян. Рәхимсез рәвештә бастырыла.

1557. Әхмәт баһадир җитәкчелегендәге гыйсьян. Баш күтәрүчеләрнең барысы да һәлак була, исән калганнарның башларын чаптыралар. Михаил Худяков язганча, **1553-1556** еллар арасында миллионнан артык татар үтерелә.

1572. Татар гыйсьяны. Бастырыла.

1573. Татар гыйсьяны. Бастырыла.

1582. Татар, чуаш, чирмеш халыкларының уртак гыйсьяны. Рәхимсез рәвештә бастырыла.

1606. Иван Болотников җитәкчелегендәге гыйсьян. Аның гаскәрендә бик күп ризасыз татарлар да була.

1615. Җан Гали җитәкчелегендә баш күтәрү. Җан Гали урыслар тарафыннан әсир алына, асып үтерелә. Ләкин ул кузгаткан гыйсьян **1629** елгача дәвам итә.

1662. Хөсәен Карачура җитәкчелегендәге гыйсьян.

1667. Кондратий Булавин җитәкчелегендәге гыйсьян. Аның урдасында татарлар бик күп була.

1682. Тилекәй Сәгыйть җитәкчелегендәге гыйсьян.

1705. Алдар Күчем җитәкчелегендәге гыйсьян.

1707. Степан Разин җитәкчелегендәге гыйсьян. Аның гаскәрендә бик күп татар сугыша.

1735. Акай белән Абдулла батыр җитәкчелегендәге гыйсьян.

1736. Йосыф Арык белән Җиһанбай җитәкчелегендәге гыйсьян.

1742. Казан губернасындагы 418 мәчет вәхшиләрчә җимерелә.

1755. Батырша (Габдулла Гали) җитәкчелегендәге гыйсьян. Төрмә сакчылары белән сугышканда үтерелә.

1772. Пугачёв явы. Гаскәренең 80%ын татар, башкорт, чуаш тәшкил итә.

1778. Татар гыйсьяны. Бастырыла.

1885. Сөләй батыр җитәкчелегендәге гыйсьян.

1896. Татар гыйсьяны.

1918-1922. Урта Азия империягә

«кайтарылганда» татарлар күпләп һәлак була.

1930-1940. Сталин тарафыннан иң галим татар интеллигенциясенең юкка чыгарылуы.

1941-1945. Фашистларга каршы сугышта иң алгы сафта татарлар күпләп кырыла.

1944. Татарларның Кырымнан куылуы. Юлда яртысының һәлак булуы.

Менә нинди безнең тарих! Шуларга өстәргә мөмкин: **1954** елда Тоцк янында ике атом бомбасы шартлый, якындагы татар авыллары юкка чыга, исән калганнары нурланыштан гарипләнә; **1983** елдан алып атаклы татар шәхесләренә бәйле биналар җир белән тигезләнә, хәтта Тукай яшәгән кунакханә дә җимерелә! Калмасын тарих, калмасын хәтер! **Яңа гасырның унынчы елларыннан** башланган афәтләр: татар мәктәпләренең ябылуы, Татарстан радиосының юкка чыгуы, татар матбугатының буылуы һ.б., һ.б.

БҮГЕН

Дәүләтчелеген югалтканнан соң татарларга 63 мең квадрат җир бүленеп бирелде, шунда Татарстан җөмһүрияте төзелде, әмма күпчелек милләттәшебез (2/3) читтә калды. Чуашстан, Мари Иле, Удмуртия, Башкортстан, Кырым, Себер, Урта Азия, Пенза, Урал киңлекләрендә мәктәпсез, милли автономиясез гомер кичерергә мәхкүм халык без — татарлар! Татарстанда калган татарларның да хәле шәптән түгел. Ана теленең кысыла баруы гына да ни тора!

Гомер буе интернациональлекне берьяклы гына аңлый килдек. Сүз дә юк, без, чыннан да, интернациональ халык: урыс милләтен сөябез, аларның телен беләбез, җырларын җырлыйбыз, тарихын, йолаларын ихтирам итәбез... Әмма ни өчендер алар безнең телне, гореф-гадәтләрне белми, белергә дә теләми. Толерантлык, дип күкрәк төябез! Әмма толерантлыкның икенче мәгънәсе дә бар: ул — авыруларга каршы торучы көчнең зәгыйфьләнүе, иммунитет системасының какшавы...

Борынгы бабаларыбыз дәүләт арты дәүләт корган. Ә бүген ни? Русиядә сан ягыннан икенче урында торган халык үзе теләгән имляны да куллана алмый! Латин алфавиты Русиянең бөтенлегенә зыян китерә, имеш! Сафсата! Татарлар Русия эчендә дүрт йөз ел гарәп хәрефендә язганнар, аңа карап империя таркалмаган; татарлар ун ел буе СССР эчендә латин шрифтын кулланган, аңа карап СССР хәлсезләнмәгән, киресенчә, ныгый гына барган; инде татарлар янә латинга кайтсалар, Русия җимереләчәкмени? Юк! Киресенчә, халыкларга тигез хокуклар бирелгән очракта, алар Мәскәүгә рәхмәтле генә булачак, уртак ватаннарын гөлбакча итәр өчен бернинди куәтен кызганмаячак. Тарихта моның мисалы булмады түгел: Әби патша дин иреге, мәчетләр кору, Коръән, китаплар чыгару турында фәрман биргәч, Русиягә тагын да теләбрәк, яратыбрак хезмәт итә башламадыкмыни? Инде татар телен илкүләм икенче дәүләт теле итеп тә игълан итсәләрме... Утопия, дияргә ашыкмагыз! Ана телебез дөньядагы иң күп, иң актив кулланыла, иң җиңел өйрәнелә торган ундүрт тел арасына кергән икән, нишләп аның Русиядә рәсми статус алырга хакы булмасын? Финляндиядә 300000 швед яши. Шуңа да карамастан, швед теле дәүләт теле дәрәҗәсендә. Ә без, татарлар, рәсми мәгълүматлар буенча гына да, Русиядә биш миллион ярым хисабында йөрибез! Ләкин бу бик шикле саннар. Чөнки Тукай Идел буе татарларын 10000000 кеше, дип яза (1985 елда чыккан биш томлыгы, дүртенче том, 208 бит). 1911 елда Идел буенда гына да шулкадәр булсак, әле татарлар күпләп яшәгән Урал, Себер, Казакъстан, Үзбәкстан, Кырымны да кушсак... түгәрәк кенә, матур гына сан килеп чыгар иде. Ким дигәндә биш миллион татар күз алдында юкка чыккан! Кая киткән алар? Үрчер, артыр урында? Моны ничек аңлау-аңлату мөмкин икән? Бәлки,

100 ел эчендәге сугышларда татарлар иң алгы сафта сугышып, күпләп кырылганнардыр? Әллә татар ирләре гайрәтсезме? Татар хатыннары кысырмы? Юк, татар гаиләсендә 3-5 бала иде, югыйсә! Ярар, Тукай ялгышсын да, ди. Рәсми саннар ни күрсәтә анда? Надир Дәүләтнең *«Русия төркиләренең милли көрәш тарихы» китабына мөрәҗәгать итик, автор 363 биттә «1897 елдагы халык санын алу нәтиҗәләреннән күренгәнчә, Русиядә 2500000 татар яшәгән»*, дип яза. Русиядә гомер кичергән үзбәкләр 1897 елда 1837240 кеше тәшкил иткән. 1939 елда аларның саны — 5000000. Соңгы җанисәп күрсәткечләре буенча, 20000000га җиткәннәр! Казакъларда да шул ук хәл. Ә татар 5000000, имеш… Монда ниндидер хата, ялгыш бар сыман!

БАШКАЛАР КҮЗЛЕГЕННӘН

Татарлар (әлбәттә, карасөякләр) урыс мещаннары кебек ук, йодрык уйнатырга ярата. Язын яисә көзен, һава торышы матур чакта, кичкә таба, сугышчылар Кабан күле буена җыела. Татарлар тамак ертып кычкыра-кычкыра урысларга ташлана, бу бәрелештә чырайлар җимерелмичә калмый. Мин мондый сугышларда татарларның урысларга караганда өстен икәнлеген игътибарга алдым…

Карл Фукс

Өйгә кайта торган юл яңа гына сөрелгән кара җир аркылы уза… Җир яхшы сөрелгән һәм туфрак өстендә бер генә үсемлек тә, бер генә үлән дә күренми — аяк асты кап-кара… Алдарак, юлның уң тарафында, ниндидер куакчык күренә. Якынрак килгәч, әле генә йолкынып ташланган «татарин»ны күрдем… Куакчыкны арба тәгәрмәче изеп узган, әмма ул әле һаман исән калкырга маташа, янтаеп торса да, тураерга тырыша. Гүя аның бер кисәк тәнен умырып алганнар, эчәкләрен актарып чыгарганнар, кулын өзеп ташлаганнар, күзен чокып чыгарганнар. Ләкин ул барыбер тора. Һәм тирә-ягындагы туганнарын кырып салган көчкә буйсынмый.

«Ай-һай, нинди гайрәт! — дип уйладым мин. — Бәндә бөтен нәрсәне һәлак иткән, миллион үсемлекләрне юкка чыгарган, ә бусы әле һаман да бирешми».

Лев Толстой

Икенче Бөтендөнья сугышында татарлар чиксез батырлыклар күрсәтте. Сугыш елларында Советлар Союзы Каһарманы булган совет сугышчылары арасында татарлар сан ягыннан өченче урынны алып тора.

Татарстан АССР тарихы

Татарстан егетләре арысланнардай сугышалар.

Иван Конев,
Советлар Союзы маршалы

Карт солдат буларак, мин сугышчы һәм командир татарларны күп күрдем һәм һәрвакыт аларның сугышта нык торуларына, тимердәй ихтыярлы булуларына соклана килдем.

Родион Малиновский,
Советлар Союзы маршалы

Кулга-кул килеп сугышканда татар ачулы. Һәм немец ефрейторы Рудольф Вольгангның үз кардәшләренә зарлануы юкка түгел: «Монда безгә каршы татар күп куелган. Болар шашкан халык һәм мин татар белән хәтта төшемдә дә очрашырга теләмәс идем».

Илья Эренбург

Шуңа өстәп нәрсә әйтәсең? Мәкаләне сөекле шагыйребез Габдулла Тукай сүзләре белән тәмамлыйк.

Без сугышта юлбарыстан көчлебез,
Без тынычта аттан артык эшлибез.
Шул халыкныңмы хокукка хаккы юк?
Хаккыбыз уртак ватанда шактый ук! ■

НӘСЕЛ ШӘҖӘРӘЛӘРЕ

Бакый Зыятдинов
(1930-2014)

Гаилә – җәмгыятьнең, илнең нигезе, беренче күзәнәге. Кешеләрдә әхлак тәрбияләүдә гаиләне җәмгыятьнең бер генә оешмасы да алыштыра алмый. Шулай ук хезмәт сөючәнлек, милеккә сак караш, үзара ихтирамлылык та гаиләдә тәрбияләнә.

Мин үземнең бу язмамда нәсел шәҗәрәләрен төзү һәм аларның әһәмияте турындагы фикерләремне җиткерәсем килә.

Татарларда 7 бабаны белү һәркемгә мәҗбүри саналган. Кешеләр үз бабаларының кемнәр икәнен белеп, алар рухына дога кылган, зиратларга барып кaберләре янында Коръән укыган. Ә инде муллалар, байлар, укымышлы кешеләр үзләренең ким дигәндә 9 бабаларын белгән. Бу теләк кенә булмаган, ә чынлап та тормышка ашырылган. Хәзерге вакытта тарихчы галимнәр төрле гаиләләрдә, архивларда сакланып калган нәсел шәҗәрәләре буенча халыкларның тарихын, этногенезын, аларның күчешләрен өйрәнә, кызыклы гына ачышлар ясый. Бигрәк тә археограф, профессор Марсель Әхмәтҗанов бу өлкәдә бик нәтиҗәле эшли. Хәзерге чорда мәктәп укучылары, студентлар арасында да бу юнәлештә төрле конкурслар оештырыла, конференцияләр үткәрелә — мин моны бик кирәкле гамәл, дип саныйм. Без яшьләрне үзләренең нәсел тамырларын өйрәнергә, матур гаилә традицияләрен дәвам итәргә өндәргә тиеш. Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк, дигән канатлы сүз бик урынлы.

Совет чорында без «искене сүтеп, җимереп, яңаны төзибез» дигән лозунг астында яшәдек, ләкин искесен җимерүен җимердек, ә аны алыштырырлык яңасын төзи алмадык. Бигрәк тә әхлак тәрбиясе өлкәсендә ярык тагарак алдында калдык. Бу чорда кешеләр, бигрәк тә җитәкче урында эшләүчеләр үзләрен ярлы яки, һичьюгы, урта хәлле гаиләдән чыккан итеп күрсәтергә тырышты. Ярлылык козырь (өстенлек) саналды. Андыйлар партия сафларына да сынау-сроксыз алынды. Кешеләр үзләренең затлы нәселдән булуларын яшерергә тиеш булдылар, ачып салсалар, аларга юл Себергә иде. Менә хәзер заманалар үзгәрде, кешеләр, бигрәк тә җитәкчеләр үзләрен затлы муллалар, гильдия сәүдәгәрләре, түрәләр нәселеннән итеп күрәселәре килә. Еш кына ул шулай булып та чыга. Безгә нәсел шәҗәрәсе төзү буенча күп кенә заказлар килә. Соңгы елларда илледән артык нәселнең шәҗәрәләрен үз районыбыз Балтач кешеләренә генә түгел, Арча,

Бакый Зыятдинов

Саба, Аксубай, Чирмешән районы кешеләренә дә төзеп бирдек. Ә кызыксынучы кешеләргә күрсәткән ярдәм тагын да күбрәк. Мин журнал укучыларын нәсел шәҗәрәсе төзүнең методикасы белән таныштырырга уйлыйм.

«Себер тракты тарихы» музеен оештыру чорыннан (1993-1995) ук төбәгебез тарихына нисбәтле язма чыганакларны эзләргә керештек. Минем фикеремчә, музей ул борынгы әйберләр җыелмасы гына булырга тиеш түгел, ә бирегә килгән кешеләр үзләренә кирәкле мәгълүмат та алып китәргә тиешләр. Шуңа да без ТР Милли архивыннан, Киров өлкәсе дәүләт архивыннан, Россия борынгы актлар архивыннан (Мәскәү), Россия дәүләт тарих архивыннан (Санкт-Петербург), Башкортстан Үзәк тарих архивыннан (Уфа) авыллар, мәктәп-мәдрәсәләр, мәчетләр, байлар, һөнәрчеләр һ.б. турында тарихи документлар соратып

алып, үзебездә шактый чыганаклар тупладык. Бу мәгълүматлар нәсел шәҗәрәләре төзегәндә файдаланыла.

Авыл җирендә нәсел шәҗәрәсе төзегәндә файдаланыла торган беренче чыганак — авыл советларында саклана торган **хуҗалык кенәгәләре** (хозяйственные книги). Монда гаилә составы, аларның туганлык мөнәсәбәтләре, гаилә әгъзаларының ничә яшьтә булулары язылган. Күп авылларның 1940 елгы, ә кайбер авылларның 1936-1939 еллардагы хуҗалык кенәгәләре сакланган.

Икенче чыганак — **метрика кенәгәләре**. 1828 елда патша муллаларга мәхәллә кешеләренең гражданлык хәле актларын теркәтү турында указ чыгара һәм күп муллалар 1829 елдан метрика кенәгәләрен тутыра башлаган. Метрикаларда баланың әтисе, әтисенең әтисе, әнисе исемнәре дә язылган, ә кайбер муллалар фамилиясен, ягъни әтисенең бабасын да язган. Чиркәүләрдә исә метрика тутыру элегрәк башланган, мәсәлән, әүвәл керәшен авылы булган Апазда чиркәү попының метриканы 1774 елдан тутыра башлаганы билгеле.

Нәсел шәҗәрәсе төзү өчен өченче чыганак — **«ревизские сказки»** — халык санын алу кенәгәләре. 1716 елдан 1858 елга кадәр ун ревизия үткәрелгән (1716, 1745, 1762, 1782, 1795, 1812, 1816, 1834, 1851, 1858 елларда). Ул бер ел эчендә генә тәмамланмаган, ике яки өч елга кадәр сузылган (мәсәлән: 1716-1719). Билгеле, «ревизские сказки»ларга кадәр дә җан исәбе алынган. 1602-1603, 1647-1656, 1678 елларда җир, халык исәбен теркәү үткәргәннәр. Борынгы авылларда яшәүче кешеләрнең бабаларын алардан да табарга була. Мәсәлән, мин үземнең бабайның исемен 1678 елгы халык исәбен алган **«ландратская книга»** материалларыннан таптым.

Хәзер ничек итеп шушы чыганаклардан файдаланырга, дигән мәсьәләне карап китик. Мин моны үз бабайларымны эзләү мисалында күрсәтәм. Бабам миңа үзенең 6 бабасының исемен әйтеп калдырды. 1940 елгы Таузар авылының хуҗалык кенәгәсендә минем бабам Зыятдинның 1869 елда туганлыгы күренә, фамилиясе Шакиров дип язылган, бездә — татарларда — әтисе исеме фамилия итеп алынган. Таузар авылының 1869 елгы метрикасыннан Зыятдинның әтисе Шакир, ә Шакирның әтисе Мөхәммәтҗан икәнен эзлибез. 1858 елгы ревизия материалларыннан әтисе Мөхәммәтҗан булган Шакирны табабыз. Бу документта Мөхәммәтшакирның әтисе Мөхәммәтҗан, Мөхәммәтҗанның әтисе Гобәйдулла, ә аның әтисе Рахматулла булуы күренә. Шуннан соң 1816, 1834 еллардагы ревизияләргә күчәбез. Аннан, борынгырак ревизиягә күчә-күчә 1716 елгы ревизиягә барып җитәбез, һәм, ниһаять, 1678 елгы җан исәбен алу кенәгәсенә күчәргә була. Шул юл белән мин үземнең 10 бабамны таптым. Әтине, үземне, улымны, оныгымны кертеп, 14 буынны язып куйдым. Буыннар арасына уртача 30 ел куйганда, бу 400 елны эченә ала. Чыннан да, мин тапкан иң борынгы бабам Дәрвиш 1600 елларда туган булып чыга.

Мәсьәләнең бер авыр ягы — ул да булса ТР Милли архивын-

да ревизия материалларының тулы сакланмавы. Казанда Казан өязенең 1858, 1851, 1834 елгы материаллары тулы диярлек, ә 1816, 1812, 1795,1782 елгылары сакланмаган. 1716, 1745, 1762 елгылар Мәскәүдә Россия дәүләт борынгы актлар архивында саклана, без шуннан алдырдык. 1795, 1812 елгы ревизия материаллары булмагач, 1816 елдан 1762 елга күчеп, бу нәсел кешесен табу авыррак. Бу очракта без эзли торган кешенең 1816 елда 54 яшьтән олы булуы яки ул исемнең сирәк очравы кирәк.

Балтач районының 2/3 өлеш авыллары элек Вятка губернасына кергән, ә Киров өлкәсе дәүләт архивында 1795, 1812, 1816 елгы ревизия материаллары әйбәт сакланган. Шуның өстенә, 1762 елгы документлар Казанда саклана, ә безнең Казан өязенеке юк. Элекке Минзәлә өязенә кергән авылларныкын Уфа шәһәреннән Башкортстан Үзәк тарих архивыннан алдырдык.



Зыятдиновлар шәҗәрәсе

Шәҗәрә агачның оч өлешен (ягъни хәзерге заман чорын) гаилә кешеләре үзләре белергә тиеш, бу мәгълүмат алардан сорап языла.

Билгеле, нәсел агачы төзеп кенә чикләнмичә, ул нәселдән кемнәр чыккан, алар кайларда, нәрсә белән шөгыльләнгәннәрен дә өйрәнергә кирәк, шул рәвешле матур традицияләрне дәвам итә алабыз. Менә шунда инде нәселең белән горурлану хисе туа да. Безнең борынгы бабаларыбыз нәсел-нәсәпләрен, бабаларын белеп кенә калмаган, туганлык җепләрен дә саклаган, бер-берсенә ярдәм иткән, уртак эшләрне өмә белән башкарган. Өй күтәрү кебек эшләрне бөтен нәселе белән бергә түләүсез эшләгәннәр, урыпҗыюда да бер-берсенә булышканнар, төрле бәла-каза, янгын, су басу булган очракта да нәсел кешеләре бер-берсенә терәк булган. Нәселдәге күркәм күренешләр хупланган, буыннан-буынга күчә барган, ә берәрсе ярамаган эш эшләсә, «нәселдә булмаганны» дип, ул яманлыкны эшләүчене әрләгәннәр. Гомумән, нәсел традицияләре — гаилә ныклыгының нигезе булып тора, уңай гадәтләр нәселдән-нәселгә күчерелә бара. ■

ЙОСЫФ ТУГАН КӨН

Наил Таиров, Илһам Таиров

Йосыф Акчураның тормыш юлы һәм киң кырлы эшчәнлеге турында язмалар шактый. Аның белән галимнәр дә, төбәкне өйрәнүчеләр дә шөгыльләнде. Әмма әлеге олуг шәхеснең биографиясендә безгә мәгълүм булмаган сәхифәләр дә бар. Аеруча аның бала чагы, яшьлек чорлары безнең өчен караңгы.

Йосыф Акчура 1876 елда туган, ләкин туган көне әлегә кадәр безнең өчен төгәл мәгълүм түгел иде. «Татар энциклопедиясе»ндә Л.Айнетдинова язган мәкаләдә 29 ноябрь, дип күрсәтелгән. «Википедия» сайтында исә Й.Акчураның туган көне 2 декабрь, дип куелган. Әмма алга таба әлеге даталарның дөрес түгеллеге дәлилләнәчәк. Й.Акчураның фәнни-публицистик мирасын өйрәнүгә шактый көч куйган олуг галимебез Мәсгут ага Гайнетдин дә аның туган көне турында берни әйтми. Әлбәттә, Й.Акчура биографиясе кертелгән башка төр җыентыклардан да без әлеге мөхтәрәм шәхеснең туган көне турында белә алмыйбыз.

Безгә, Сембер өлкәсенең дәүләт архивында тикшеренү эшләре алып баруыбыз нәтиҗәсендә, мәшһүр фабрикантлар һәм хәйриячеләр нәселеннән булган әлеге гыйлем иясенең, сәясәтченең төгәл туу датасын ачыкларга насыйп булды.

Сембер шәһәренең XIX гасырдагы указлы мулласы, үзе язып барган метрика кенәгәләренең берсенә нигезләнеп, 1889 елның 25 нче сентябрендә татар телендә мондый белешмә («дәфтәре метрикадан язу») бирә: *1) Мөхәммәдйосыф вөҗүдкә килмеш (туган); 2) ноябрьнең икенче көнендә 1876 елда; 3) атасы Сембернең первой гильдии купец Хәсән Сөләйман углы Акчурин; 4) анасы Фәхрибану Габдерәшид кызы; 5) Бәлдә (шәһәр) Сембердә вөҗүдкә килмеш (туган). Сембердә имам җамигъ Вәлиулла Габделгаффар улы.* Документка шул ук имамның мөһере сугылган: «Мулла Велиулла Абдул Гафаров».


2

Метрическая выпись

указнаго Имама Города Симбирска

Мухаметъ-юсифъ родился	ноября 2го дня 1876 г.	отецъ его Симбирск. 1ой гильдiи купецъ Хасянъ Селеймановичъ Акчуринъ, мать Фехри-бану Абдурешетовна	въ гор. Симбирскъ	№ 11

Симбирский указный мулла Абдул Гафаровъ

Йосыф Акчураның туган көне, урыны һәм әти-әнисенең исемнәре күрсәтелгән белешмә. 1889 ел

Белешмәнең русчага тәрҗемәсе дә бар. *«Метрическая выпись указного имама города Симбирска: 1) Мухамет-Юсиф родился; 2) ноября 2-го дня 1876 г.; 3) отец его Симбирский 1-й гильдий купец Хасян Селейманович Акчурин; 4) мать Фехри-бану Абдурешетовна; 5) в гор.Симбирск. Симбирский указный мулла Абдул Гафаров».*

Димәк, Й.Акчура иске стиль белән 1876 елның 2 ноябрендә (яңа стиль буенча 15 нче ноябрендә) дөньяга килгән. Шунысын да искәртергә кирәк, әлеге белешмәдә теркәлгән мәгълүмат шәхеснең туу датасын ачыклау өчен әлегә бердәнбер чыганак.

Туу урыны мәсьәләсе белән эш берникадәр катлаулырак. Беренче карашка, галим туган урын Сембер шәһәре кебек, чөнки гражданлык актларын метрика кенәгәсенә әлеге шәһәрнең указлы имамы язып барган. Әмма Й.Акчураның кендек каны Казан шәһәрендә, әнисенең ватанында тамган булырга да мөмкин. Бер шәһәр яки авылда туып, икенчесендә теркәлү тәҗрибәсе элек тә булган, хәзер дә гамәлдә.

Йосыфның Зөябаш (Старотимошкино) авылында туганлыгын да инкяр итеп булмый. Чөнки губерна үзәгендә йорт сатып алганчы Акчуриннарның төп утары шунда булган. Кызганыч, Й.Акчураның кайда туганлыгы турында төгәл әйтеп булмый, гәрчә белешмә документта Сембер шәһәре, дип язылган.



Белешмәнең татарчасы. 1889 ел

Туган көнен төгәл күрсәтүдән тыш, әлеге документ безгә янә бер кыйммәтле мәгълүмат бирә. Чыганакта Й.Акчураны дөньяга китергән ананың исеме төгәл күрсәтелгән. Фәнни әдәбиятта исә Йосыф әнисенең исеме ике вариантта: Камәрбану (Бибикамәрбану) яки Фәхрибану, дип языла иде. Белешмә-документта «Фәхрибану» дип язылган булу, безгә әлеге вариантның дөреслеген исбатлый. Шулай итеп, киләчәктә дөнья күрәчәк фәнни хезмәтләрдә, әлбәттә, без Й.Акчураның әнисен Фәхрибану, дип язарга тиешбез.

***

Белешмә-документ турында берничә сүз. Документ Акчуриннар гаиләсенең фаҗигале чорында язылган. Хәсән Акчурин, 1879 елда вафат булганнан соң, аның мал-мөлкәтен бүлешү һәм варислары арасында рәсмиләштерү процессы башлана. Кредиторларга Хәсәннең һәм гаиләсенең бурычларын түләргә кирәк була. Х.С.Акчуринның милкендә булган объектлар барлана. Мәгълүм ки, бу мал-мөлкәт Сембер губернасында гына түгел, ә башка төбәкләрдә дә була. Әлеге байлык, күчемсез милек белән идарә итү мәсьәләсе килеп туа. Без танышкан белешмә-документ та нәкъ менә шушы авыр һәм катлаулы мәсьәләләрне хәл итү процессында бирелгән.

Белешмәне биргән мулла турында түбәндәгеләрне әйтергә мөмкин. Вәлиулла Габделгаффаров – Сембер шәһәренең күренекле муллалары нәселеннән. Габделгаффаровлар – укымышлы кешеләр, рус телен дә камил белгәннәр. Алар татар сәүдәгәрләре һәм бай эшкуарларының васыятьнамәләрен рус теленә тәрҗемә иткән (мәсәлән, Акчурин Курамша Габдулла улы (1868), аның энесе Сөләйман (1864)). Шулай итеп, Й.Акчурага нисбәтле документта да Вәлиулла имам имзасы булу очраклы күренеш түгел. ■

ЧЫҢГЫЗ АЙТМАТОВНЫ БИРГӘН МӘЧКӘРӘ

Фәүзия Бәйрәмова

Хәмзә Габделвәлиев. Мәскәү, 1889 ел

Узган җәй миңа Кукмара районының Мәчкәрә авылында булып кайтырга туры килде... Моңа кадәр дә Сахалиннан алып Төркиягә кадәр бик күп татар авылларын күргәнгә, юл йөрергә ияләнгәнгә, Мәчкәрәгә дә бары тик булачак китабыма материал туплау өчен генә барган идем.

Мин бирегә дөньякүләм танылган язучы Чыңгыз Айтматовның нәсел җепләрен, аның әнисе ягыннан татар тамырларын эзләп килдем. Ләкин Мәчкәрә мине тагы әллә кайсы яклары белән үзенә бәйләп куйды, яраттырды, сокландырды, гаҗәпләндерде... Бирегә барысы да бар иде: җанга рәхәтлек бирерлек гүзәл табигать, таш мәчетләре һәм йортлары белән борынгылыкка шаһәдәтлек биреп торган чал тарих, кабер ташларына тарих моңы сеңгән борынгы зират, Котып белән Казан арасында барлыкка килгән кариле татарлары язмышы... Чәчәк атып утырган, һәр йорты гөл кебек булган, тырыш, иманлы, мәгърифәтле татар авылы!.. Хәер, Кукмара районында һәр авыл шундый диярлек. Алай да, Мәчкәрә элек тә, хәзер дә аларның барысыннан да аерылып торган, ул саладан бигрәк, каланы хәтерләткән, мәдәният-мәгърифәт ягыннан да, сәнәгать-промышленность ягыннан да үзәк ролен башкарган. XVIII гасыр ахырында ук монда таш мәчетләр һәм данлыклы мәдрәсәләр булган, XIX гасырда исә Мәчкәрәдә киҗе-мамык, бәс-тукыма фабрикалары, чуен кою заводлары гөрләп эшләгән, аның сәүдәгәрләре дөнья буйлап эш йөрткән. Моңа төбәк тарихын өйрәнүче галимнәр дә игътибар иткән: *«До советского периода село входило в состав Малмыжского уезда Вятской губернии, — дип яза алар. — Населённый пункт резко отличался от многих татарских селений тем, что уже в конце XVIII века являлся торгово-промышленным центром. С 1778 года здесь свою продукцию производили кумачная и кожевенная мануфактуры, принадлежавшие братьям Абдулле, Мухаметрахиму и Ярулле Утямышевым. В XIX веке их потомки владели медеплавильным, мыловаренным, суконным, ваточным предприятиями в Казанской и Вятской губерниях».* (Кукморский край. — Казань, 2008. — С.161.)

Бу хезмәттән күренгәнчә, «беренче гильдияле Малмыж купецлары» Үтәмешевләр хәйриячелек белән дә нык шөгыльләнгән — алар Малмыждан Казангача арада йөзләгән мәчет-мәдрәсәләр салдырган һәм тоткан. «1802 елда Казанда алар акчасына «Иске таш» мәчете һәм 1882 елда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе төзелә», — дип язалар алар турында. Моның өстенә Үтәмешевләр төрле дәрәҗәдәге депутатлар, гласныйлар, җәмәгать эшлеклеләре дә булып тора. Әмма совет власте аларның бар мал-мөлкәтен тартып ала, үзләрен төрмәләргә озата. Затлы, мәгърифәтле Үтәмешевләр нинди шартларда да юкка чыкмый. Шушы Мәчкәрә авылында 1926 елда туган, 3 яшендә әнисе белән сөргенгә сөрелгән Рөстәм (Үзбәк) Исмәгыйль улы Үтәмешев галәм һәм медицина өлкәсендә дөньякүләм танылган галимгә әйләнә, космонавтлар әзерли, шул исәптән — Юрий Гагаринны да. Аның улы Илдар Үтәмешев тә медицина техникасы өлкәсендә дөньякүләм танылган галим, Мәскәүдәге зур фәнни

институтның җитәкчесе. Билгеле, Чыңгыз Айтматов тамырларының нәкъ менә шушы авылга, нәкъ менә шушы Үтәмешевләргә барып тоташуы бер дә гаҗәп түгел кебек. Әмма дөньяга яшерен символ-тамгалар телендә яза алырлык талант иясен биргән Кукмара төбәге әле башка үзенчәлекләре белән дә аерылып торырга тиеш иде... Һәм ул үзенчәлекләрне мин борынгы тарихыбызда таптым.

Кукмара төбәге турында, шул исәптән Мәчкәрә авылы хакында да инде шактый яздылар, шуңа күрә, мин монда нининдидер яңалык ачарга җыенмыйм. Бары тик төбәк тарихының әлегәчә читтәрәк калган якларын яктыртмакчы булам (әлбәттә, үз күзаллавым белән). Кызганыч ки, бездә барлык авылларның да диярлек тарихы урыс архивларында телгә алынган вакытлардан башлана, бу, нигездә, XVII-XVIII гасырлар, сирәк очракта — XVI гасырның икенче яртысы. Мәчкәрә тарихы белән дә шулай. Энциклопедияләрдә һәм, гомумән, күпчелек язмаларында авылга нигез XVI гасырның икенче яртысында, ягъни Казан ханлыгы җимерелгән чорда салынган, диелә. Әйе, 1552 елгы фаҗигадән соң татарларның бер өлеше шушы якларда сыену табарга мөмкин. Әмма бу әле аңарчы биредә татар авыллары булмаган, дигәнне аңлатмый. Адәм баласы һәрвакыт кеше яшәгән җирдә урнашырга тырыша. Татарлар да бер-берләре янына сыенырга омтылган, утлы-сулы, мәчет-мәдрәсәле авылларга килеп урнашкан.

Безнең фикеребезчә, Мәчкәрә авылы XVI гасырга кадәр дә булган, һәм анда, кайбер тарихчылар язганча, удмурт-арлар гына яшәмәгән, татарлар да көн күргән. Гомумән, кешеләр бу тирәләрдә моннан ун мең еллар элек яшәгән, бу турыда Кукмара төбәгеннән, Мәчкәрә авылыннан табылган борынгы табылдыклар сөйли. *«Человек обитал на кукморской земле несколько тысяч лет назад, об этом говорят находки, обнаруженные в Урясьбаше, Кукморе, Маскаре, Салтык-Ерыкле,* — дип язалар тарихчылар. — *Каменное долото, скол с конического нуклеуса, каменный отбойник, найденные в них, принадлежат эпохе неолита (около VIII-III тысячелетия до нашей эры)».* (Кукморский край..., С.37.) Бу кешеләр кемнәр булган? Өздереп кенә әйтә алмыйбыз. Әмма безнең җирләрдәге бөтен борынгы тарихны җиңел генә фин-угыр халыкларына биреп кую белән дә килешмибез. Бу — безнең дә җирләр, безнең дә тарих, безнең дә язмыш...

Кукмара районының археологик картасында Мәчкәрә авылында таш һәм бронза чорында да кешеләр яшәгәнлеге, алардан торак урыннары калганлыгы һәм шул заман табылдыклары яктыртылган. Югарыда телгә алынган «Кукморский край» китабында бу якларда беренче болгарларның 1236 елларда пәйда булуы хәбәр ителә: *«Первые булгары появились в селе Маскара, освоенной до них черемисами. Затем появились булгаро-татарские села Кулларово (Чишмабаш), Ураскино (Туембаш) и Янцобино»*. (Кукморский край..., С.38.) Мәчкәрә авылыннан шулай ук Алтын Урда чоры тәңкәләре табылганлыгын да әйтеп үтәргә кирәк. Димәк, биредә татарлар инде шул чорларда ук яшәгән. Әйткәнебезчә, Казан җимерелгәч, аларга качып котыла алган казан татарлары да килеп кушыла, Касыйм ханлыгында, мишәр илендә хәлләре авырайгач, чукынудан качкан татар-мишәр морзалары да биредә сыену таба. Менә шушы «морзалар факторы»на киңрәк тукталасы килә.

Заманында Мәчкәрә авылы Ишмән иле дип аталган, аңа нигезне Бөрбаш авылыннан килгән Ишмән Туктаргали улы салган, дигән фараз бар. Безнең уебызча, Ишмән инде моңа кадәр булган авылга килеп урнашкан. Туктаргали картның кабере бүгенге көндә Балтач районының Бөрбаш авылында, ә Ишмән нәселе исә шушы Мәчкәрә

Хәмзә бай (уңнан беренче) гаиләсе белән. Беренче рәттә, әтисе янында – Нәгыймә. Каракол шәһәре, 1909 ел

төбәгендә тамыр җибәргән. Бу зур нәселнең дүрт йөздән артык кешене үзенә туплаган шәҗәрәсе узган гасырларда ук эшләнгән, ул соңгы вакытларда тулыландырылган һәм фәнни әйләнешкә кертеп җибәрелгән.

Мин әлеге шәҗәрәнең гарәп һәм кирилл хәрефләре ярдәмендә язылган вариантлары белән Кукмара районы төбәк тарихын өйрәнү музеенда да, татар шәҗәрәләре турындагы фәнни китаплар аша да таныштым. Бу нәсел шәҗәрәсенә җентекләп тукталуымның сәбәбе — Чыңгыз Айтматовның әнисе Нәгыймә апа да шушы Ишмән нәселеннән була, аның әтисе Хәмзә шушы Мәчкәрә авылында 1840 елларда туа, ул Габделвәлиев фамилиясен йөртә. Шәҗәрәнең зур бер тармагы исә Үтәмешевләр фамилиясе белән дөньяга тарала, алардан да танылган байлар, иганәчеләр, зур галимнәр чыга. Шәҗәрә төзүчеләр Ишмән нәселенең Шәһре Болгар якларыннан булуын язып калдырган, шул ук вакытта аларның Ханкирмәннән (Касыйм каласы), төньяктан килүләренә дә ишарәләр бар, Ишмән нәселенең данлыклы Кара бик, Карахан нәселе белән дә бәйлелеге күренә.

Мәчкәрә элек тә, хәзер дә авылларның барысыннан да аерылып торган, ул саладан бигрәк, каланы хәтерләткән, мәдәният-мәгърифәт ягыннан да, сәнәгать-промышленность ягыннан да үзәк ролен башкарган.

Кара бик шәҗәрәсенең берничә варианты бар, ул Татарстанда, бигрәк тә, төньяк районнарда шактый таралган. Белгәнебезчә, Кукмара районы республикабызның төньягына урнашкан, ә Мәчкәрә авылы бу районның да иң төньяк читендә, Киров өлкәсе чигендә. Кара бик шәҗәрәсенең галим Сәет Вахиди тапкан нөсхәсендә Ишмән

исеме дә бар, ул инде теге заманнар өчен соңгы буыннарның соңгысы булып тора. Шәҗәрә Туктар Ибраев тарафыннан 1851 елда төзелгән. Кара бик шәҗәрәсенең күпчелек вариантлары Нух галәйһиссәламнән башлана, арада күп ханнар һәм акыл ияләре бар, шулар арасында Сократ хәким һәм Бачман ханның исемнәре дә еш телгә алына. Шәҗәрәләрдә Кара бик нәселенең Рум тарафыннан, Византиядән килгәнлеге кат-кат әйтелә, Искәндәр Зөлкарнәйн исеме кабатлана, Идел-Җаек буйларына килеп урнашкан Кара бик тә — шул затлы нәселдән, Ишмән үзе дә шул нәсел тармагында.

Югарыда телгә алынган Ишмән шәҗәрәсе галим Марсель Әхмәтҗанов китабында Туктар карттан башлана. (Марсель Әхмәтҗанов. Татар шәҗәрәләре. — Казан, 1995. — Б.111.) Ә Шиһабетдин Мәрҗани исә Мәчкәргә күчкән Ишмән нәселен Сөләйман әл-Кирманидән башлый: *«Үз балалары бу заманда нәселләрен «Габдулла бине Габдесәллам бине Хәлил бине Йосыф бине Ишмән бине Туктарга-*

Ф.Бәйрәмова Мәчкәрә зиратында мулла, хаҗи Мөхәммәтҗан байга куелган таш янында

Бүгенге Мәчкәрә авылы

ли бине Көчек бине Тәбеҗ бине Кодеш бине Сөләйман әл-Кирмани» дип билгелиләр», дип яза. (Шиһабетдин Мәрҗани. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. — Казан. 1989. — Б.230.) Мәчкәрәдә табылган һәм хәзер Кукмара музеенда куелган Ишмән шәҗәрәсе дә Сөләйманнан башлана. Аннан — Кол Сөләйман, аннан — Кодаш, аннан — Тәбеҗ, аннан — Көчек, аннан соң Туктаргали китә.

Кайбер галимнәр Ишмән нәселенең башында торган бу Сөләйманнарны Болгардан килгән, дип, кайберәүләр — Алтын Урдадан күчкән, дип бара, Ханкирмәннән, Нократ (Нухрат) авылы якларыннан күчкән, дип тә яза. Минем дә шушы Ханкирмән — Нократ юнәлешен ныклабрак өйрәнәсем килә. Дөрес, Ханкирмәнне күрше Мамадыш районы Кирмән авыллары белән тәңгәлләштерергә тырышучылар да бар. Әмма моңа дәлилләр юк. Бу турыда Шиһабетдин Мәрҗани дә искәртә. «Кукморский край» китабын төзүчеләр дә Ишмән нәселенең Ханкирмән белән бәйлелеге мәсьәләсенә тукталган, әмма моны раслардык архив документлары юклыгын әйткән.

«Высказанное в своё время предположение Ш.Марджани о том, что родоначальники этой фамилии берут свое начало из Ханкирмана (то есть, города Касимова), существует среди современных учёных и сегодня, — дип яза алар. — Однако предположение о том, что древние потомки этого рода в конце XVIII века после распада Касимовского ханства перекочевали в деревню Бурбаш, не подтверждается архивными материалами». (Кукморский край..., Б.155.)

Әйе, тарихи документлардан күренгәнчә, Ишмән нәселенең Бөре елгасы

Бу нәсел шәҗәрәсенә җентекләп тукталуымның сәбәбе – Чыңгыз Айтматовның әнисе Нәгыймә апа да шушы Ишмән нәселеннән була, аның әтисе Хәмзә шушы Мәчкәрә авылында 1840 елларда туа, ул Габделвәлиев фамилиясен йөртә. Шәҗәрәнең зур бер тармагы исә Үтәмешевләр фамилиясе белән дөньяга тарала, алардан да танылган байлар, иганәчеләр, зур галимнәр чыга.

буйларында XVI гасырларда ук яшәве, ә Мәчкәрә тирәсенә 1678 елларга кадәр килеп урнашканлыклары билгеле. Шул ук вакытта, Туктаргали Кәчековның һәм аның бабаларының бик борынгы заманнардан Нократ буйларында, Хлынов өязендә (хәзерге Киров өлкәсе) урман-җирләре булганлыгы да мәгълүм. Бу хакта аларга 1652 елда патша Алексей Михайлович биргән документ сакланган. Биредә борынгы бабаларыннан калган урман-җир мираслары булгач, димәк, Туктаргали балаларының да кариле (Нократ) татарлары белән ниндидер туганлык бәйләнешләре бар?

Үтәмешевләр дә (Ишмән нәселенең зур бер тармагы) чыгышларын Бөрбаш-Мәчкәрә белән генә бәйләп куймыйча, үзләрен Кырым ханнары, нугай морзалары, Чыңгыз хан, Сөембикәләр белән бәйләп карый. *«Современный представитель данного рода — учёный Ильдар Рустамович Утямышев — опираясь на записи своего отца, сообщает о том, что «родовые нити ведут к крымским ханам, имеют общих прадедов с Сююмбике, дочерью ногайского мурзы… и все связаны с потомками Чингизхана»*, — дип яза төбәк тарихын өйрәнүчеләр. (Кукморский край…, С.156.)

Әлбәттә, боларны исбатлау шактый авыр, әмма аларда хаклык та булырга мөмкин. Һәрхәлдә, республикабызның төньягында яшәгән татарларны, шул исәптән Ишмән нәселен дә, Кара бик шәҗәрәсе, кариле татарлары тарихы белән дә бәйләп өйрәнергә кирәктер. Бу хакта галим Марсель Әхмәтҗанов та әйтә: *«Канбар, Кара бик нәселләре Сакмар суы буйларыннан, Нократтагы Карино авылына һәм Чуаштан чигеннән Уфага кадәр булган киң мәйданнарда яшиләр,* — дип яза ул. — *Аларның саны йөзләрчә мең кешегә җитә. Шунлыктан Кара бик нәселенең Идел-Урал буе татарлары этник тарихында урыны зур. Кара бик халкын тәшкил иткән угыз-кыпчак ыруглары, Болгар вилаятендәге исән калган болгарлар белән кушылып, бүгенге Идел-Урал татарларының зур бер компонентын тәшкил итәләр».* (Марсель Әхмәтҗанов. Татар шәҗәрәләре…, Б.26.)

Без бу язмабызда ни өчен Кара бик шәҗәрәсенә, кариле-нократ татарлары тарихына җентекләп тукталабыз соң? Чөнки, безнең уебызча, Кукмара төбәгендә, бигрәк тә аның Мәчкәрә кебек иң төньяк читендә яшәгән татар авыллары тарихына, шул исәптән Ишмән нәселенә дә, кариле-нократ татарларының тәэсире нык булган. Бу инде башкачарак тарих, үзенчәлекле холык һәм мәдәният, саладан бигрәк, кала традицияләрен саклау һәм дәвам итү, гаять тырышлык, генетик яктан, нәселдән килгән лидерлык билгеләре һәм затлылык… Кукмара татарларында боларның барысы да бар.

Тарихчы-галим Дамир Исхаков та нократ татарларына зур бәя бирә: *«Нократ татарларының төп өлешен, үзәк өлешен Алтын Урдадан чыккан татарлар тәшкил иткән,* — дип яза ул. — *Тәгаенрәк тә әйтеп була: алар кыпчак кабиләсеннән чыкканнар. Барысы да затлы татарлар. Казан ханлыгы оешкан вакытта Болгар вилаяте ягыннан Казан тарафына үтеп кереп, Арча даругасында, ягъни өяздә, хөкемдарлар булганнар. Ягъни, хакимиятне кулда тотканнар, бәкләр, хаким катлам булган-*

Мәчкәрәдәге Үтәмешевләр төзеткән Җамигъ мәчете

нар». (Татар милләт календаре, 2003 ел, Б.276.)

Шуларны белгәннән соң, Чыңгыз Айтматовның әнисе ягыннан бабаларының нәкъ менә Кукмара төбәгеннән, Мәчкәрә авылыннан, кариле-нократ татарларының бөтен традицияләрен дәвам иткән Ишмән нәселеннән булуына гаҗәпләнергә кирәкми. Болар — узган меңьеллык башында ук, Болгар дәүләте составында булуларына карамастан, Ар иле дип аталган үз мөстәкыйль җирләрендә яшәп яткан, Алтын Урда составында да чагыштырмача мөстәкыйльлекләрен саклап калган, әле 1361 елда да «Каринское княжество» дип аталган үз биләмәләрендә көн күргән затлы-гайрәтле татарлар. Урыс рәсми чыганакларында аларны «арские князья» дип тә атаганнар. Моны Арча атамасы яки ар-удмуртлар белән генә бәйләп карарга ярамый. Тарихтан күренгәнчә, бары тик 1489 елда гына бу җирләрне Иван III гаскәре яулап ала һәм Кар иле — Ар иле, төньяк татарларының мөстәкыйль иле, көчләп урыс дәүләте составына кертелә. Бу хакта үзе дә шушы якларда — Малмыж каласында туып-үскән тарихчы-галим Михаил Худяков менә нәрсә яза: *«В 1467 г. каринские татары могли составлять прочную опору казанцам при завоевании последними Вятской земли. Они удержали свою автономию вплоть до 1489 года, когда московское войско покорило Вятскую общину. Вместе с нею утратили самостоятельность и каринские татары: князья их были низложены и отвезены пленниками в Москву».* (М.Худяков. Очерки по истории Казанского ханства. — Москва, 1991. — С.21.)

Әлбәттә, кариле татарларының Казан белән бергә яисә Казанга каршы вакытлары да булган. Урыс дәүләтенә Казаннан алда көчләп кертелгәч, аларның сайлап алу мөмкинлеге калмый инде. Ни генә булмасын, алар туган туфрагына, диненә һәм теленә тугры кала, инде ничә гасырлар шушы җирләрдә татар булып, мөселман булып яши, монысы өчен дә зур рәхмәт аларга!

Ахыры киләсе санда ■

МИЛЛИ ДӘҮЛӘТЧЕЛЕК ТУГАНДА...

Рәмзи Вәлиев

Татарның һәр чорда бәйсез дәүләт төзү теләге белән януы – табигый күренеш. Дөньяда милли үзаңы булган һәр милләт тә үзенең дәүләтле булуын һәм үз телендә баласын укытып, үз телендә җырлап, сөйләп яшәүне телидер. Бу – күрше милләтләр өчен дә куркыныч тудырмый, закон бозу да түгел.



Борһан Шәрәф (1883-1942)



Галимҗан Шәрәф (1896-1950). ГУЛАГта, 1937 ел. Рәссамы Хәнәфи Нәфыйков

Безнең мәшһүр бабаларыбыз, шанлы дәүләтләр төзеп, Кытай, Россия кебек дәүләтләргә, гомумән, бөтен дөньяга дәрт һәм көч биреп торган. 500 ел элек югалткан дәүләтчелекне кайтару теләге белән һәр татар гасырлар дәвамында янса да, узган гасырның 1917-1920, 1990 елларында гына моңа күпмедер дәрәҗәдә ирешә.

XX гасыр башында ук Садри Максуди Дәүләт Думасы депутатлары алдында чыгыш ясаганда: *«...Иртәмесоңмы мин барыбер сезнең кебек үк хокукка ия булырмын. Россиядә булган милләтләрнең үз көннәрен үзләре күреп яшәү хокукларын танымый торып, сез дәүләт белән идарә итәрлек хәлдә булмаячаксыз!»* – дип әйтә.

Менә шушы хокук өчен көрәшне башлап җибәрүчеләрнең берсе, Петроград тимер юл инженерлары әзерләү институты студенты Галимҗан Шәрәф була. Ул 1915 елда ук «Татар учагы» дип аталган студентлар оешмасы төзи. Бу оешманың эшчәнлеге турында әлегә бик аз билгеле, әмма анда катнашучыларның исем-фамилияләрен атап чыгу да татарларның, башка мөселман халыкларының милли-азатлык хәрәкәтендәге урыны, роле турында күзалларга мөмкинлек бирә. Галимҗан Шәрәфнең үз сүзләренә караганда, оешма әгъзалары арасында Ильяс һәм Җиһангир Алкиннар, Солтанбәк Мамлиев, Кәрим Сәгыйтов, Габдулла белән Гани Абызовлар һәм башкалар була. Алар түгәрәк утырышларында Явыз Иванның колониаль сәясәте нәтиҗәсендә дәүләтчелекләрен югалткан Русия мөселманнарының милли-мәдәни үсеше мәсьәләләрен тикшерәләр,

кайбер татар зыялыларының пантюркизм һәм панисламизм белән мавыгуларын тәнкыйтьлиләр, мөселман халыклары мәдәниятенә кагылышлы башка мәсьәләләр буенча фикер алышалар. «Татар учагы» әгъзалары Казан, Саратов, Киев, Ростов (Дон буендагы) һәм башка шәһәрләрдәге фикердәшләре белән элемтәләр булдыра.

Февраль һәм Октябрь инкыйлаблары бик күпләр белән бергә Г.Шәрәфнең язмышын да кискен үзгәртеп җибәрә. Ул укуын ташларга мәҗбүр була һәм аны яңа вакыйгалар дулкыны үз эченә бөтереп ала.

Мәгълүм булганча, 1917 елның май аенда Мәскәүдә Бөтенрусия мөселманнарының беренче корылтае җыела. Анда 900 чамасы делегат катнаша. Делегатлар арасында мөселман зыялылары, хәрбиләр һәм руханилар була. Съездда Ә.Цаликов, Г.Ибраһимов, Г.Терегулов, Ф.Туктаров, Ә.Мөхетдинова, Галимҗан, Борһан, Шәһәр Шәрәфләр, М.Бигиев, Г.Исхакый, А.Рәсүлзадә, Ә.Вәлиди, һ.б. катнаша. Корылтайда эшчеләр, крестьяннар, хатын-кызлар тормышы, милли мәдәният мәсьәләләре карала һәм алар буенча тиешле карарлар кабул ителә. Әлеге мәсьәләләрне тикшергәндә Галимҗан Шәрәф тә ялкынлы чыгышлар ясый.

Корылтайда игътибар үзәгендә торган һәм күп бәхәсләр тудырган проблема — Русиядәге дәүләт төзелешенең нинди булырга тиешлеге хакындагы мәсьәлә. Чөнки делегатлар милли төбәкләрдә миллият мәсьәләләренең ничек хәл ителәчәгенең бу проблеманың Русиядә ничек хәл ителүенә бәйле булуын яхшы аңлый. Корылтай күпчелек тавыш белән Русия демократиягә нигезләнгән Федератив республика булырга тиешлеге турында карар кабул итә. Бу исә мөселман сәясәтчеләренең милли мәсьәләнең нәзари һәм гамәли нигезләрен үзәктәге шовинистларга караганда тирәнрәк аңлаганлыкларын күрсәтә, чөнки бу вакытта большевиклар партиясе һәм В.И.Ленин үзе дә бөтен тырышлыкларын унитар дәүләтне саклап калуга юнәлтәләр.

Галимҗан Шәрәф корылтайдагы докладында татарлар өчен «туфраклы мохтарият» (территориальная автономия) кулай булачагына басым ясый. Аның бу фикерен Ф.Кәримов белән Ф.Туктаровлар да хуплый. Корылтайда соңыннан мөселман халыкларының иҗтимагый-сәяси эшчәнлекләре белән идарә итү һәм Вакытлы хөкүмәт белән элемтәдә тору өчен башкарма орган сайлана. Ул Бөтенрусия Мөселман комитеты дип атала.

Галимҗан Шәрәф Татарстанның мөстәкыйль дәүләтчелеге тарафда-



Ильяс Алкин (1895-1937). Студент чагы

Сәетгәрәй Алкин (1867-1919)

ры булса да, милли-мәдәни мохтарият (әгәр дә ул территориаль булса) төзү ихтималыннан да баш тартмый. Шуңа күрә дә аны милли-мәдәни мохтариятне гамәлгә ашырырга тиешле һәйәт составына сайлыйлар. Бу һәйәтнең әгъзалары итеп И.Әхтәмов, Ә.Мөхетдинова, Ф.Кәримов, К.Кәрим, Н.Хәлфин кебек шәхесләр дә сайлана.

Мәскәү һәм Казан съездларыннан соң, ниһаять, 1917 елның 22 ноябрендә Уфада Милли Мәҗлес сессиясе ачыла. Анда килгән 96 депутат арасында Г.Шәрәф тә була. Сессия президиумының рәисе итеп Дәүләт Думасы әгъзасы Садри Максуди, сәркатибе итеп Габдрахман Фәхреддин раслана. Милли Мәҗлес 1918 елның 11 гыйнварына кадәр эшли.

Аның эшчәнлегенең бөекмәмләкәтчеләр теләмәгән юлга кереп китү ихтималын абайлаган Русия Халык Комиссарлары Советы (Совнарком) ул көннәрдә «Бөтен Шәрык һәм Русиянең мөселман хезмәт ияләренә мөрәҗәгать» кабул итә. «Мөрәҗәгать»тә «Мөселман хезмәт ияләре үз тормышларын бернинди ирексезләүләрсез, үзләре теләгәнчә төзи алалар, үз диннәрен тотарга хокуклылар, аларның бу хокуклары инкыйлабның, Советларның бөтен көче белән сакланачак», — диелә. Әлбәттә, документның Милли мәҗлес депутатларына тәэсире зур була. Һәр милләткә үз тормышын үзе теләгәнчә корырга ирек бирү вәгъдә ителгәч, Мәҗлес депутатлары арасында милли дәүләт төзү мәсьәләсенең беренче урынга чыгуы һич тә гаҗәпләнерлек хәл түгел. Бу юнәлештә тәүге адым буларак «Идел-Урал штаты»н төзү игълан ителә. Моңа ирешү өчен «туфракчылар» фракциясе әгъзасы Г.Шәрәф тә шактый көч куя. Ул фракция исеменнән «туфраклы мохтарият» хакында махсус доклад белән чыгыш ясый, булачак җөмһүриятнең атамасын «Идел-Урал» дип расларга тәкъдим итә, җөмһүрият мәйданының картасын төзи. Әлбәттә, бу мәсьәлә шома гына узмый, ике фракция — «төрекчеләр» һәм «туфракчылар» арасында кискен көрәш бара. Шунысын да әйтү кирәктер: большевиклар, сул эсерлар, гомумән, суллар фракциясе «туфракчылар» ягыннан чыгыш ясый. Ниһаять, алар тәкъдиме өстенлек ала. «Идел-Урал штаты»н гамәлгә ашыру буенча Галимҗан Шәрәф рәислегендә махсус һәйәт төзелә, аның составына Галимҗан Ибраһимов, Ильяс Алкин, Сәлах Атнагулов, Фатыйх Сәйфи-Казанлы, Сәет Енгалычев, Нәҗип Хәлфин һәм Фатих Мөхәммәдъяров керә. Аларның барысы да Советлар нигезендә мөстәкыйль җөмһүрият төзү тарафдарлары булалар.

«Идел-Урал штаты»н төзү һәйәте Казанга күчкәч, аның Президиум рәисе итеп И.Алкин, ә урынбасары итеп Г.Шәрәф раслана. Г.Шәрәфнең милли дәүләт төзелеше турындагы фикерләре Милли Мәҗлестә ясаган докладындагыга караганда, соңгы айларда беркадәр үзгәрә. Беренчедән, ул «Идел-Урал штаты»н федерация составындагы мохтариятле җөмһүрият итеп төзергә тәкъдим итә. Икенчедән, хакимият органнары Советлар системасы буенча сайланырга тиешләр, ди. Өченчедән, һәр Совет халыкның милли нисбәтен искә алып сайлануын яклый.

Кызу бәхәсләрдән соң күпчелек тавыш белән Г.Шәрәфнең тәкъдиме кабул ителә. Әмма аның элекке тарафдарлары Г.Шәрәфнең фикерләре үзгәрүне кабул итми һәм Казан белән Уфа матбугатында аңа «гомумхалык сайлаган җыелыш карарларын бозганы өчен» шелтә белдерелү турында хәбәрләр басыла. Шулай да бу вакыйганы Г.Шәрәфнең «Идел-Урал штаты»ннан ваз кичүе, дип бәяләү дөрес түгел. Ул, зирәк сәясәтче буларак, мәҗлестә кабул ителгән карарга вазгыятьнең үзгәрүенә бәйле кайбер үзгәрешләр кертү зарурилыгын аңлап эш иткән булса кирәк.

«Идел-Урал штаты»ның барлыкка килү ихтималы Русия җитәкчеләренең планнарына һич тә сыеша алмый. Милли Мәҗлестән соң «Идел-Урал штаты»н тормышка ашыру эшләрен II Бөтенрусия мөселман хәрбиләре

корылтае вәкилләре дәвам итә. 1918 елның 8 гыйнварында хәзерге Ратуша йортында (элеккеге офицерлар йорты) тантаналы рәвештә икенче съезд башланып китә. Монда большевиклардан Я.С.Шейнкман, М.Солтангалиев, шәһәр башлыгы Иванов, мөселман комитетыннан Ш.Әхмәров, Польша һәм Балтыйк буе төбәкләреннән килгән татарларның вәкилләре, чуаш, чирмеш, мукшы депутатлары, гомумән алганда, барысы да ялкынлы чыгыш ясап, съездны котлыйлар. Ирек мәйданында кызыл, яшел байраклар җилферди, халык тантана итә, тиздән бәйсез «Идел-Урал» булыр, дип өметләнә. Әмма беркадәр вакыт узгач, мәкерле большевиклар «Идел-Урал штаты»н игълан итүгә киртә кора. Болар барысы да астыртын рәвештә эшләнелә һәм нәтиҗәдә 28 февральнең төнендә съезд җитәкчеләреннән Ильяс һәм Җиһангир Алкиннар, Усман Токумбәтов, Мозаффаровлар кулга алына.

Ул вакытта килеп туган авыр хәлне аңлау өчен, әлеге вакыйгаларның нәкъ уртасында булып, соңыннан алар хакында истәлекләр язып калдырган Мирсәет Солтангалиев язмаларына игътибар итик. II Бөтенрусия мөселман хәрбиләре съезды җитәкчеләре кулга алынуны тулысынча хуплап, М.Солтангалиев Совет хакимиятенең бу гамәлен болай аңлата: *«Съезд җитәкчеләре «Идел-Урал штаты» төзелү турында белдерергә карар иттеләр. Большевикларның Казан губерна комитеты яшерен киңәшмәсе җыелды. Анда мин һәм иптәш Сәетгалиев тә катнашты. «Нәрсә эшләргә?» дигән сорау куелды. Киңәшмәдә иптәш Шейнкман рәислек итте. Иптәш Сәетгалиев аларга республика төзелүне «игълан итәргә» мөмкинлек бирү ягында торды. Чөнки аның фикеренчә, бу кешеләр барыбер власть, җитәкчелек эшләрен башкара алмаячак. Мин киресенчә уйладым. Төгәл итеп әйткәндә, әгәр без «штат төзүне игълан итәргә» мөмкинлек бирсәк, аннары инде аны «төзәтергә» соң булачак, дидем. Мин түбәндәге фикерләрдән чыгып эш иттем: а) Татар дәүләтен игълан итү татар халкында милләтчеләр файдасына кискен борылыш ясавы мөмкин; б) без ул вакытта кораллы конфликт юлына баса алмый идек, безнең (ягъни Советларның – Р.В.) Казанда кораллы көчләребез юк иде диярлек, ә «Хәрби Шура» татар солдатларының санын Казанда гына да 60-80 меңгә кадәр җиткерә ала иде. Менә шуңа күрә дә инде мин милләтчеләр тарафыннан «штатны» игълан иттермәскә һәм алдан кисәтү чарасы итеп хәрәкәтнең җитәкчеләрен кулга алуны тәкъдим иттем».*

Большевиклар җитәкчелегендәге Совет хакимияте четерекле милли-сәяси мәсьәләләрне көч куллану юлы белән хәл итүне кулайрак күргән. Кызганычка ки, Солтангалиев кебек талантлы «милли большевиклар» да үз милләттәшләренә карата башлыча шундый ук чаралар күрүне хуплаган.

Большевиклар башка методларны да актив рәвештә куллана. Авыр хәлдә калгач, хәйлә юлына басып, «Идел-Урал штаты»н Советларга бәйләп игълан итәргә мәҗбүр булганлыгын күрәбез. Казан губерна Советы тарафыннан кабул ителгән карарга игътибар итик: *«Совет Урал-Идел өлкә республикасын оештыруга ашыгыч чаралар күрә, бу республика милли-пропорциональ (сыйнфый) нигездә Халык Комиссарлары Советы җитәкчелегендә оештырыла. Президиумга Уфа һәм Оренбург советлары белән Идел-Урал республикасын ашыгыч рәвештә игълан итү мәсьәләсе буенча бәйләнешкә керүне йөкләргә»*. Башка партияләрнең, демократиянең идеяләрен урлау большевикларга бернигә дә тормый. Бу аларга хас күренеш. Гомумән алганда, «Идел-Урал»га бары тик «Советская» (һәм «республика») сүзен генә өстәп, хәтта унбер кешедән торган яңа коллегия дә төзелә, әмма болар барысы да Милләт Мәҗлесен, «Идел-Урал» һәйәтен искә алмыйча эшләнә.

Дәвамы бар ■

БОЛГАРДА – АК КУНАКХАНӘ

Болгар тыюлыгында кунакханә комплексына нигез ташы салынды. Шул рәвешле, республикада туризмны үстерүгә тагын бер адым ясалды. 27 апрель көнне Татарстан Президенты вазифасын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов һәм республиканың Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев Болгар шәһәрчегендә 300 урынга исәпләнгән кунакханә комплексына нигез салу чарасында катнашты. Әлеге кунакханә шунда ук булган Ак пулатны хәтерләтеп торачак. Бу бина ерак гасырлар элек тә иң изге урыннарның берсе булып саналган.

«Яңарыш» фонды проекты буенча Болгар һәм Зөядә 49 тарихи ядкяребез яңартылды һәм төзелде. Узган ел исә ЮНЕСКО Бөтендөнья мирас комитеты карары нигезендә Болгар тарихи-археология комплексы Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелде. Президент вазифасын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов бу вакыйганы күптән көтелгән һәм зур кыйммәткә ия җиңү, дип бәяләде.

Соңгы биш ел эчендә республикага, шул исәптән Болгарга

М.Бадыйкшин фотолары

килүче туристлар саны бермә-бер артты. Әйтик, 2014 елда бирегә 285 мең кеше килгән, шуларның ике меңе — чит ил туристлары. Яңа кунакханә төзелү исә аларның санын арттыруга, ягъни Татарстанда туризмны үстерүдә янә бер адым булачак. Комплекс территориясендә җәяүлеләр зонасы, велосипедта йөрүчеләр өчен юллар, балалар мәйданчыгы һәм мунча комплексы урын алачак. Шунда ук 220 машинаны кую урыны да булыр, дип уйланыла. ■

ТӨРКИ ДӨНЬЯ ҺӘМ ДӨНЬЯГА КАРАШ

Рафаэль Мөхәммәтдинов,
Бөтендөнья төрки халыклар ассамблеясының Координацион советы әгъзасы, тарих фәннәре кандидаты

V. ТАБИГАТЬНЕ КАЙГЫРТУЧАНЛЫК

Төрки халыкларда кешенең җәмгыятькә, табигатькә карата мөнәсәбәте нинди булырга тиешлеге хакындагы карашларга күз салганда, без аларда башкалардан аерылып торган бер үзенчәлекне күрәбез. Әгәр кайбер халыклар үзләрен Алланың колы дип игълан иткән, ә башкалары үз түрәләренең колы булырга ризалашкан булса, төрки халыклар исә һичкайчан үз милләттәшләрен кол хәлендә калдырмаган. Үзләрен күкнең (яисә кояшның, галәмнең, ә ахыргы чиктә галиҗәнап Табигатьнең) уллары итеп санаганнар. Шуңа күрә алар табигатькә карата бик мәрхәмәтле булган, аның белән килешеп яшәргә тырышкан. Чыңгыз ханның «Яса» дигән кануннар җыелмасына гына күз төшерсәк тә, анда табигатькә зарар китергән иң вак гамәлләр өчен дә үлем җәзасы бирелгәнлеген күрәбез. Табигатьнең арулыгы төркиләрдә бер культ хәленә әйләнгән. Алар үзләрен табигатьнең патшасы яки колы итеп түгел, ә табигый бер өлеше итеп санаган.

*Ахыры. Башы 4 нче санда.

VI. ТАБИГАТЬ ЭСТЕТИКАСЫ

Төркиләрдә табигатькә олы ихтирам, хөрмәт тереклек дөньясына соклану, аның матурлыгына карап эстетик ләззәт табу гадәте бар. Моңа японнарның сакура (япон чиясе) чәчәкләренә сокланулары һәм алардагы экибана (чәчәк бәйләмнәрен ясау) сәнгате охшаш. Эш шунда ки, килеп чыгышлары буенча японнар төркиләрнең борынгы кардәше. Төрки, монгол, маньчжур, корея, япон телләре алтай теле гаиләсенә керә. Төркиләрдә исә табигатькә соклану шигъриятә тирән эз калдырган.

VII. АТА-БАБАГА ХӨРМӘТ ҺӘМ ВАТАННЫ ЯРАТУ

Төрки халыкларның дөньяга карашында тагын бер үзенчәлек — алардагы Ватанны ярату хисе. Моның турында Орхон-Енисей ташъязмалары сөйли. Төркиләр карашынча «җир-су» төшенчәсе бербөтен, «ватан» сүзенә мәгънәдәш. Ватанга, туган җиргә булган сөю, мәхәббәт хисе борынгы төркиләрдә культ хәлендә. Җир катламының илаһы «Удук (Изге) Җир-Су» булган. Бу культ тау, күл, елгаларга табыну белән бәйле.

Ата-бабага һәм Ватанга булган хөрмәт, ихтирам, ярату хисе төркиләрнең сәяси фикеренә, һичшиксез, йогынты ясаган. Аларда инсан бакый дөньяга күчкәннән соң аның берен, өчен һәм кырыгын уздыру гадәте дә ата-бабаларга хөрмәт һәм ихтирам билгесе. Бу гадәтләр төркиләрдә ватанпәрвәрлекне тәрбияләргә һәм үз тарихларын, аеруча борынгы заманны белергә, өйрәнергә, аның белән горурланырга этәргеч тудырган.

Бу тема хәзер аеруча мөһим. Чөнки тарих фәнендә киң таралган аурупамәркәзи карашларны яклаучы галимнәр төркиләрне яшь, варвар, бары тик күчмә бер халык итеп кенә күрсәтәләр иде. Соңгы елларда бу стереотип бераз какшаган булса да, аны тулысынча фаш итәр өчен безгә әле күп эшлисе бар. Борынгы төрки мәдәниятен дөньяда тәүге цивилизация буларак танылган Шумердан да алданрак барлыкка килгәнлеген тану заманы инде җиткәндер. Төркиләр шумер халкының формалашуына турыдан-туры катнашкан. Моны бай тел материаллары исбатлый.

VIII. СОЦИАЛЬ ГАДЕЛЛЕК ҺӘМ ТӨРКИ ХАЛЫКЛАРДА ҖӘМГЫЯТЬНЕ ҮСТЕРҮ ЮЛЛАРЫ

Төрки халыкларның дәүләт төзелеше, түрәләр һәм халык арасындагы мөнәсәбәт, социаль гаделлек турындагы карашлары да борынгы чорга барып тоташа. Без Төрки каганлык дәверендә (VI-VII гасырлар) куелган кабер ташларындагы язмалардан шул чорның иҗтимагый тормышы турында фикер йөртә алабыз. Хакимият башында каган торган, каган хакимияте аның кардәшенә мирас итеп тапшырылган, ләкин хакимиятнең көчеше бәкләр тарафыннан корылтайда расланган. Бәкләрдән түбәнрәк социаль катлам — «будун» (кара халык). Төркиләрдә коллар да булган, ләкин аларның күп өлешен нигездә чит илдән китерелгән әсирләр тәшкил иткән.

Каганның вазифалары:

1) дәүләтне яклау һәм киңәйтү; 2) дәүләт һәм халыкның мул тормышын тәэмин итү; 3) дәүләтнең бөеклеген ныгыту һәм данын арттыру.

Каганның төп сыйфатлары:

1) зирәклек; 2) кыюлык; 3) тугрылык.

Дәүләттә яшәгән кешеләрнең сыйфатлары:

1) итагатьлелек; 2) башкаручанлык;

3) каган һәм түрәләр оештырган бөтен эшләрдә һәм сугыш сәфәрләрендә тәртипне саклап эш итү.

Төрки дәүләтнең каганы үз белдеге белән генә эш итмәгән, ул бәкләр белән киңәшләшеп һәм «төрә»гә (ата-баба гадәтләренә) таянып гамәл кылган. Бу кагыйдәләрне бозган очракта бәкләр аны корылтайда үз вазифасыннан азат итә һәм башка каганны сайлап куя алган.

Төркиләрдә җәмгыятьнең әлеге моделе бүген дә гамәлдә, дип әйтергә була. Ләкин хәзер «бәкләр»гә депутатлар яисә министрлар, ә каганга — президент, дип әйтәләр, ягъни яңа атамалар кертелсә дә, асылы шул ук калды.

Җәмгыятьтә социаль катламнарга аерылу борынгы заманнан ук килә. Мәсәлән, каганлыкта 100000 сарыкка һәм 10000 атка ия гаиләләр булган. Ләкин төрки җәмгыятьтә үсешкә ирешү, карьера ясар өчен төрле социаль механизмнар яхшы эшләгән, күрәсең. Мәсәлән, «бәк» дәрәҗәсе гомерлеккә бирелмәгән һәм мирас итеп балага күчмәгән. «Бәк» титулы кешенең сугышта катнашканы яисә дәүләтнең идарә системасында уңышлы эшләгәне өчен бирелгән. Шулай итеп, кеше үзенең шәхси сәләте белән дә икътисади уңышка, мал-мөлкәткә ирешкән. Мәсәлән, ятим бер малай, яшьтән үк каганга хезмәт итеп, утыз яшенә җиткәч, аның милке 10000 атка җиткән, һәм ул идарә системасында да зур дәрәҗәгә ирешкән.

Төрки элитага (түрәләргә), аеруча каганга халыкның язмышы һәм мул тормышы өчен җаваплылыкны аңлау һәм тою хас. Күлтәгиннең абыйсы булган каган болай әйтә (Күлтәгин кабер ташындагы язмасыннан бер өзек): *«Халкым өчен төннәрен йокламадым,*

көндез дә эшсез утырмадым. Кардәшем Күлтәгин белән берлектә хәлдән тайганчы сугышларда катнаштым. Үлемгә барып җиткән халыкны мин торгыздым, киеме тузып беткән халыкка кием бирдем, ярлы халыкны бай иттем, аз санлы халыкны күп санлы иттем!»

Төркиләр үз заманында Һун империясе, Төрки каганлык, Чыңгыз хан империясе кебек дөньядагы иң зур дәүләтләрне корган. Әлеге дәүләтләрдә билгеле бер социаль гаделлек һәм социаль хәрәкәт механизмнары булган.

Социаль гаделлек принцибы бүген дә төркиләр өчен көн үзәгендә. Ул аларның дөньяга карашы һәм идеологиясенең аерылмас бер өлеше.

Соңгы дәвер тоталитар социализмы, олигархик капитализмнең тоталь монополиясе дә төркиләр тарафыннан кабул ителмәде. Хәзерге заманда төрки халыкларга халык капитализмы юнәлешендә үсеш кулайрак булыр иде. Халык капитализмы модельләренең берсе казакъ академигы, Бөтендөнья төрки халыклар ассамблеясы (БТХА) президенты Ерментай Солтанморатовның «Дөньяны төптән үзгәртү» («Трансформация мира», Алматы, 2002) китабында күрсәтелгән. Бу модель буенча сәнәгать оешмасының эшчеләре оешманың акцияләренә ия була. Шул сәбәпле алар бу сәнәгать оешмасының бер үк вакытта эшчеләре дә һәм милек хуҗалары да булып санала. Хәзер без бу модельне төрки халыкларның социаль үсеше юлы дип атыйбыз.

Бу модельгә таянып, Казакъстан президенты Нурсолтан Назарбаев үзенең «Гомуми хезмәт җәмгыяте» («Общество всеобщего труда») дигән идеясен халыкка тәкъдим итте. Шул ук тема буенча күренекле татар һәм Россия галиме, академик, милек һәм милләтара мөнәсәбәтләр фәлсәфәсе белгече Борһанов Әгъдәс Хөсәен улы да тирән фәлсәфи фикерләргә таянып күп әсәрләр язды. Әсәрләрендә ул, кеше милеккә ия булган очракта гына иреклe һәм мөстәкыйль була ала, дигән идеяне алга сөрә. Галим, халыкның үсеше һәм мул тормышы олигархик монополистлар капитализмында түгел, ә ярышып-узышып эшләүче милек ияләренең киң, урта катламы булганда гына барлыкка килә ала, дигән фикерне раслый. Аның Россияне аптыраштан (тупиктан) коткару өчен дә үз концепциясе бар. Шулай ук ул Татарстан өчен дә милли идеяне тәкъдим итте (Карагыз: Борһанов Әгъдәс. Милек фәлсәфәсе, 2 нче басма, Казан, 2002).

***

Җыеп әйткәндә, нәрсәдән гыйбарәт соң төркиләрнең дөньяга карашы? Тормышның һәм белемнең төрле өлкәләрендә аларның дөньяга карашы билгеле бер төп идеяләр рәвешендә чагылыш тапкан.

I. Онтология (булулык, яшәеш турындагы белем) өлкәсендә:

1) бөтен барлык (бытие) бердәнбер чыганактан (галәмгә кадәрге чуалчыклыктан, ягъни хаостан) туган; 2) бу чыганак (хаос) гомоген (бертөрле) матдәдән — судан торган; 3) бөтен әйберләр һәм вакыйгаларның эчке каршылыгы бар һәм бу — табигый хәл.

II. Социаль тормыш өлкәсендә:

1) табигатькә кайгыртучан мөнәсәбәт, аның белән килешеп, аңа җайлашып яшәү; 2) табигатьне данлау, аңа мәдхия уку; 3) ата-бабага хөрмәт, ватанпәрвәрлек, үз тарихың белән горурлану; 4) социаль гаделлек, идарә итүче түрәләрнең (элитаның) халык һәм дәүләт каршында җаваплылыгы.

Төркиләрнең дөньяга караш нигезләре меңнәрчә еллар дәвамында формалашкан. Бу нигезләрнең, үзенчәлекле карашлар һәм идеяләрнең тамырлары иң борынгы төрки халыкларга барып тоташа. Шул ук вакытта алар бүгенге төрки җәмгыятьләр өчен дә заманча һәм актуаль, халыкара кыйммәтләр системасына да яхшы туры киләләр. Мин, төрки дәүләтләрдә дөньяга бу карашның нигезләре җирле материаллар белән баетылып, социаль белемнәр буенча дәреслекләр һәм милли идеология концепцияләре язганда да кулланылыр, дип өмет итәм. ■

КҮҢЕЛГӘ ЯКЫН ТӨРКИЯ...

Сөмбел Таишева

Май аенда Казанда төрки дөнья журналистларының II корылтае узачак. Моннан нәкъ ун ел элек Татарстаннан бер төркем журналист һәм мөхәррирләр Истамбул һәм Анкара шәһәрләрендә төрек телендә эшләп килүче гаммәви мәгълүмат чаралары белән җентекләп танышкан иде.

ПУШКИН ШИГЫРЕНӘ ГАШЫЙК КОНСУЛ

2004 елда Төркиянең Татарстан Республикасындагы Генераль Консуллыгын Исмаил Хаккы Муса җитәкли башлады. Ул — профессиональ дипломат. Казанга килгәнче Төркиянең Аурупа Берлеге каршындагы Вәкиллегендә даими киңәшче булып торган. Моннан унбер ел элек Казан үзенең олуг бәйрәмен — меңьеллыгын каршыларга әзерләнә иде. Күп кенә төрек компанияләре, эшкуарлары һәм төзүчеләре башкалабызда эшли. Алар Кол Шәриф мәчетен, «Пирамида» мәдәни-күңел ачу комплексын төзүдә һәм башка төзелешләрдә, шулай ук Кремль китапханәсен, Муса Җәлил исемендәге Опера һәм балет театрын, Казан университетын төзекләндерү вә ямьләндерүдә актив катнашты.

«ТАТМЕДИА» агентлыгында оештырылган матбугат конференциясендә дә сүз әнә шул хакта барды. Төп кунагыбыз исә Исмаил Хаккы Муса иде. Июль аеның ул мәртәбәле көне әле бүген дә хәтеремдә саклана. Төрек дипломаты тәбрикләү сүзен бөек Пушкинның шигырьләрен русча яттан сөйләп башлап җибәрде. Исмаил бәй белән мин моннан берничә генә көн элгәре танышкан идем. «ТАТМЕДИА» җитәкчесе урынбасары буларак, матбугат вә мәгълүмати оешмалар белән очрашулар, халыкара хезмәттәшлек өчен җаваплы идем. Шулвакыттан бирле без Академическая урамында урнашкан «ТАТМЕДИА» офисында, яисә ул чактагы Казан санаториесы бинасында тыйнак кына урын биләгән Төркия Республикасы Консуллыгында еш очраша идек. Бүгенге көндә исә Консуллык бинасы гаҗәеп күркәм, тарихи урында — күренекле дәүләт эшлеклесе һәм мәшһүр шагыйрь Гавриил Державин хөрмәтенә куелган һәйкәл каршында — юл аша гына тора. Консул белән безнең арада дуслык мөнәсәбәтләре урнашты. Исмаил Хаккы Мусаның гаиләсе Франциядә яши, ул үзе дә француз телен бик яхшы белә. Миңа, чит телләр факультетын тәмамлап, француз телен һәм әдәбиятын махсус өйрәнгәнлектән, аның белән шушы телдә аралашу үзе бер рәхәтлек бирә иде.

Дәүләт бәйрәмнәрендә, тантаналарында да һәрдаим очрашып тордык. Төркия Республикасы көне аеруча истә калган. Безне — журналистларны — иң кадерле кунак сыйфатында кабул иттеләр. Шәрык нигъмәтләреннән бөркелгән гаҗәеп тәмле исләр, мөгаен, кечкенә Швейцариянең (Консуллык урнашкан бу урынны элек шулай атап йөрткәннәр) һәммә ягына да таралгандыр… Хуҗабыз Исмаил бәй исә Ватаны — Төркия хакында сөйли. Йотлыгып тыңлыйбыз. Бераздан безнекеләр дә Истамбулда, Анкарада, яисә Ак

Сулдан уңга: Сөмбел Таишева, Исмаил Хаккы Муса (бүгенге көндә – Төркия Республикасының тышкы эшләр министры), Марат Моратов һәм Фәрит Шаһиәхмәтов. Казан, 2005 ел

Төркиядә «Анадолу» хәбәрләр агентлыгы җитәкчеләре хозурында

диңгез буйларындагы сәфәрләрдә алган тәэсирләре белән уртаклаша башлады. Генераль консулның зәвык белән җиһазланган кабинетындагы затлы китапларын караштырганда ул минем яныма килде, тәэсирләремне сорады. Пәхләвә, рәхәт-лукум һәм ширбәт телләребезне дә балландырган иде, мин, кыюсызлыгымны да онытып, ни кызганыч, әле моңа кадәр Истамбулда булырга туры килмәгәнемне әйттем.

— Берничә журналистны Истамбулга сәфәргә оештырып җибәрик, алайса! — диде ул.

ЯҢАЛЫК «КҮГӘРЧЕННӘРЕ»

Янә берничә айдан, төгәлрәге, 2005 елның гыйнвар азагында безнең журналистлар төркеме Төркия җиренә аяк басты. Ике атна дәвамында без илнең ике төп каласында — Истамбулда һәм Анкарада булдык. Без дигәнем — «Казанские ведомости» газетасының баш мөхәррире Венера Якупова, «Татарстан яшьләре»нең баш мөхәррире Исмәгыйль Шәрәфиев, «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгының директоры (бүгенге көндә «Бизнес он-

лайн» электрон газетасын җитәкли) Рәшит Галләмов, Түбән Кама телерадиокомпаниясе директоры Айдар Сәлимгәрәев, Чаллы телерадиокомпаниясе директоры Хәбибрахман Шәфигуллин һәм мин — делегация җитәкчесе. Сәфәребезнең максаты — Төркиянең гаммәви мәгълүмат чаралары эшчәнлеге белән якыннан танышу.

Тормышта тәүге тапкыр күргән һәрнәрсә, беренче мәхәббәт шикелле үк, гомерлеккә истә калучан, диләр. Безне дә, бактың исә, әнә шундый мәхәббәт көткән икән биредә. Төркиягә мәхәббәт! Һава аланыннан (аэропорттан ягъни) безне туп-туры кафега алып киттеләр. Төрле нигъмәтләрдән, тәмтомнан өстәлләр сыгылып тора! Әмма дә безне иң әсәрләндергәне бинииһая зур ләвәш һәм аңа мәк орлыкларын тезеп язган «Татарстан» сүзе булды. Чын-асыл мәгънәсендә кардәшлек мәхәббәте билгесе иде бу!

Сәфәребез вакытындагы иң әһәмиятле очрашу Дәүләт министры Бәшир Аталай белән булды, дип исәплим. Вәләкин әле бу очрашуга кадәр үк безгә Төркиянең гаммәви мәгълүмат чаралары (ГМЧ) — «TRT», «ATB», «CNN TURK», «SKY TURK» телерадиокомпанияләре, «Заман» газетасы, «Анадолу» һәм «Җиһан Нәбәр» мәгълүмат агентлыкларына барып, аларның тарихы белән танышып, төрек медиа системасын «эченнән» өйрәнү мөмкинлеге тудырылды. Иң әүвәл Төркия Республикасының матбугат һәм мәгълүмат буенча Баш идарәсе генераль директоры Габдрахман Билгич бу эштә безгә хәерхаһлык күрсәтте. Баш идарә статусы буенча бездәге мәгълүмат министрлыгы дәрәҗәсенә тәңгәл һәм ГМЧ белән җитәкчелек итүче Дәүләт министрына турыдан-туры буйсына. Нәкъ менә шушы, биш мең хезмәткәрне берләштерүче идарә, безнең эшлекле сәфәрне оештырды да инде. Төркия хакында ил эчендә һәм дә бөтен дөньяга мәгълүмат тарату — идарә алдына куелган төп бурыч әнә шул.

ГМЧ эшчәнлеген оештыруда берничә оешма катнаша. ГМЧ өчен хөку-

мәт грантлары каралмаган. Әмма дә милли мәгълүмат чараларына иҗтимагый оешмалар ярдәм итә ала.

Радио һәм телевидение буенча мөстәкыйль Югары Совет телерадиокомпанияләрне теркәү белән шөгыльләнә. Әлеге Совет ил парламенты карары белән булдырылган. Безгә, әлбәттә, хөкүмәтнең ГМЧ эшчәнлегенә тыкшынмау сәясәте алып баруын кат-кат әйттеләр. Төркиядәге ГМЧ, Конституция буенча, бәйсезлеккә ия. Цензура тыелган. Вәләкин, кайбер телевидение журналистлары әйтүенә караганда, рәсми булмаган цензура телевидение өлкәсендә, өлешчә булса да, барыбер бар икән. «Сез, әлбәттә, хупланмаган материалны тапшыруга бирә аласыз, ләкин алга таба сезнең өчен һәммә ишекләр дә ябылачак», — дип аңлатты алар.

Бүгенге көндә Татарстанда «ТАТМЕДИА» АҖ карамагында йөзгә якын ГМЧ эшләп килә. Дәүләт «Яңа гасыр» каналын да яртылаш финанслый. Төркиядә исә ике ГМЧ гына дәүләттән матди ярдәм ала. Болар — «TRT» дип аталучы бик зур милли телерадиокомпания һәм акционерлык җәмгыяте рәвешендә эшләп килүче «Анадолу» дәүләт мәгълүмат агентлыгы. Соңрак мәгълүм булганча, дәүләт әлеге агентлык акцияләренең контроль пакетына ия булып тора икән.

«Анадолу» агентлыгының гасырга якын тарихы бар. 1920 елда Анкарада Төркиянең Бөек милли җыены уздырыла һәм анда милли хөкүмәт оеша. Бер елдан соң, 13 октябрьдә Анкара башкала дип игълан ителә. Шул ук елның 6 апрелендә, милли азатлык көрәше вакытында, Мостафа Кәмал Ататөрек мәгълүмат һәм идеологиянең биниһая зур көчен бик яхшы чамалаган, әлбәттә. Ул чакта да, хәзер дә агентлыкның төп максаты — ил һәм дөнья күләмендә Төркия Республикасы хакында мәгълүмат тарату. Быел безнең беренче мәгълүмат агентлыгыбыз «Татар-информ» 25 яшен тутырса, «Анадолу» исә 95 яшьлеген бәйрәм итә. Халыкара электрон челтәрләр өлкәсендә Төркиядә аерым агентлык — «Рейтер» эш йөртә.

«Анадолу»ны барып күрү, җитәкчелек һәм журналистлар белән очрашу, аралашу һәммәбезнең дә күңеленә хуш килде.

Без еш кына: «дәүләти мәгълүмат чаралары үз-үзен акламый, табыш китерми», — дигән фикерләр ишетәбез.

Төркия журналистлары берлеге вәкилләре

Ә менә «Анадолу» мәгълүмат агентлыгы, көн саен дөньяга 700 яңалык «күгәрчене» очырып, елына 25 миллион доллар табыш ала. Үзара хезмәттәшлек формасы да бик камил эшләнгән: хөкүмәт мәгълүматка заказ бирә, әгәр дә хәбәр кызыклы һәм сыйфатлы икән, аны сатып ала. «Анадолу» — илнең иң эре биш мәгълүмат агентлыгының берсе.

ВЕЛОСИПЕДЛАРДА КИЛҮЧЕ «ЗАМАН»

Моннан ун ел элек Төркиядә байтак кына мәгълүмат агентлыклары эшли иде: «Хөррият», «Миллият», «Ихлас», Икътисади яңалыклар агентлыгы, Күңел ачу һәм актуаль яңалыклар агентлыгы. Без «Хәбәр» агентлыгы (Cihan Haber Agency) белән дә таныштык. Ул «Заман» газетасы белән бергә уртак холдингта эш алып бара. Әле ул елларда ук үсеш вә алгарыш җәһәтеннән бу агентлык бездәгеләрдән ике адымга алда бара иде. Агентлык видеосюжетлар белән аралаштырылган мәгълүмати яңалыклар, текстсыз фотосурәтләр тәкъдим итә. Аларда илнең һәммә ГМЧ вәкилләре белән хезмәттәшлек итү җайга салынган. Утыз интернет-сайт, чит илләрдәге Reuters, BBC телевизион каналлары белән дә элемтә булдырганнар. Боларының телевизион төркемнәре исә даими рәвештә Әфганстанда, Казакъстанда, Багдадта, Керкукта, Лондонда, Франктфуркт-Майнда даими эшли. Бу хакта безгә көндәлек «Заман» газетасында очрашу вакытында Мәхмәт бәй Камыш сөйләде. «Заман», «Хөррият», «Милләт», «Төркия», «Сабах», «Мәйдан», инглиз телендәге «Тюркиш Дейли Ньюс» — илдәге иң йогынтылы матбугат чаралары. 18 ел нәшер ителүче «Заман»ның ул вакытта 510 мең укучысы бар иде. Абунәдән кергән табыш — өч миллион ярым доллар. Еллык абунә — җиде доллар. Мөхәррирләребез сорау арты сорауны яудырып кына торды. Абунәчене яулап алу бер хәл, тиражны да даими саклый алырга кирәк бит әле! 90 нчы елларда үзебезнең «Сөембикә», «Чаян», «Идел» журналлары йөзәр мең данәдә нәшер ителде. Ә хәзер?! «Заман»ның зур тираж җыюдагы бер шарты — илдәге 700 журналист, шулай ук Нью-Йорктагы, Лондондагы, Мәскәүдәге, Чикагодагы махсус хәбәрчеләр газета өчен сыйфатлы контент тудыра. Икенче шарты

— «Заман», «Вакыт» газетасы белән берлектә, альтернатив язылу системасын булдырган, һәр абунәчесен белеп тора. «Бездә һәркөнне ике мең кеше «Заман»ны туп-туры өйгә яисә офиска китерә! — ди алар, — күбесе — велосипедларда».

ЖУРНАЛИСТЛАР БЕРЛЕГЕ

Профессионал журналистларга BASIN карточкасы бирелә. Бездәге «Пресса» таныклыгы кебегрәк. Аны унөч кешедән торган Матбугат буенча комиссия (күбесе — журналистлар берлеге әгъзалары) тапшыра. Төркиядә иң беренче (1860 елда) нәшер ителгән газета — «Тәрҗуман-и Әхвәл». Бүгенге көндә илдә тугыз меңнән артык журналист газеталарда эшли. Профессионал Берлекләре 1946 елда оеша. 3200 әгъзасы бар. Төркиядә яһүд, итальян, грек, әрмән телләрендә дә чыгучы газеталар бар. ГМЧның тулаем табышы — алты йөз миллион долларга якын. Әмма дә соңгы елларда Берлекнең матди хәле шактый ук кыенлашты, диләр әңгәмәдәшләребез. Пенсиягә чыгу тәртипләре дә үзгәргән. Элек ир-ат — 20, ә хатын-кыз 18 ел матбугатта эшләп лаеклы ялга чыга алган, хәзер исә — фәкать гомуми пенсия яшенә җиткәч кенә...

КҮПТАРМАКЛЫ TRT

Төркиядә радио — 1927 елдан, ә телевидение 1952 елдан эшли башлый.

2005 елда илдә 16 хосусый телекомпания бар иде. Иң зур милли телерадиокомпанияләре — TRT — 1964 елда ачыла. Анкарада без аның җитәкчесе Мостафа Демирбашы белән дә очраштык. Программаларны бер ел алдан әзерләп куялар икән. TRT үзе 7 каналдан тора: TRT-1 — гаилә каналы, TRT-2 — яңалыклар каналы, тәүлек дәвамында эшли. TRT-3 — спорт каналы. TRT-4 Төркия парламенты утырышларын тапшыра. Мәгарифкә багышланган канал да бар. TRT INT чит илләрдә яшәүче ватандашларга, ә TRT TURK исә Үзәк Азия һәм Кавказ мәмләкәтләренә юнәлеш тота. TRTның Тышкы яңалыклар департаменты 26 телдә, шул исәптән татарча да, яңалыклар әзерли. Тапшырулар бөтен дөньяга тарала.

TRT карамагында 4 илкүләм һәм 8 төбәкара радиостанция эшләп килә.

ДӘҮЛӘТ МИНИСТРЫ БЕЛӘН ОЧРАШУ

Төркия Республикасының Дәүләт министры Бәшир Аталай белән очрашуыбыз эшлекле сәфәребезнең чын мәгънәсендә таҗы булды.

Бәшир Аталай Төрки Бердәмлек һәм Үсеш Идарәсе (TIKA), Төркиянең радио һәм телевидение комитеты (TRT), радио һәм телевидение Югары советы (RTUK), Дәүләт статистика институты (DIE) эшчәнлеге өчен җавап бирә, аның вазифасы вице-премьер статусына тиң. Узган ел Казанда төрки әдәби журналларының Форумына бөтен дөньядан баш мөхәррирләр җыелган иде. Аларның сәфәренә әнә шул TIKA матди ярдәм күрсәтте.

Бәшир Аталай белән очрашу вакытында Төркия һәм Россия арасындагы мөнәсәбәтләр, мәгълүмат чараларының юнәлеше, әһәмияте хакында да сөйләштек. Дөньякүләм мәсьәләләр дә читтә калмады.

Саубуллашканда үзара сувенирлар алыштык. Кулына китап тоткан чалмалы татар аксакалы белән нечкә билле биюче татар кызының фарфор сыннары бүләкләр музее киштәсендә әле дә сакланадыр. Ә менә алтынсу бизәкләр белән бизәлгән төрек тәлинкәсе элгәрege җитәкчебезнең шкафында берничә ел дәвамында балкып торды.

СОЙ — ТАМЫР!

Узган ел Казаныбыз төрки дөньяның мәдәни башкаласы дип игълан ителгән иде. «ТӨРКСОЙ» атамасындагы соңгы иҗекнең ни аңлатканын да, ниһаять, бик күпләр белә башлады. Сой — төрекчә тамыр дигән сүзне аңлата. Бик тә мәгънәле сүз!

Төрки милләтләр мәдәниятен һәм сәнгатен үстерү белән шөгыльләнүче «ТӨРКСОЙ» оешмасының штаб-фатирында да булырга туры килде. Безне департамент башлыгы Сәрдәр Эрдем, төрки сәнгать һәм мәдәният буенча администратор Мәхмәт Окутан һәм вәкилебез Лилия Саттарова каршы алды. Оешмада 14 ил әгъза булып тора, дивар буенча аларның әләмнәре эленгән.

Бюджет әгъза илләр керткән акчага һәм Төркия Республикасының Мәдәният һәм туризм министрлыгының саллы матди ярдәме белән тулылана.

Истамбулда булган янә бер күркәм очрашу күңелдә саклана. Татарстанның Төркиядәге Вәкиллегендә булды бу очрашу. Ул чакта биредә Радик Гыйматдинов эшли иде. Бүгенге көндә ул — Татарстан Республикасы Президенты вазифаларын башкаручы Рөстәм Миңнехановның ярдәмчесе. Төркиядәге Вәкиллегебездә ул 2012 елга кадәр эшләде. Истамбулдагы мәдәни программабыз да гаҗәеп эчтәлекле булды. «Великолепный век» сериалы төшерелә торган Топкапы Сарае безне аеручa таң калдырды. Истамбулның төп Солтанәхмәт мәйданы, янәшәдәге Айя Суфия мәчете, Зәңгәр мәчет манаралары — тарихи биналарның күплегеннән башың әйләнмәле!

Язмамның азагында янә бер тарихи һәйкәлгә тукталмыйча китә алмыйм. Чөнки ул турыдан-туры мәгънәсендә тән һәм күңелләрне пакьләндерә торган һәйкәл иде. Сүз Чемберлеташ хамамы (мунча) хакында бара. Аның бинасы 1584 елда Солтан Сәлим IIнең хәләл җефете Нурбану Солтанбикәгә атап салынган.

***

Ә кичкырын без Босфор буенда Истамбулда яшәүче милләттәшләребез белән очраштык. Кайбер апаларның безнең белән татарча сөйләшкәндә күзләренә ихлас яшь бөртекләре шытып чыкты. Ватанны, Казанны сагыну, юксыну хисләре иде бу. Хәер, үзебезнең дә күңелнең бер өлеше Рим, Византия һәм Госманлы империяләренең башкаласы булган меңьяшәр Истамбулда калды... ■

М.Бадыйкшин фотолары

ЭШЛЕКЛЕ СӘФӘР

29-30 апрельдә Татарстан Президенты вазифасын вакытлыча башкаручы **Рөстәм Миңнеханов** эш сәфәре белән Төркия Республикасында булды. Ул Төркия Президенты **Рәҗәп Тайип Эрдоган** белән очрашты. Әлеге чара Анкарада Төркия Республикасы Президенты резиденциясендә узды. Аннары Рөстәм Миңнеханов җитәкчелегендәге делегация төрек эшмәкәрләре, министрлар белән эшлекле очрашуларда булды, Төркиядә яшәүче милләттәшләребез белән аралашты. ■



«ТӘВӘККӘЛЛӘП БЕР ХАТ ЯЗЫЙМ...»

Нәзирә Фәттахова, Ләйсән Харрасова





Элек-электән хатлар кеше тормышында зур урын алып торган, элемтә чарасы гына түгел, уй-кичерешләреңне җиткерү, эч-сереңне чишү юлы да булган. Хатларның тарихи кыйммәте зур: алар танылган шәхесләрнең тормышын тирәнтен өйрәнергә булыша.

Татарстан Республикасы Милли музее фондында Муса Җәлилнең хатлары саклана. Аларны шартлы рәвештә ике төркемгә бүлеп була:

1) Җәлилнең үз кулы белән язган хатлары;

2) Җәлил имзалаган эш хатлары.

2006 елда, тууына 100 ел тулу уңаеннан, Татарстан китап нәшрияты шагыйрьнең биш томлык сайланма әсәрләр җыентыгын бастырып чыгарды. Басманың азаккы томында Муса Җәлил тарафыннан язылган җитмеш хат урын алган. Кереш өлешендә: «Бу басма, соңгы елларда формалашып килүче яңа карашлар һәм тенденцияләрне күз уңында тотып, бер төркем әдәбият белгечләре тарафыннан әзерләнде. 1975 елда дөнья күргән дүрт томлыкта шагыйрь иҗаты, гомумән алганда, шактый тулы чагылыш табуын исәпкә алып, аны әзерләүчеләр әлеге басмага таянып эш иттеләр. Соңгы елларда Җәлил архивының аерым куллардан кергән материаллар исәбенә баюын һәм фәнни принциплар кулланып тасвирлануын исәпкә алып, һәр текст чыганаклар буенча тикшерелде һәм төзәтмәләр кертелде, кыскартылган урыннар тулыландырылды. Басмага дүрт томлыкта булмаган дистәдән артык шигырь, мәкалә, көндәлек һәм хат текстлары да өстәлде»[1], — диелгән. Ләкин әлеге җыентыкта музей фондыннан өч кенә хат тәкъдим ителгән, болар: 1921 елның 21 ноябрендә Кәшфи Басыйровка (НМРТ КППи-119608), 1942 елның 9 мартында кызы Чулпанга (НМРТ КП-124224) (күчермәсе безнең музей экспозициясенә куелган (НМ РТ В-16950)) һәм 1942 елның 27 маенда Гази Кашшафка (НМРТ КППи-119803) язган хатлар.

Җыентыкка кермәгән хатларның өчесе шагыйрь, татар совет поэзиясе классигы, Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе Хәсән Туфанга адресланган. Кулъязмаларның икесе шәмәхә төстәге кара каләм, өченчесе кара карандаш белән латин шрифтында язылган. Кәгазь читләре беркадәр таушалган. Кайбер бөкләнгән урыннар ертыла башлаган. Шулай да, чагыштырмача яхшы сакланган, диярлек. Әлеге хатлар Муса Җәлил белән Хәсән Туфан арасындагы мөнәсәбәтне, якын дуслыкны күзалларга ярдәм итә. Алар аша илдәге мәдәни һәм иҗтимагый тормышны, әдәби бәйләнешләрне, шагыйрьнең дусларын һәм

[1] Муса Җәлил. Әсәрләр. Биш томда. — Казан. Татарстан китап нәшрияты. 2006. — Б.7-8.

танышларын да ачыкларга мөмкин. Муса Җәлил 1927 елдан алып 1939 елга кадәр Мәскәүдә яшәсә дә, хатлар аша Казандагы әдәби тормыш эчендә кайный, үткәрелгән һәм планлаштырылган барлык әдәби, мәдәни чаралар турында хәбәрдар була. Хатлардан шул ачык күренә.

Хәсән Туфанга язылган беренче хат (НМРТ КП-24544/3) 1933 елның 11 февралендә стандарт булмаган озынча кәгазьдә язылган. Икенчесе (НМРТ КП-24544/4) — 1933 елның 22 октябрендә. Ә өченче хат (НМРТ КП-24544/6), кызганыч ки, тулысы белән сакланмаган, бары өченче бите — фрагменты гына бар.


[illegible] 7.11.85 —3—
Sin bu şartnь bozarga tieş tygelseң. Bu datanь hic sikser quj!.. (Bik [illegible] sorьjm).
Muzьkalь nomerga ǝzerlek barь!.. Professor Litinski hǝm Şerman Rajskilar belǝn sөjlǝştem. jazalar. Kompazitorlar belǝn dǝ sөjlǝşelgǝn.
Biz kandǝ konkret nǝtiçǝlǝr turьnda jazarmьn.
[illegible]
Musa
11.XI.35.
Minem adres:
Москва, 25.
Столешников пер. д. 11,
кв. 1. [illegible]
ГОМТР 24544-6

Җәлил язган хатның бер өлеше

Җәлилнең 1935 елның 21 октябрендә Рауза Кастровага язган хаты (НМРТ КП-23608) да бик кызыклы. Бу хат кара каләм белән гарәп шрифтында язылган (бүгенге имляга Татарстан Республикасы Милли музееның өлкән фәнни хезмәткәре Р.Ә.Абзалина күчерде), чагыштырмача яхшы сакланган. Хаттан чыгып шагыйрьнең эчке дөньясын, шулвакытта кичергән хисләрен белеп була, андагы юллар Мусаның холык-фигылен ачарга ярдәм итә.

Фондтагы иң кызыклы хатларның берсе — 1941 елның 20 июнендә сеңелесе Хәдичәгә юлланганы (НМРТ КП-22536/17). Ул урыс телендә, шәмәхә кара белән язылган, берничә тапкыр бөкләнелгән, шактый таушалган, ертылган урыннары да бар. Бөкләнгән урындагы сүзләрне укып булмый. Әлеге хатта абый белән сеңел арасындагы мөнәсәбәт, Казандагы сугыш башланыр алдыннан булган тормыш ачык чагыла.

Муса Җәлилнең 1940 елның 26 июлендә ТАССР Югары Советы Президиумы рәисе Гали Динмөхәммәтовка аталган хаты (НМРТ КП-21329/2) шәмәхә кара белән татар телендә язылган (кирилл шрифтында), яхшы сакланган. Хатта телгә алынган имзалы китап та Татарстан Республикасы Милли музее фондында саклана.

Күрәбез ки, Милли музей фондында сакланган хатлар әдипнең туганнарына, дусларына, язучыларга, таныш-белешләргә, иҗади киңәш сораучыларга адресланган. Безнең көннәргә кадәр килеп җиткән хатлар аша Муса Җәлилнең шагыйрь генә түгел, ә күп башлангычларга нигез салучы, һәйбәт җитәкче, ярдәмчел дус, кайгыртучан ир һәм ата булганлыгы аермачык күренеп тора.

Хатларны, орфографиясен һәм стилистикасын саклап, тулысынча укучыларга тәкъдим итәбез.

М.Җәлил, Х.Туфан, журналист Г.Хәбиб. Малеевка иҗат йорты. 1931 ел

МУСА ҖӘЛИЛ ХАТЛАРЫ

Туфан!

Мин исән-сау 22сендә (бүген) иртә сәгать 6да кайтып җиттем. Яңа гына әле кайтып, бер кешене дә күрмәгәнгә күрә, яңалыклар яза алмыйм. Тиздән озын хат язармын.

Мин юлда портфелемне актарып, синең бүлмәдә бик күп нәрсәнең онытылып калганын сиздем. Алар барысы да кәгазь затыннан. Син иренмичә бер кич утырып, бүлмәңдәге бөтен кәгазьне актар һәм минем сызмаларны аер әле. Минем истәгеләр шулар:

1) Кара калын шигырьләр дәфтәре.

2) Шулай ук общий дәфтәр. Көрән (коричневый) төсле. Эчендә һәртөрле мәкалә, шигырь черновиклары. Бу төптә миңа бик кирәкле нәрсәләр бар. Шул ук төптә сезнең радиога балалар тапшыруы өчен яза башлаган «Югалган Һималай» дигән әйберем бар. Аның өчен Мәрьям мине сүгә инде. Ул ашыгыч кирәк.

3) Кечкенә, көрән төсле адреслар дәфтәре (алфавитлы).

4) «Алдынгы республиканың кан тамыры» дип карандаш белән язылган бер мәкалә черновигы (Татарстан турында күп кенә кәгазьләрдә).

5) Конвертта акча документлары.

6) «Кара сыра» шигырь черновиклары һ.б.

Син инде актарып үзең тап. Алама гына кәгазьдә язылган булса да, бик кирәкле язу булырга мөмкин. Менә бу санаганнардан — «Югалган Һималай», «Алдынгы республиканың кан тамыры», «Адреслар дәфтәре», «Акча документлары» бик ашыгыч кирәк. Син шуларны бүген үк ашыгыч (һава почтасы) хат белән җибәрсәң, зур ярдәмең булыр иде.

Өзелеп көтәм.

Кайтканда синең шигырьләреңне укып кайттым. Әле ике генә бүлекне укыдым. «Урал эскизлары» чиксез матур. Укыганнан укыйсы килә. «Караулда» алай түгел. Тегеләрендә бик оста бирелгән нечкә, җылы лирика бар. Алары йөрәк шигырьләре. Ә болары акыл шигырьләре. Болары трибунага басып сөйләнгән сүзләр төсле. Тегеләре иптәшеңә-сердәшеңә икәү утырып йөрәктән сөйләгән сүзләр төсле.

Сульва[2], мин укыганны күреп, берике сүз үзеннән әйтеп куйды: — Аның шигырьләрендә логика юк…

Бу кеше үзе «логика» белән башы әйләнгән кеше.

Бу урында ни мәгънәдә әйткәндер, аңламадым. Ә минем өчен синең хис белән язылган шигырьләрең авыр мантыйк белән язылган шигырьләреңнән якынырак.

Ерикәйләргә[3] вокзалдан кайтышлый

[2] Сөләйман Ярулла улы Вәлиев-Сульва (1899-1956), артист һәм режиссёр.
[3] Әхмәт Ерикәй (1902-1967), шагыйрь.

юл уңае кереп, әйберләрен калдырып чыктым. Хуҗа хатынга әйт: әйберләре сау-исән тапшырылды.

Ерикәйне ҮК политотдел редакторы итеп Чистайга җибәрергә җыена. Ерикәй: «Барырга туры килә инде», — дип тора. Мине дә шул язмыш көтә. Бармый булмас.

Ярый. Хуш. Алгач та хат яз.
Муса 22/X.33.

Туфан!

Синең Әхмәт Ерикәй аркылы биреп җибәргән запискаңны алып укыдым. Син, риядан гына булса да, минем күңелемне күккә күтәрерлек җылы сүзләр язгансың. Билгеле, алай ук түгелдер инде. Мине Казанда кем генә сагынсын икән!.. «Башкаларның да көткәне сизелә» диюең дә синең үз иҗатыңның җимешедер.

Ләкин, бик ышанып җитмәсәм дә, хатыңны укыгач, гаҗәп шатландым. Әллә ничек duslardan үзем яраткан сүзләрне ишетү күңелле булып китте.

Казанга бик барырга теләвемә карамастан, һаман барып булмый. ҮК күптән түгел Мәскәүдәге ике журналны да Казанга күчереп, андагы журналларга кушарга карар чыгарды. Менә шул мәсьәлә озак кына сузылып килгәнгә, миңа аны ташлап китәргә туры килмәде. Аннан журнал исеменнән Казанга командировка да алып булмады.

«Коммунист»[4] Уралга командировка бирә иде дә, Уралга бару мине ул хәтле кызыксындырмады. Менә хәзер, «Октябрь баласы»ның[5] Казанга күчүе уңае белән, миңа шушы көннәрдә ЦБ командировкасы белән Казанга барырга мөмкинлек чыгып тора. Мин шул уңай белән китеп, хәзер ул мәсьәлә кичекмәгән булса, радиоцентрда калырмын.

Ләкин монда Агиш мине Уралга җибәрелә торган вагон-гәҗитәнең редакторы итеп җибәрергә тели. Мин сүз бирдем бирүен дә, ләкин һаман Казанга барасы килә.

Кайсылай гына булса да, мин озакламый Казанга барып чыгармын инде. Уралга үтеп барышлый, әллә Казанның үзенәме, һәрхәлдә барырмын. Сиңа телеграмм сугармын.

Журнал беткәч, ни эшләргә булыр — анысын уйлаган юк әле.

Хәзер каләмне Фәезгә[6] бирәм.

Туфан, мин сиңа аерым һәм озын хат язарга җыенам. Шуңа күрә шушының белән мохтасар калып Әхмәт.

P.S. Теләшкә көләч сәлам!

Хуш. Муса.

Әхмәт Ерикәй сиңа күп сәлам сөйләде.

11/II.33.

Фрагмент

Син бу шартны бозарга тиеш түгелсең. Бу датаны һичшиксез куй!.. (Бик нык сорыйм.)

Музыкаль номерга әзерлек бара! Профессор Литинский[7] һәм Шерман[8], Райскилар[9] белән сөйләштем. Язалар. Композиторлар белән дә сөйләшелгән.

Тиз көндә конкрет нәтиҗәләр турында язарсың.

Хуш. Муса
11.XI.35.
Минем адрес: Москва, 25.
Столешников пер. д.11, кв.1.

Рауза![10]

Син миңа бик матур рәсем җибәргәнсең. Бу рәсем аркылы мин сине

---

[4] Мәскәүдә чыгып килгән үзәк татар газетасы, 1933 елдан 1935 елга кадәр Җәлил газетаның мәдәният бүлеге җитәкчесе булып эшли.
[5] 1929-1932 елларда Мәскәүдә чыгарылган журнал. Җәлил журналның баш мөхәррире була.
1933 елны журналны «Пионер каләме» исеме белән Казанда чыгара башлыйлар.
[6] Әхмәт Фәйзи (1903-1958), шагыйрь, прозаик, драматург.
[7] Генрих Ильич Литинский (1901-1985), композитор, педагог, профессор, РСФСР, ТАССР, Якут АССР һәм Чуаш АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, ТАССР һәм Якут АССРның халык артисты.
[8] Исай Эзрович Шерман (1908-1972), дирижёр, педагог. Карелия АССРның халык артисты, РСФСРның атказанган артисты.
[9] Райский Назарий Григорьевич (1876-1958), җырчы, педагог, профессор, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе.
[10] Рауза Кастрова (1911-2012), Муса Җәлилнең Мәскәүдәге танышы, радиокомитетта эшләгән.

хыялымда җанландырып күз алдыма бастырам. Менә әйтерсең лә, син менә «Яңа Афон»ның биек ярындагы кипарислар артына яшеренгәнсең дә, миңа карап шулай җылмаясың.

Рәсемдәге бу кыз нәкъ синең төсле. Күз карашлары да, иреннәре дә, көләч йөзе дә, шат җылмаюы да бар да, бар да миңа таныш. Алар барысы да синең үзеңнән алынганнар.

Менә хәзер генә син диңгездән коенып кайтып килә торгансыңдыр. Кавказның җылы кояшы сине бүген иртәдән бирле иркәләп кайнар комда тирбәткәндер. Син кояшның алсу нурларын йомшак тәнеңә ефәк япма итеп япкансыңдыр да, су кызы төсле зәңгәр диңгез дулкыннарына ыргытылгансыңдыр.

Әнә син җибәргән рәсемдә, вак кына бөдрә дулкыннарын уйнатып, ерак диңгез күренә. Бигрәк матур инде бу Кара диңгез!.. Ә менә син, су кызы, диңгездән башыңны гына чыгаргансың да, миңа карап көләсең. Су кызлары шаян булалар бит алар!.. Син дә шулай.

Син миңа шулхәтле матур рәсем җибәргәнсең. Аның аркылы мин сине күз алдымда басып торган төсле ачык күрәм. Диңгездә коенганыңны да күрәм, комда кызынганыңны да күрәм; кипарисларга тотына-тотына «Яңа Афон»ның биек ярыннан акрын гына югарыга атлап менгәнеңне дә күрәм.

Шуларны күрәм дә сиңа сокланам һәм сиңа кызыгам. Үземнең дә шунда буласым килә. Синең белән бергә. Сары алтын төсле саф комга ятып тәгәрисем килә. Синең белән бергә зәңгәр томан төсле бөдрә диңгездә шаярып йөзәсем килә. Синең белән бергә кипарислар арасында качышып уйныйсым килә.

Син шул усал!.. Үзең генә киттең дә бардың. Миңа күңел өчен: «Әйдә!», — дип тә әйтмәдең. Ярый инде.

Ә менә киләсе ел бергә барырбыз, ярыймы. «Ярый», дип хат яз (күнлем өчен генә булса да).

Рәсемең дә бик матур. Хат килү үзе дә бик зур шатлык. Ә менә берсе ярап бетми: нигә рәсем янына кош теледәй генә булса да бер хат кисәге дә язып салмадың инде?

Ничек ял итәсең, яхшы урнаштыңмы, һавалар яхшымы, саулыгың урыныңдамы, яхшы карыйлармы, компаниягез нинди, кемнәр бар һәм башкалар турында кыска гына язсаң, белеп торыр идем, ичмасам.

Хат яз ярыймы, Рауза!..

Мин инде сине сагына башладым. Безнең дуслык — комдагы магнолия төсле яңа гына бөреләнә башлады ахрысы. Бөреләре ачылса һәм ул матур гына итеп ап-ак саф чәчәк атса, нинди күңелле булыр. Магнолия төсле матур дуслыгыбызга үзебез дә сокланырбыз. Ә инде бөредә чакта ук өзеп ташласак, бер дә кызыгы булмас. Шуның өчен хат яз!..

Хуш. Муса. 21/X-35г.

Дорогая сестра Катя![11]

Письмо твое сегодня получили. Спасибо! Мы ждём и не дождемся твоего приезда к нам. Об этом никаких других разговоров быть не может. Мы этому верим так-же, как верим восходу солнца на следующее утро. Поэтому ты уж не пиши там: «если так…, если эдак…». Пусть будет твёрдо решено: как кончатся твои зачёты (…) ты на другой же день быстро собираешься и приезжаешь к нам. Мы уверенно с особой радостью и искренностью пригласили тебя еще в Москве приехать к нам в Казань и сейчас повторяем это. С большим удовольствием встретим тебя.

Так, значит, договорились: 25/VI кончаются у тебя зачёты и пожалуй это письмо ты получишь тоже к этому времени. Допустим 4-5 дней туды-сюды. И к 1/VII ты приедешь к нам. Конечно, телеграфно ты предупредишь об этом и мы встретим.

Я сегодня еще раз напишу брату Ибрагиму[12] и настоятельно буду приглашать его на лето в Казань. Но меня удивляет одно: почему он моё первое

[11] Хәдичә Җәлилова (1918-2000), Муса Җәлилнең сеңлесе.
[12] Ибраһим Җәлилов (1901-1979), Муса Җәлилнең абыйсы.

письмо оставил без ответа. Это было очень длинное, обстоятельное и очень, на мой взгляд, искренное, теплое письмо. Я в этом письме так-же его приглашал в отпуск к себе и несколько раз повторял своё приглашение. Я кажется, говорил тебе об этом своём письме. Говорил так-же, что не получил ответа и просил тебя написать об этом. Ты, правда, напиши в своём очередном письме об этом и спроси: получил ли он его или нет!.. Я сам тоже напишу и буду приглашать его. До сих пор я не писал только потому, что ждал ответа.

У нас были большие материальные затруднения и поэтому не могли прислать деньги для покупки кое-что на лето. Завтра мы сколько нибудь-то (...) отправим мамаше[13] для покупки необходимых продуктов. Ты уж обязательно захвати их с собою. А то знаешь сама в Казани ничего почти нет. Первое необходимое придется привезти (мука, сахар, макароны, рис и др.)

Мы напишем папе[14] или Газизу[15], приготовили посылку и обязательно встречались с тобой в Столешниковом пер.,[16] если тебя затруднит поехать в Загорянск[17]. Если тебя не затруднит эта поездка, то адрес Загорянки таков: Северная жел. дор. (от Северного вокзала) станция Загорянск (надо сесть на поезда идущие в Щелково или Монино, а не Пушкино или Загорск). После Мытищи 4-я остановка. В Загорянск: 6-я просека, 7-я дача. Ехать туда не долго. Если поедишь, хорошо будет. На всякий случай мы напишем Газизу или папе, чтобы они оставили записку, < > никого.

Если не затруднит, то папа может твоим билетом отправит в багаже (сдать в багаж) велосипед Чулпана[18]. А то она скучает по нём.

Ну, кажется всё.

Мы живём ничего. Думаем снять дачу под Казанью в деревне. К твоему приезду мы уже будем на даче.

Общественные просмотры оперы «Алтынчәч»[19] прошли с большим успехом. Вся Казань в восторге от «Алтынчәч». Ты как раз приедешь к премьере.

Вообще к твоему приезду в Казань будет много интересного: все декадные спектакли увидишь.

Приезжай!

Зине[20] тоже напишу письмо. Она что-то там не пишет.

Крепко целуем тебя: Муса.

Чулпаночка скучает по тебе: каждый день спрашивает: «Когда придёт тетя Катя?!»

М. 20/VI.41

Динмухаметов ага![21]

Сез миннән кичә иҗатым турында сораштыгыз, нинди яңа әсәрләр язуым турында сораштыгыз. Бу минем өчен бик күңелле булды. Язучы өчен аның иҗаты — язган әсәре иң кадерле баласы шикелле якын әйбер бит! Ана өчен, аның якын баласы турында сорашу никадәр күңелле булса, язучы өчен дә аның иҗаты турында сорашу шулкадәр күңелле.

Сезнең игътибарыгыз һәм кайгыртучанлыгыгыз күңелгә елылык бирде, дәртне күтәрде.

Сезнең шулай минем иҗатым белән кызыксынуыгызга шатланып, яңа гына басылып чыккан поэмамны җибәрәм («Хат ташучы» поэмасын).

Укып чыгарсыз һәм фикерегезне әйтерсез, дип ышанам.

Сәлам белән, Муса Җәлил.
26.VII-40г.

*Хатларны **Нәзирә Фәттахова** һәм **Ләйсән Харрасова** әзерләде.*

[13] Рабига Сәйфуллина, Әминә (Муса Җәлилнең хатыны) Сәйфуллинаның әнисе.
[14] Котдус Сәйфуллин, Әминә Сәйфуллинаның әтисе.
[15] Газиз Сәйфуллин (1915-?), Әминә Сәйфуллинаның энесе.
[16] Столешников урамы, 11 йорт, 1 фатир — Муса Җәлилнең Мәскәүдәге адресы.
[17] Мәскәү янындагы бистә, анда Әминә Сәйфуллинаның әти-әнисе яшәгән.
[18] Чулпан Җәлилова (1937), Муса Җәлинең кызы.
[19] Нәҗип Җиһанов музыкасы.
[20] Зәйнәп Җәлилова (1908-1965), Муса Җәлилнең сеңелесе.
[21] Гали Афзалетдин улы Динмөхәммәтов (1892-1951), ТАССР Югары Советы президиумы рәисе.

ЮГАЛМАСЫН ҖИРДӘ ЭЗЛӘРЕ...

Әрибә Айтуганова[1]

ӘТКӘЕМНЕ КҮРӘСЕМ КИЛДЕ...

1942 елның гыйнвар аенда безнең Айтугановлар гаиләсе соңгы тапкыр бергә җыелды. Әткәй белән кече абыебыз Ягъсуб әле фронтка алынмаган. Олы абыебыз Нәкыйп, артиллерия училищесын тәмамлагач, Башкортстанга, үзе командир булачак частькә сугышчылар мобилизацияләргә җибәрелгән, юл уңаенда өч-дүрт көнгә авылга керергә җай тапкан. Көннәр бик салкын — 35-40 градус торды. Ә без ул салкыннарны сизмәдек тә шикелле, чөнки җидебез дә бергә: әткәебез

Кәрам Айтуганов кызлары Әрибә, Әдилә һәм улы Ләбиб белән. 1941 ел

[1] Әрибә Кәрам кызы Айтуганова — Бөек Ватан сугышының тыл ветераны, Әгерҗе районындагы Нарат авылында яши.

Мөхәммәткәрам, әнкәебез Әминә, ике абый, мин — 13 яшьлек Әрибә, 11 яшьлек сеңелем Әдилә, 7 яшьлек энем Ләбиб. Җидебез дә исән-сау…

Шул елның апрель башында — Ягъсуб абый, май азагында әткәй фронтка алынды. Әткәй киткәндә: «Сугыш тиз генә бетмәс, берәребез булса да кайтыр әле», — диде. Август азагында ук — Ягъсуб абыйның, декабрь азагында әткәйнең һәлак булуы турында хәбәр алдык. Шулай да, әйткәне хак булды: өчесеннән берсе кайтты.

Ягъсуб абый — Орёл өлкәсендә, әткәй Смоленск өлкәсендә баш салган. Икесенең дә кайда күмелгәннәре язылган иде. Сугыш беткәнче «бәлки, кайтырлар әле» дигән өмет белән яшәдек. Аннан соң каберләрен табу, ятып калган җирләрен яд итү теләге туды. Эзләвем озын-озак елларга сузылды… Бу турыда тәфсилләп язуымның мәгънәсе шунда: сугышта һәлак булган якыннарының эзен, каберен эзләүчеләр хәзергәчә бик күп, өметләре өзелмәсен, димен. Иртәме-соңмы хәбәрләре килер. Минем әлеге хикәятем — шуның бер мисалы…

Әйткәнемчә, безнең әткәй — Айтуганов Кәрам Хафиз улы (1896 елгы) — сугышка 1942 елның 26 маенда китте. Ул чакта сугышка китүчеләрне бөтен авыл халкы амбар янына чыгып, юл янында озатып кала иде. Әткәй исә безгә анда барып йөрергә кушмады. Ишегалдында гына хушлашты. Капка төбенә җигүле ат килеп туктады. Әткәй юл капчыгын алып атка утырды, без капка төбендә басып калдык. Ул авылдан берүзе китте.

Әткәйдән беренче хат 9 июньдә Ижау шәһәрендәге лагерьдан килде. Күршедәге Үтәгән авылыннан укытучы Мирзаһит Айдаров, Исәнбай авылыннан Салих Сабитовлар белән бер частьта хәрби һөнәргә өйрәнәләр икән. Бер атнадан соң икенче хат алдык. Мирзаһит абыйның хатыны Ижауга килә икән, шуның аша оекбаш, бияләй һәм башка вак-төякләр җибәрүебезне сораган. Айдаров та хатынына бу турыда язган. Июнь урталарында Гыйльмиҗамал апа безнең әйберләрне алырга килде. Шулчакта: «Минем дә әткәй янына барасым килә», — дип бик каты ялындым. Аптырагач, барысы да: «Бар, алайса», — диде. Гыйльмиҗамал апа юлга тагын ике авылдаш хатыны белән берсекөнгә чыгачагын әйтте. Аннары: «Тик барганда сине ияртә алмыйбыз, атка авыр булыр, кайтканда алып кайтырбыз», — дип өстәде. Шулай килешендек. Ләкин Ижау кадәр Ижауга ничек барырга соң? 130 чакрымлык ара бит! Иртәгәсе көнне колхоз Ижауга ат җибәрә икән. Тәгәрмәч маена. Әнкәй белешкән. Алар мине дә алып барырга ризалашты.

Шулай итеп, иртәгәсен көндез кузгалдык, икенче көнне кичкә Ижауга җиттек. Әгерҗе ягыннан кергән якта урнашкан Татар бистәсенә килдек. Анда безнең авылдан киткән Мөхәммәтгали һәм аның хатыны Хәмидәләргә барып кердек. Иртән торгач, Хәмидә апа мине әйберләрем белән Актаныш районының Бикчәнтәй авылы (әткәйнең туган авылы) кешесе Заһитларга илтеп куйды. Әткәйләр лагерьдан аларга килеп йөри икән. Көндез бирегә Айдаров абый килде дә, мине лагерь артындагы хәрби өйрәнү урынына алып китте. Мирзаһит абый, хәрби эшкә өйрәтүче командирга әкрен генә дәште. Безнең янга бер кулын бәйләп аскан, шадра йөзле, яшь кенә өлкән лейтенант Сәгыйтов килде. Мирзаһит абый аңа «күчтәнәч» бирде. Сәгыйтов әткәйне безнең янга чакырып китерде. Әткәй гимнастёркадан, башында — пилотка. Ул мине күреп шаккатты: «Ничек килдең? Мин бит килеп йөрмәскә кушкан идем». «Сине күрәсем килде, әткәй», — диюдән узмадым. Әткәй Сәгыйтовка: «Менә, минем дөнья күтәргә калган кызым — шушы», — дип таныштырды, шул мизгелдә аның күзләреннән яшь саркып чыкты. Аннары алар өчәүләп Мирзаһит абыйның папиросын кабыздылар. Безнең әткәй гомер тартмый иде. Ә монда кабызды. Әллә биредә тартыр-

га өйрәнгән, әллә иптәшләре тартканга гына?.. Анысын аңламадым, сорарга да кыенсындым. Шуннан соң командирлары әткәй белән Мирзаһит абыйны иртәнгә кадәр «ирекә җибәрде». Лагерьга якын гына, тау төшкәч, авыл өйләре тезелеп тора. Берсенә кайтып кердек. Әткәй белән өйалдында төне буе сөйләшеп чыктык. Ул үзебезнең, авылдашларның хәлен сорашты, нык торырга кушты, киңәшләр бирде. Шул рәвешле мине юатырга, күңелемне күтәрергә тырышты сыман. Иртән иртүк, яктыргач ук, чәй эчтек тә әткәй белән Мирзаһит абыйның икесен озаттык. Лагерь якын, урамнан бераз баргач, тау гына менәсе, менгәч үк сирәк кенә агачлар, шунда — лагерь. Без капка төбендә басып калдык. Алар бераз киткәч, хатыннарның берсе: «Озак карап тормаек, озак торып кайтырлар», — дип безне алып кереп китте. Әткәй белән Мирзаһит абый, без китергән күчтәнәчле капчыкларын асып, икәүләп тауга менеп калдылар.

Нәкыйп Айтуганов

Әткәйләрне озаткач, өй хуҗалары — эшкә, Үтәгән хатыннары өчесе дә базарга китте. Миңа ишегалдыннан беркая да чыкмыйча аларны көтәргә куштылар. Үзем генә калып бераз торгач, башыма әткәйне тагын бер күреп кайту уе килде. Әткәйләр киткән юлдан барып, таудан менеп, хәрби лагерьга юнәлдем. Капка төбендәге сакчы сорагач: «Әткәйне эзлим», — дидем. Ул: «Хәзер лагерьда кеше юк, барысы да хәрби өйрәнүләргә киттеләр», — диде. Мин кичә әткәй белән күрешкән җиргә йөгердем. Тик анда бүген беркем дә юк иде. Кире фатирыбызга кайттым. Кайту белән күрше Үтәгән авылы хатыннары мине ачулана башладылар. Мин аларга: «Әткәйне тагын бер күрим, дип барган идем, тапмадым», — дидем дә елап җибәрдем. Шуннан алар үзләре дә елый башлады. Чөнки әлеге хатыннарның икесе ирләрен очрата алмады. Аларны элеккеге көнне генә фронтка җибәргәннәр икән.

Юлга кузгалдык. Төнгә авылга кайтып җиттек. Сәяхәтем тәмам.

Әткәйне соңгы тапкыр күрүем шулай булды. Һаман күз алдымда тора: дөньяга балкып кояш чыгып килә, ә ул тауга менеп бара. Адымнары салмак, йөзе моңсу...

Әткәйнең иптәшләре Мирзаһит белән Салих икесе дә сугыштан исәнсау әйләнеп кайтты. Кайткач ук икесе дә безгә хәл белергә килде. Ижауда ничек хезмәт иткәннәрен, әткәйдән кайда аерылганнарын сөйләделәр.

Әткәйләр Ижаудан фронтка 3 июльдә киткәннәр. Бу турыда ул Муром

станциясеннән язып җибәргән иде. Мирзаһит Айдаров та аның белән бергә булган. Хатында: «Үзәк шәһәргә таба алып баралар, берәр җирдә хәрби кием киендерер өчен туктатырлар, дип уйлыйбыз», — дигән иде. Үзәк шәһәрне Мәскәү дип аңладык. Хатта 6 июль датасы тора. 8 июльдә Иваново өлкәсе, Юрьев-Польский шәһәреннән язган иде. «Монда бераз торырбыздыр, хатны алу белән язсагыз, бәлки хатыгыз килеп тә җитәр», — дигән иде. — Айдаров белән бергә әле...» 27 сентябрьдә: «Хәрби полосада торабыз, әле үзгәрешләр юк», — дигән хат килде. Әле сугышка кермәгәннәр, дип аңладык. «Полевая почтовая ст. 1622938, ст. полк, 3 батальон, 7 рота адресына язып торыгыз», — дигән иде. 16 ноябрьдә кыска гына хәбәр салган: «Сугыш кызу, әлегә исән-сау...» Соңгы хәбәре шул булды.

Әткәй турындагы кара кәгазьне яттан беләм: «Ваш красноармеец Айтуганов Карам Хафизович, уроженец Тат. АССР, Красноборский район, дер. Сосново, в бою за социалистическую родину, верный воинской присяге, проявив геройство и мужество был ранен и умер от ран 5 декабря 1942 года. Похоронен в братской могиле в Смоленской области, Слободского района, Аносинского сельсовета, дер. Джунда, на северо-восточной окраине, в 500 м от деревни»[2]. Бу — хәрби комиссариаттан килгән күчермә, шуңа күрә авыл-район исемнәренең дөрес язылмавы да ихтимал иде.

Сугыштан соңгы тормышлар бераз рәтләнгәч, мин китапханәдә эшли башлагач, шул адрес буенча хат язып, әткәйнең каберен эзләргә керештем. 1980 елның август аенда, ниһаять, җавап килде. Анда болай дип язылган: «В Слободском районе Смоленской области есть деревня, называется она Джица, это вы неправильно прочитали в похоронке или кто в извещении неразборчиво написал. Деревня Джица Аносинского сельсовета. В дни войны там располагался медсанбат, потом госпиталь. Если кто умирал от ран — его там же и хоронили. Сейчас недалеко от этой деревни есть братская могила, стоит над ней обелиск со звездой, но фамилии пока ничьи не указаны. Ведь это был 1942 год, у нас все тут горело и гремело, шли жестокие бои, хоронить не всех успевали, не то что фамилии писать. Ваш отец и похоронен в этой могиле вместе с другими воинами. Если имеете возможность — приезжайте. С уважением, Евгения Павловна Гавриленкова, заведующий музеем поселка Пржевальское».

Шушы хатны алгач, әткәйнең каберенә бару теләге белән берничә ел янып йөрдем. Җае да, мөмкинлеге дә, вакыты да чыкмады. Ниһаять, 1985 елда барырга тәвәккәлләдек: мин, сеңелем Әдилә, энем Ләбибнең кызы Миләүшә, кече кызым Нурсөя.

Евгения Гавриленкова белән очраштык. Әткәйнең һәлак булуы турындагы хәбәрне һәм әткәйнең 1942 елның 16 ноябрендә язган соңгы хатын бирдем. Ул, үзендәге документлар белән чагыштыргач, дөрестән дә, әткәйләрнең частьлары шушы тирәдәге сугышларда катнашканлыгын раслады һәм сугыш көннәре турында сөйләде. Евгения безне әткәй күмелгән урынга баруны оештырды. Автобус йөртүчесе безне кирәкле җирдә төшерде, юлны күрсәтте. 200 метрлап читкә киткәч, уңга борыласы, түбәнгә төшәсе. Анда чокырдан сай гына су агып тора. Күпере дә, басмасы да юк. Ташларга басып аркылы чыктык та тауга күтәрелдек. Калкулыкка менеп җитүгә үк сул якта, юл буенда ук, зәңгәргә буялган агач рәшәткә белән бүлеп алынган зур гына мәйдан. Тирәюнь — урман. Куе, гел яфраклы агачлар гына. Бездәге кебек ылыслылары юк. Мәйданның көнбатыш читендә биек

[2] Монда һәм моннан соң хатларның, документларның орфографиясе, пунктуациясе һәм стилистикасы оригиналдагыча бирелә.

мәрмәр обелиск, өстендә кызыл йолдыз, астарак бик зур алтын хәрефләр белән «Вечная слава героям войны!» сүзләре язылган. Көньягына кеше йөрердәй генә рәшәткә капка куелган. Шул капкадан обелискка кадәр асфальт сукмак. Ул сукмак буйлап ике яклап агач эскәмияләр куелган. Обелискның төбенә өч яклап тар гына түтәлләр ясалган. Алардагы гөлләр үсеп кенә килә иде әле. Обелискка исемлек куяр өчен урыннар уелган, әмма исемлек үзе юк. Е.П.Гавриленкова безгә: «Музей карамагында шушындый ун обелиск бар (бусы 10 нчы номерлысы икән), берсендә дә исемнәр язылмаган, без хәзер исемлек булдыру эшенә керештек», — дигән иде.

Обелиск янына килдек, башта тыштан карап тордык, аннан капкадан эчкә үттек. Мәйдан чиста, ямь-яшел үлән үскән. Эскәмияләрдә ярты сәгатьләп утырдык. Аннары юлдан 400-500 метр ераклыкта күренеп торган өйләргә таба киттек. Безне ике хатын-кыз күзәтеп торган икән. Ачык чырай белән каршы алдылар, өйләренә чакырдылар. Кунакка кергәнче, өй буенда утырып, алардан сугыш вакытындагы хәлләрне сораштык.

Бик күп еллар элек бу авылның исеме Пустые Лжецы булган. Соңрак югары өлешен Джица, түбән өлешен Дятлово дип йөрткәннәр. Сугыш вакытында мәктәптә медсанбат, аннан соң госпиталь оештырылган. Яралыларның мәктәпкә сыймаганнарын өйләргә таратып та дәвалаганнар. Табиблар, шәфкать туташлары, санитарлар — барысы да хәрбиләр. Хуҗалык эшләрендә авыл халкы булышкан.

Ярадан үлгәннәрне өс киеме белән мәктәп чоланына чыгарып куя барганнар. Күпләп җыелгач кына шушы урында зур чокыр казып, барысын да күмгәннәр. Кабат җыелгач, тагын шунда ук күмгәннәр. Безнең әткәй дә күмгәннәрен көтеп чоланда шулай яткандыр инде, дигән уй йөрәкләрне чәнчеп үтте. Бу каберлектә бары тик госпитальдә үлгәннәр генә җирләнгән. Обелиск янындагы чәчәк түтәлләрен күрше Гончарово авылындагы мәктәп балалары ясаган. Тугызынчы майда һәйкәл янына мәктәп балалары һәм авылдагы барлык халык чыга, митинг була, кешеләр һәм балалар чәчәк куеп китә икән.

Бу ике хатын сугыш вакытында биредә булган хәлләрне елый-елый сөйләде: «Безнең өйгә яралыларны кертеп салдылар. Араларында авыр яралы япь-яшь солдат бер тәүлек буе әнисен чакырып ыңгырашып ятты да, көндез үлде. Ул үлгәч үк почта килде, шул солдатка әнисе язган унлап хат бар иде. Ичмасам, хатларны да күрми үлде, дип барыбыз да еладык». Сугыш вакытындагы авыр тормышларын, мондагы хәлләрне искә алу аларга да бик кыен иде шул. Китешли, туганнар каберлегенә кабат кердек, әткәй белән хушлаштык, авылдан алып килгән бер уч тафракны шунда салып калдырдык.

Үзебездәге, музейдагы рәсми документларны карап-тикшереп, сугыш вакытында анда яшәгән, сугыш афәтен үз күзләре белән күргән кешеләр белән сөйләшкәннән соң, без әткәйнең шушы каберлектә җирләнүенә ышанып кайттык. Әткәйнең соңгы эзләре калган җир — Смоленск өлкәсе, Демидов районы, Гончарово авыл советы, Дятловщина авылы. Әткәй каберенә баруыбызга 30 ел вакыт узса да, ул җирләр һаман күз алдымда тора.

Хәзер интернет заманы бит, ул авыл әлегәчә бар микән, дип быел тикшереп карадык. Бар икән. Шул Дятловщина авылы янындагы туганнар каберлегендә 84 сугышчы күмелгән, дигән мәгълүмат таптык. Музей белән элемтәгә кердек, әтиегезнең исеме обелискка язылган, диделәр. Димәк, аның эзе югалмады. Чынлыкта анда ничә милләттән, күпме сугышчы ятуын беркем дә төгәл белми һәм белмәс...

Ахыры киләсе санда ■

ӘМИРХАННАР НӘСЕЛЕННӘН

Зөлфәт Хәйруллин

Бөек Ватан сугышы ветераны Әнәс Әмирханов озак еллар «Татарстан яшьләре» һәм «Ватаным Татарстан» газетасы редакцияләрендә рәссам булып эшләде. Аның тормыш юлы озын һәм гыйбрәтле.

1929 елда гаиләгә кайгы килә. Әтисе Габдулла абзыйны *кулга алалар. Өч елга Соловкига сөргенгә сөрәләр. Кечкенә Әнәс әнисе белән Соловкига бара. Алар анда бер ай торып кайта. «Урман эчендә — агачтан салган бараклар. Әтиләр утын кисә, пычкы кайрый иде. Миңа да барак эченнән — агачтан ясалган нардан урын бүлеп*

Әнәс Әмирханов

бирделәр. Әти төрмәдә утырган өчен гомер буена икенче сортлы кеше булып яшәдем», — дип искә ала Әнәс ага Соловкида ясап кайткан рәсемнәрен күрсәтеп. Өлкән классларда укыганда, уку түләүлегә әйләнә. Ә түләргә акча юк. Әнәс абый, аптырагач, эшләп укырга мәҗбүр була. Ул физикадан яхшы укый. Ләкин, әле унсигез яшь тулмау сәбәпле, эш табу бик авыр була.

Бервакыт Әнәсне күн-галантерея фабрикасына чакыралар. Әгәр дә сигнализацияне төзәтеп бирсәң, эшкә алабыз, диләр. Бер атна эчендә ул аны эшләп чыга. Шуннан электромонтёр булып китә. Ул анда куна-төнә эшли, кичке мәктәпне тәмамлый, урта белем ала.

Әнәсне сугышка 1942 елда алалар. Артучилищеда укып, артиллерист булып китә ул. Аларны Ленинград фронтына җибәрәләр. Яшь сугышчы монда нинди генә хәлләргә очрамый. Аптырагач, учакка азлап кына дары сибеп, чәйнектә чәй кайнаталар, мунчага ягарга утын беткәч, шартлаткычлары алынган миналар ягып мунча керәләр, бетләрдән арыналар. Алар, сугыша-сугыша, Ленинград ягындагы Красное Село авылын азат итә, һаман алга бара. Ул Финляндияне азат итүдә катнаша. Эстония, Латвияне яшеренеп калган немецлардан чистартырга булыша. Ленинградның көньягында Царское Селода багана башына, чормаларга менеп кунаклаган снайперларны атып төшерә. Шунда яралана. Аны госпитальгә салалар. Үз частемнан калмыйм дип, ул аннан кача. Бу вакытта Казандагы әнисенә: «Улыгыз хәбәрсез югалды», — дигән хат килеп төшә. Сугыш беткәч тә әле ул Ленинград шәһәрен миналардан чистартуда катнаша. 1947 елда гына туган якларга кайта һәм янәдән монтёр булып эшли. Рәсем ясарга аны И.Шишкинның «Арыш кыры» дигән әсәре илһамландыра. Ул Казан сәнгать училищесына укырга керә.

Рәссам булу теләге бик көчле була. 1952 елда Әнәс аганың күптәнге хыялы тормышка аша. Ул Гали Хуҗи җитәкләгән «Яшь сталинчы» газетасына рәссам булып урнаша. Шуннан бирле Әнәс Габдулла улының бөтен гомере, әйтик, унбиш еллап тормыш юлы республиканың яшьләр газетасы белән бәйле булса, лаеклы ялга кадәр өлеше «Социалистик Татарстан» (хәзер «Ватаным Татарстан») газетасында үтә.

Әнәс абыйга инде, Аллага шөкер, 92 яшь тулып килә. Ул әле дә көр күңелле, яхшы хәтерле. Фатих Әмирханны якыннан күреп калуы, аның белән дусларча аралашуы турында горурланып сөйли, мәшһүр туганын сагынып искә ала. Тормыш иптәше вафат булганнан соң, озак еллар кызы Земфира тәрбиясендә яши. Мин аңа сәламәтлек, бәхет, шатлык телим. ■

Г.Хөсәенов – алдагы рәттәгеләр арасында сулдан икенче. 1973 ел

СҮЗ ҺӘМ СУРӘТ

Рафаэль Ильясов,
Татарстанның халык артисты

«Шәхси фотоальбомымда кадерләп саклана торган әлеге фоторәсемнәргә караган саен күңелдә якты хатирәләр яңара. Аларның беренчесен миңа спорт дөньясында легендар шәхескә әверелгән милләттәшебез бүләк итте. 1973 елда мин Төрекмәнстан башкаласы Ашхабадта Әлфия Авзалова төркеме белән гастрольдә булдым. Без «Ашхабад» кунакханәсендә «Спартак» футбол командасы белән бергә туры килдек. Шунда татар егете Галимҗан белән танышып киттек. Ул гаҗәеп гади, милли җанлы, аралашучан кеше буларак истә калды. Аны концертыбызга чакырсак та, Ашхабадта уеннарын тәмамлап, Мәскәүгә китүе сәбәпле, килә алмады.

Соңыннан төрле чыганаклар аша шушы якты күңелле танышым турында мәгълүматлар тупладым. Галимҗан Салих улы Хөсәенов 1937 елда Татарстанның Норлат (элекке Октябрь) районы Яңа Иглай авылында туа. Хәрби чиндагы Салих аганы гаиләсе белән Куйбышев шәһәренә күчерәләр. Әтисе 41 яшендә вафат була. Галимҗан каладагы гидротехника техникумын

Уң планда – Нурсөя исемле кыз – Ф.Яруллинның булачак хатыны. 1950 нче еллар

тәмамлый. 1957-1960 елларда «Крылья Советов», 1961-1973 елларда «Спартак» (Мәскәү) командаларында уйный. Җирле «Крылья Советов» командасының капитаны итеп тә сайлыйлар. Ике тапкыр СССР чемпионы (1962, 1969) була. Өч тапкыр СССР кубогын ота (1963, 1965, 1971). Европа кубогының көмеш медале белән бүләкләнә (1964). СССРның җыелма командасында катнаша (1960-1969), СССРның атказанган спорт остасы дәрәҗәсенә ирешә (1967). 2010 елның 5 февралендә Мәскәүдә вафат була».

***

«Икенче фото 1950 нче еллар ахырында Татарстанның халык шагыйре, чын мәгънәсендәге каһарман шәхесебез Фәнис Яруллинның фатирында төшереп алынды. Ул вакытта язучы Волгоград урамындагы 30 нчы йортта яши иде. Композитор Наилә Зарипова (фотода аккордеон белән) Фәнис Яруллин шигыренә «Сиреньнәр» дигән җыр язган иде. Ул аны миңа тәкъдим итте. Җыр ошады, аны үз репертуарыма кабул иттем. Менә шуннан соң без аны Фәнис Яруллинның үзенә җырлап күрсәтергә булдык. Рәсемдә әнә шул мизгел — яңа җыр премьерасы чагылыш тапкан. Ул көнне шагыйрь янына студент яшьләр дә килгән иде.

Мин бу рәсемнәрне кадерләп саклыйм. Данлыклы милләттәшләремнең якты рухларын хөрмәт белән искә алам». ■

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор **РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВ**ның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

КУТАДГУ БИЛИК

(Котайткыч белем)

Йосыф Баласагуни
(Йосыф Хасс-Хаҗиб)

Аның йөзен күргән бәхетле булыр,
Ике дөньясында да котлы булыр.

Ни ди, ишет, әнә калабыз башы
(Ил идарәсенә җитәр, шәт ушы):

«Кануны тугры бәк – үзе бер бәхет,
Халыкка китерә файда, ямь вә кот».

Данлыклы бу бийгә бару мәслихәт,
Шуңа барып бәхет-кот таба ир-ат.

Канунга тугрылык – нигез ныклыгы.
Кануннар бозылса, нигез мурт булыр.

Канунга хыянәт итсә хан-бигең,
Җиде кат җиреӊ дә убылыр иде.

Гадел бийне күргән зат котлы булыр,
Уңышка ирешер, язын йолыр.

Бүген кеше булсам, син беләсең бит,
Моңа сәбәпче һәм терәкче илбик.

Ходай бирде – ушлы, белемле булдым,
Барча игелеккә ирешә алдым.

Ходай бирде тәүфикъ, чын изгеләрчә
Үземә халыкның йөген йөкләргә,

Хөкемдарга син бик кирәксең бүген:
Син генә чишәрлек бар, ди, бер төен.

Шуннан ул җибәрде сиңа әйтергә.
Дучар итмә мине синсез кайтырга.

Бөтек язды сиңа үз кулы белән.
Ниләр теләгәнен укып күр менә.

Үгделмеш кесәдән чыгарды бөтек.
Ачты да Уйгырмыш укыды тотып.

Укып чыккач, озак уйланып торды,
Һәм әйтте: – Хөкемдар зур белем бирде.

«Инде үзең кил», дип әйткән хөкемдар.
Барча игелекне санаган – ни бар.

Бөек эш ич бу хәл бигрәк тә менә,
Хәзер нишлим инде, киңәш бир миңа.

ҮГДЕЛМЕШ БУ МӘСЬӘЛӘДӘ УЙГЫРМЫШ БЕЛӘН СӨЙЛӘШӘ

Җавап биреп әйтте Үгделмеш: – Илбик
Сөйли сине генә, төшерми телдин.

Телен тибрәттеме – исемең чыга,
Хәзер сине күрү өчен ашыга.

* Дәвамы. 2013 елның 10 нчы саныннан басылып килә.

**«Кануны тугры бәк – үзе бер бәхет,
Халыкка китерә файда, ямь вә кот».**

Күңел биреп сөйсә әгәр бер затны,
Сүз аралаш шуның кабатлый атын.

Гашикъылар ни диләр, син шуны укы:
Сөеклеңнең йөзе – күңел туклыгы.

Күңел кемне сөйсә, күзең шуңарда,
Сөйгәнең йөзеннән күзең нур ала.

Күңелең ни тели – телдә, сүзеңдә,
Телеңнән дә бигрәк чагыла йөзеңдә.

– Ярый, аңлыйм, – диде Уйгырмыш, – миңа
Киңәш бир, нишләргә сорыймын шуңа.

Рәхимле кардәшем, син миңа якын,
Киңәш биреп үтә кардәшлек хакын.

Бу эштә нәкъ синнән киңәш сорыймын,
Ярдәм итәр, димен, синең гыйлемең.

Түгел кардәш кенә, дус та була бел.
Бу ике сыйфатны бергә җыя бел.

Рәхим итәр кеше син генә миңа.
Бүген ни эшләргә һәм ни кылырга?

Җаваплап Үгделмеш әйтте: – Бу сүзне
Юнәлтмә син миңа, и нурлы йөзем.

Сине чакырырга җибәрде илбик.
Нинди киңәш сиңа бирим, ди, инде.

«Киттек», кенә димен, юк бүтән сүзем.
«Барырга кирәкмәс» диялмим үзем.

Сине мин апкайтсам, миңа файдасы.
Үзем өчен йөргән кебек булмасын.

Ишет, ни дигән бер белемле чигил[1]
(Белексез, тыңла һәм хөрмәтләп иел):

**Рәхимле кардәшем, син миңа якын,
Киңәш биреп үтә кардәшлек хакын.**

[1] Чигил – борынгы бер төрки кабилә атамасы. Алар, ихтимал, Болгар кабиләләренең берсе әсегел белән бердәй яисә кардәш булгандыр. Чигил сүзенең гади кеше (асыл зат түгел) дигән мәгънәсе дә булган.

Киңәшергә кирәк төрле зат белән,
Хәл итәргә кирәк күңел-җан белән.

Үз кирәгең өчен күп сөйләмә син,
Ахыр югалтырсың эшең файдасын.

Киңәш ул шулчакта гына чын киңәш,
Киңәшче бер файда көтмәсә, кардәш.

Киңәшче булынса бер мәнфәгатьтә,
Сүзе бигүк тугры булмас, әлбәттә.

Киңәшергә кирәк төрле зат белән,
Хәл итәргә кирәк күңел-җан белән.

Үзеңә рәхимле син үзең генә,
Кешегә сөйләсәң, калыр сүз генә.

Киңәшсәң үз-үзең белән син киңәш,
Теләмә, сорама миннән һич киңәш.

Сине алырга дип килдем ул җирдән.
«Киңәш» тик бер генә: «Әйдә, йөр бергә».

Кеше арасында аяу, изгелек
Бу эшкә кагылмый – анык билгеле.

Авыл-калаларга ни өстенлек бар –
Бәйнә-бәйнә сөйләп кылдым ич изһар.

Беләсең, барсын да дөрес сөйләдем,
Бер Алла белә, тик бәхет теләдем.

Кешедән качканнар ни майтардылар?
Кешегә кешенең һәрчак эше бар.

Мөселман кешенең уртаклаш моңын –
Илаһ бирер сиңа җәннәттән урын.

Телең-күңлең белән Тәңрегә табын,
Кайда яшәсәң дә саф булсын җаның,

Тик ялгыз яшәмә, урының ил-көн,
Кеше гайбен күрмә, үзеңнекен күр.

Бу бәйтне укы да, акыллы булсаң,
Әйбәт булыр аны гамәлгә куйсаң:

«Кайда яшәсәң дә бер ул изге юл:
Игелек сорама, үзең иге бул».

Кеше яхшысына шундый сыйфат хас:
Кайда йөресә дә юлыннан чыкмас.

Күңел игелеге чыксын йөзенә,
Яшәүдән тапсын ул сөенеч кенә.

Иге булып туган һәр җирдә иге,
Токымы да булмас бер җан көеге.

Ия бул үзеңә иге холыкка,
Ниләр эшләсәң дә, шуннан курыкма.

УЙГЫРМЫШ ДӨНЬЯНЫ ГАЕПЛИ

Җавапта Уйгырмыш әйтте: – Сүзем шул –
Сүзеңне ишеттем, хәзер тыңлар бул.

Дөнья, ахры, сине алдап сөйдергән,
Гаебен фазыйләт итеп күндергән.

Мөселман кешенең уртаклаш моңын –
Илаһ бирер сиңа җәннәттән урын.

Гаҗәп түгел, чөнки шундый канун бар:
Хаталардан хали була сөйгән яр.

Дөньяны сөйгәчтен, барча гаебе,
Кабы-чүбе хәтта була кадерле.

Гашикълар әйткәнчә, сөекле затның
Начар ягы була сөйкемлек башы.

Гашикълык билгесе менә шул булыр –
Гаебе фазыйләт булып тоелыр.

Дөньяны сөюең шулай синең дә,
Гаебен шәплек дип әйткәч, күренә.

Мактама син, туган, миңа дөньяны,
Кире якларын күп беләм мин аның.

Ялгышканга җәза Тәңре кулында;
Төнәк кенә безнең юлда бу дөнья.

Төнәгән төшеңне сөймә син артык,
Җитәр җирең – оҗмах, кулавыз – котлык.

Илаһ бирә икән бүләкләп колын –
Дөнья малын түгел, намус сафлыгын.

Бу дөньяның коты начар коттыр ул:
Кот түгел, йот: диннән ераклаштырыр.

Баекса ил, төшә тәкәбберлеккә,
Күңеле сафлана тик фәкыйрьлектә.

Мин Тәңрегә тиң, дип йөргән тиленләр,
Дөньяны яулыйм, дип, эттәй үлделәр.

Шәрә киләбез дә, шәрә китәбез.
Комсызлыктан ник баш тартмый икәнбез?

Ник ул горурлыгың, китәсе бәндә,
Ике көнлек кунак булганың хәлдә.

Беләсең ич – гомер үлемгә бара.
Һәр борылышта үлем караулап тора.

Дөнья ача капка артыннан капка,
Бар да бара соңгы капкага таба.

Үзең «ике көнлек бер сөенечтән
Калдым», дип, үкенеп көенмә һич тә.

Бер битен күрсәтә дөнья, бир китен:
Тиз үк тартып ала биргән нигъмәтен.

Тереклек һәм үлем бирә һәр көнне,
Чакырып, уята төрле дәртеңне.

***
Дөнья күләгәгә, бакчы, бик охшаш:
Кусаң, тоттырмас һәм качсаң, калышмас.

Бу мәгънәдә тагын әйтелә бер сүз
(Мәгънәсенә төшен, тыңла, күңле төз):

«Бу дөнья качадыр, аңар иярсәң,
Һәм иярер сиңа, син качыйм, дисәң».

Дин-иманга үчле бу дөнья малы,
Ашый дөнья динне, белеп тор аны.

Бизәнер бу дөнья, күрсәтер үзен,
Кәләштәй кыланыр — җилкенер күңлең.

Мактама син, туган, миңа дөньяны,
Кире якларын күп беләм мин аның.

Ә күңел бирдеңме – ул явыз кортка:
Көн дә сүзгә килә, якаңнан тота.

Кем дә кем күңелен бирсә аңарга,
Исәр ул, гомере үтә заяга.

Газиз гомрең, санлы яшәү көннәрен
Ничек сарыфлыйм, дип уйлан элгәре.

Тереклегең изге эшләр нигезе,
Исраф итмә аны, өлгер егетем.

Дөньяда өч төрле була нәрсәләр:
Йә хәрәм, йә шикле, йә дөрес – хәләл.

Бу дөньяны сөйсәң, ул сине сөрә,
Кинәнеп мавыксаң, тиз йөз чөерә.

Хәрәмгә газап бар, хәләлгә – хисап,
Аз гына шик-шөбһә булса, бул син сак.

Кәеф-сафа, шатлык бары симертә,
Ачы кайгылар да бары тилертә.

Сөенечкә кара — азагы сагыш,
Сөенеч артыннан куу – ул ялгыш..

Башланышы нигъмәт – азагы михнәт,
Тик михнәтләр соңы гына бер нигъмәт.

Ни ди, ишет, әнә уяурак дустың:
«Ерак тор дөньядан – өтеп алмасын.
Синең байлыгың, күр, рухи ярлылык,
Фәкыйрьгә нисбәтән генә син байсың».

Җаваплама, аңлаш, сүксәләр сине –
Кара җир катында түләр үчеңне.

Таралачак барча өйгән әйбереň,
Чәчеләчәк синең җыйган һәр нием.

Китүчән ул – кемдер китәдер көн дә,
Килүчән ул – афәт киләдер һәр дәм.

Хәрәмгә газап бар, хәләлгә – хисап,
Аз гына шик-шөбһә булса, бул син сак.

Бу дөнья юлында тукталыш кына,
Һәрбер тукталышта корма зур бина.

Үтүчәндер – вакыт үтеп тора ул,
Булучандыр – көн дә бер хәл була ул.

Фани дөнья өчен көймәс галимнәр –
Киләсе дөньяга үзен хәзерләр.

Үләсен белгәннәр юкка куанмас,
Үлемне күргәннәр артык юанмас.

Юлаучы юлында өй корып тормый,
Китүче кирәген өйдә калдырмый.

Бу дөнья юлында тукталыш кына,
Һәрбер тукталышта корма зур бина.

Бу дөнья әйбере изге түгелдер,
Чөнки закун-заңы үзгәртелер гел.

Бәдәл[2] кылды дөнья малын изгеләр,
Заһитлар дөньядан тәмам дүнделәр.

Күренмәс тозакчы ул – дөнья малы.
Күзәтеп, уйланып белдем мин аны.

Бу дөньяда бәндә кыла гафиллек:
Тозакка керә дә, үз-үзен белми.

Ни ди, ишет инде, шагыйрьләр башы
(Бу дөнья эшендин сакланмыш кеше):

Бар дөньялык бергә җыелсачы бер,
Мең ел дәвам итсә иде бу гомер.

Юк икән, табышың – кара җир асты,
Аның түшәнәге – җара җир[3] – каты.

Бары төшкенәдер кичәр гомерләр:
Ниләр кылган булсаң, төштә күренә.

Үкенсәң дә беркөн, нәтиҗәсе юк,
Ни кылсаң, шул анык – ел, ай, көн танык.

Яшәү татлылыгы бу өч нәрсәдән:
(Һәрберсендә бардыр йөзәр тәркибәт)[4]

Сөенерлек инде ул өч шатлыгы.
Калган өчкә килик, и ил олугы:

Иң әүвәл – кешенең үлем казасы,
Үлем татлы түгел, Адәм җәзасы.

Аның соңында ул угыл-кыз торыр,
Имгәклеге белән алар биздерер.

Ни ди, ишет, әнә акыл бирүче:
«Хатын һәм балалар алыр бар көчне.

Хатын белән җылы сөхбәт соңында,
Бәкегә чумдыра сине бу дөнья».

Татлы кайда булса, татсызы бергә,
Сөчектән соң тиздән ачысы килә.

Ни ди, ишет, әнә акыл бирүче:
«Хатын һәм балалар алыр бар көчне.
Хатын белән җылы сөхбәт соңында,
Бәкегә чумдыра сине бу дөнья».

Яшәү татлылыгы шулай килгәчтен,
Бигүк ямьле түгел дөнья сөхбәте.

Яшәве татлы да, ачыдыр үлем,
Төнгә алмашына бу якты көнем.

Тегеөч шәй – бөтен дөнья ләззәте,
Нәтиҗәсен тыңла, и холкы рәтлем.

Дөнья рәхәте, тән – ул җанына яу,
Бу яу корган ике ягыңа да ау.

Өченче яу – дингә хыянәт ясы[5].
Бу яуны һичкемгә Ходай язмасын.

Болар бергә була камаган дошман,
Җаныңа дошманлык менә шулардан.

Дәвамы бар ■

[2] Бәдәл — изге эшләргә (хаҗга h.б.) акча бирү.
[3] Җара җир — кара катлам астындагы сары җир, комлык h.б.
[4] Тәркибәт — тәркип өлеше, состав өлеш. КБтә, нишләптер, бу «өч нәрсә» әйтелми. Монда лакула бар бугай.
[5] Яс – «траур» (КБтә күп тапкыр килә, татар сөйләшләрендә дә бар).

«КИҢӘШСЕЗ СҮЗ БАШЛАМА...»

(Әсән Кайгының тормыш юлы һәм иҗаты)

Марсель Әхмәтҗанов

Әсән Кайгы Сабит улы – Олуг Мөхәммәд ханның якын кардәше һәм киңәшчесе, Алтын Урда дәүләтенең һәм соңрак Нугай Урдасының зур шагыйре, фикер иясе, дәүләт эшлеклесе.



Әсән Кайгы дөрбәсе. Казакъстанның Кызыл Урда өлкәсе, Шиели районы. 2006 ел

Идегәй би үтерелгәч, 1419 елдан Олуг Мөхәммәд хан Сарай шәһәрендә тәхет иясе була. Әсән Кайгы да бу вакытларда аның хозурында йөргән. Шагыйрьнең 1419 елдан алдагы елларда да Олуг Мөхәммәд юлдашы булуында шик-шөбһә юк.

Тәхет өчен дәгъвачылар Алтын Урдада фетнәләр күтәреп, Олуг Мөхәммәдне тәхеттән төшерергә тырышкан. Шундыйларның берсе — Чыңгыз хан нәселеннән Борак бине Койырчык бине Ырыс бине Чимтай 1427 елда Олуг Мөхәммәдкә каршы Ак Урдадан килеп сугышып йөргән. Олуг Мөхәммәд аны җиңеп, Ак Урдага качарга мәҗбүр итә. Хан үзенең бу җиңүе турында 1428 елның 14 мартында

Госманлы солтаны Газый Морад IIгә хат язып җибәрә. Ул хатында Туктамыш хан заманыннан соң Алтын Урда дәүләтенең эчке ныклыкка ирешүен, фетнәче Боракны җиңүен белдереп, ике ил арасында дуслык һәм сәүдә итешү турында тәкъдимнәр ясый. Олуг Мөхәммәд кебек кешедә Әсән Кайгы дәүләт иминлеген күргән һәм аның белән язмышын бәйләгән. Хан кыен хәлләрдә калган вакытта да аны ташлап китмәгән.

Әсән Кайгы турында беренче мәгълүмат тарихчы Корбангали Халидинең (1846-1913) «Тәварихе хәмсә» хезмәтендә теркәлгән. Бу китапта Алтын Урдада Туктамыш ханнан соң, Сарай шәһәрендә тәхеттә утырган Тимер Котлыг ханның оныгы Кече Мөхәммәд 1437 елда фетнә күтәреп, Олуг Мөхәммәд ханны Сарайны ташлап чыгарга мәҗбүр иткәнлеге языла. Олуг Мөхәммәд башта Кырымга юнәлә, аннан атасы Эчкеле Хәсәннең әүвәлге биләмәсе булган Болгар Олысына барырга карар итә. Әсән Кайгы бу вакытта да Олуг Мөхәммәд тарафдары булып, хан белән бергә Болгар Олысына китә.

Олуг Мөхәммәд Болгар Олысына барганда үзенең 3000 кешелек халкы белән Ука елгасы буендагы Белёв шәһәре янына килеп туктый. Шулвакыт ханның үз кулыннан Мәскәүдә идарә итү өчен ярлык алган Василий II нче аның лагерена хыянәтчел рәвештә һөҗүм итә. Рус гаскәрендә 40000 сугышчы була. Олуг Мөхәммәд хан шактый өлкән яшьтә булуына карамастан, үзенең 3000 кешелек гаскәр башында торып, князь Василий II гаскәренә һөҗүмгә ташлана. Мондый кыюлыкны көтмәгән рус гаскәре тетрәп кала һәм котлары очып кача башлый. Василий II татарлар кулына әсирлеккә төшә.

Олуг Мөхәммәд князьгә, аның кешеләренә руслар әсир татарларга карата эшләгән вәхшилекне эшләми. Рус князенең үз җаны өчен куркып, тетрәп торганын күреп, аңа зур йолым хисабына әсирлектән котылырга тәкъдим ясый. Василий II бу тәкъдимгә бик теләп риза була.

Шагыйрь Әсән Кайгы шушы үрнәк нигезендә дәүләт башында торучының нинди булырга тиешлеген күргән. Шагыйрьнең аңа табынып яшәве, хан үлгәнче, 1445 елгача дәвам иткән. Олуг Мөхәммәд үлгәч, Әсән Кайгы, Болгар Олысы нигезендә барлыкка килгән Казан ханлыгыннан кардәш җиде ыруны ияртеп, Түбән Иделгә, Дәште Кыпчакка күчеп китә. Аңа ияреп китүчеләр — канлы, чаншклы, керей, уак, табын, теләү, тама ырулары. Бу ыруларның этнонимнары бүгенге көнгә хәтле Урта Идел топонимнарында саклана: Канлы — Иске Кандал авылы, Уак — Увек шәһәре (хәрабәләре), Табын — Тамбов шәһәре һ. б.

Әсән Кайгы Урта Азия якларына күченгәндә исә анда бер-берсенә бәйсез үзбәк, казакъ, мангыт дәүләтләре оешу дәвере була. Болгар олысыннан Әсән Кайгы белән килгән ырулар да әле аерылмаган. Аларның бүлгәләнүе соңырак, беренче казакъ ханнары, Кечек Мөхәммәд оныклары Кирәй һәм Җанибәкләр чорында (1459-1480 елларда) булган.

***

Казакъ, кыргыз, каракалпакларда сакланган риваятьләргә караганда, Әсән Кайгы Сабит улы нindидер Хәсән хан нәселеннән килгән шәхес булган. Хәсән хан кем? Ул кайда яшәгән?

Олуг Мөхәммәд ханның атасы Эчкеле Хәсән Алтын Урданың башкаласы Сарайда 1368-1369 елларда хан булып торган һәм үз исеменнән акча суктырган. Хаҗитархан олысы солтаны Хаҗи Чиркәс тарафыннан Сарайдан көч белән куалап чыгаргач, Хәсән хан Болгар олысына китә һәм анда идарә итә башлый. Хәсән Яңа Болгарда (Яңа Казан) солтан булып торганда, аңа Суздаль һәм Түбән Новгород князьләренең берләштерелгән һөҗүмнәре булганлыгы рус елъязмаларыннан мәгълүм.

Хәсән солтан алардан зур йолым түләп кенә котылып кала.

Руслар 1376 елда янә Казанга һөҗүм иткәндә, Хәсән һәм Мөхәммәд солтаннарның исемнәре телгә алына. Атаклы инглиз нумизматы Стэнли Лэн-Пуль Болгар Олысын Олуг Мөхәммәд ханның нәсел биләмәсе, дип карый һәм 1438 елда аны үзенең ата-бабалары йортына китте, ди. Болгар Олысы җирләре Алтын Урда төзелгән вакытта ук Җучиның улы Тука-Тимергә тапшырылган була. Шәҗәрә буенча карaганда, Олуг Мөхәмәд бине Хәсән бине Али бәк бине... бине Түләк Тимер бине Сарыча бине Үрәң-Тимер бине Тука-Тимер бине Җучи.

Инглиз галиме хезмәтендә исеме мәгълүм булмаган Түләк-Тимер улы, 1486-1488 елларда фарсы телендә язылган «Могазз ал-ансәб» исемле чыганакта Җаные дип теркәлгән. Бу фарсы чыганагында Хәсән солтанның Мөхәммәд ханнан тыш Кәнбий исемле кызы барлыгы да күрсәтелә. Мөхәммәд ханның без белгән Мәхмүдәк солтан һәм Касыйм солтаннан тыш, Дилшад исемле кызы булганлыгы да теркәлгән. Әлбәттә, бу шәҗәрәгә Хәсән солтанның да, Олуг Мөхәммәд ханның да барлык балалары да кергән, дип әйтеп булмый. Керми калган исемнәр дә бар. Мәсәлән, рус тарихи чыганакларында Олуг Мөхәммәд ханның Якуб исемле улы искә алына, ә фарсы чыганагында — юк.

Әсән Кайгыны тудырган ананың исеме — Салиха. Казакъ риваятьләрендә аның әтисе Сабит — сунарчы булып, гаиләсе янына бик сирәк кайтып йөргән, дип сөйләнә. Әгәр алай гына булса, Әсән Кайгы Олуг Мөхәммәдкә якыная алыр иде микән! Ихтимал, ул ханга әнисе ягыннан кардәш булгандыр. Анығрак әйткәндә, ул Олуг Мөхәммәд апасының яки сеңлесенең улы булса кирәк. Бу фикерне рус галиме Г.Н.Потанин язып алган мәгълүматлар да раслый: *«Роды Керей и Уак — пришельцы Средней Орды: пришельцами они считаются потому, что в то время, когда люди трёх сотен, уш-юз, образовали из себя три отдельных племени, был некто по имени Асан Кайгы, из потомков Хасен хана. Этот Асан Кайгы, желая переселиться в край, где не бывает зимы, разведывал о землях и, перебравшись в Джийдели-Байсын, местность за Бухарой, остался там и послал семь человек к народу трёх сотен (уш-юз) пригласить их (прикочевать)...»* Бу мәгълүмат нәкъ менә Әсән Кайгының Олуг Мөхәммәд атасы Хәсән солтанга онык булганына дәлил булып тора да инде.

К.Халидинең тарихи хезмәтендә Әсән Кайгы Чыңгыз хан бәкләреннән Майкы бинең алтынчы буын вәкиле, ул Олуг Мөхәммәд ханга буйсынучы, аның хезмәткәрләренең берсе, асылы «нугай», дип язылa. Бүгенге Татарстан Республикасының берничә районында бабалары Майкы бигә (яки Байкы бигә) барып тоташкан нәсел шәҗәрәләре табылуы мәгълүм. Бу инде Әсән Кайгы нәселенең вәкилләре хәзер дә яши, дигән фикерне алга сөрә. Мәсәлән, чукынып руслашкан кенәз Асаковларны күп кенә галимнәр Әсән Кайгы нәселеннән булырга тиеш, дип уйлый.

Әсән Кайгының намаз-нияз беләп яшәп, аның көлмичә, кайгылы яшәгәнлеге дә бәян ителә. Шунлыктан аңа «Кайгы» дигән кушамат бирелгән, дигән фикер теркәлеп калган. Ул бик акыллы киңәшләр бирә алган. Хәтта ханнар да аңа киңәш сорап килгән. Мәсәлән, хан бер кеше турында: «Аны бәк кылсам ничек булыр?» — дип сорагач, Әсән Кайгы: *«Торнадан җасаул куйсаң, башыңнан кайгы китмәс, затсыздан түрә куйсаң, җортың морадына җитмәс»*, — дип җавап биргәне мәгълүм. Әсән Кайгыдан: *«Күп, күп заман узар. Карагай башын чуртан чалар»*, — дигән мәкаль-әйтем дә калган.

Шагыйрьнең туган елын һәм

җирен казакъ галимнәре Идел буе белән бәйли, 1361-1370 елларда дип тәгаенлиләр. Әсән Кайгы имам Мәгъзам кызы Гөлҗазирәгә өйләнгән. Бу никахтан уллары туган, аңа Абат дип исем кушканнар. Алар утрак тормыш белән яшәгән.

Казакъ мәгърифәтчесе Чокан Вәлиханов Әсән Кайгының Җидесу өлкәсендә (хәзерге Алма-Ата шәһәре тирәләре) күчеп йөргәнлеге хакында мәгълүмат калдырган. Бу галим аның «нугай акыны», ягъни татар икәнлеген дә белгән.

Шагыйрьнең исеме һәм атасының исеменнән күренгәнчә, ул мөселман традицияләре нык сакланган гаиләдә үскән, дини гыйлемгә ия, укымышлы, урта гасыр татар әдәбияты белән таныш булган. Шунлыктан аның шигырьләрендә дала халкы өчен хас булмаган гарәп-фарсы алынмалары еш очрый: гадел, залим, галим, нәләт (нәләт яугыры), асыл, кызметшең (хезмәтчең), хош (хуш), гареп (гарип), карияләр (авыллар), кадерен, мөритен (мөрид), пир, адам (кеше), әзиз (газиз), нәпсе, дәүләте, аргымак, акылыңа (гакыл), айыбын (гаебен), менези (мәне) һ.б.

Татар шәҗәрә материаллары күрсәткәнчә, Нугай Урдасын төзүдә катнашкан күп халык Кырым, Идел-Урал, Себер, Әстерхан, Касыйм якларында яшәүче хәзерге татарларның этник тарихында зур эз калдырган. Әсән Кайгы да Идел буйларында, Болгарда туып, Казанда яшәп, Сарай шәһәрендә тәрбия алган, үзенең гыйлемен бөтен Дәште Кыпчакка чәчкән.

Атаклы җырау гомеренең соңгы елларын Урта җүздә, Сырдәрья буйларында уздырган. Казакъ галимнәре аның үлгән елын 1465 дип тәгаенли. Әсән Кайгы Сары Аркада үлеп, Олытауда күмелгән. Аның кабере өстенә дөрбә корылган. Дөрбә Казакъстанның Кызыл Урда өлкәсе, Шиели районында урнашкан. Сакланышы яхшы, дәүләт карамагына исәпкә алынган. Аның төзелешеннән Әсән Кайгының шактый ук бай кеше булганы аңлашыла.

***

Әсән Кайгы ханнар белән яхшы ук таныш булганга, дәүләт мәнфәгатьләрен кайгыртып, ил өчен борчылып яшәргә, иҗат итәргә өйрәнгән һәм шул карашларына гомере буе тугры калган. Аның шигырьләрендә гаделлек һәм гаделсезлек, игелек һәм явызлык, әхлак һәм азгынлык, байлык һәм ярлылык, зирәклек һәм ахмаклык, бәхет һәм хәсрәт темалары чагылыш таба. Шагыйрь, халык гамен чигеп, аның киләчәк язмышы өчен борчылып, хакимнәрнең уйламый эшләгән гамәлләре өчен хәсрәтләнеп яши. Әсән Кайгы әсәреннән бер өзек:

Гаделлекнең билгесе —
Белә торып бормаса.
Акыллының билгесе —
Үткән эшне кумаса.
Җаманнарның билгесе —
Җауга каршы тормаса.
Залимнәрнең билгесе —
Казна малын урласа.
Наданнарның билгесе —
Белгәннең телен алмаса.
Үлсәң калыр адың юк,
Тередә даның булмаса.

Шагыйрь мактанчык, комсыз, дуслыкны санламаган адәмнәргә менә нинди киңәшләр бирә:

Аргамакка мендем дип,
Арткы төптән адашма:
Көнендә үзем булдым дип,
Киң пәйилгә талашма;
Артык өчен әйтешеп,
Дусларың мән санашма.
Гыйльмем җорттан ашты дип,
Киңәшсез сүз башлама,
Җиңәмен дип берәүне
Үтрек сүз мән кыстама.

Әсән Кайгының шигъри мирасында туганнар арасында җәнҗал куптармау-

га өндәгәннәре дә бар. Мондый әсәрләр урта гасыр классик әдәбиятында очрамый. Әсән Кайгы иҗаты исә саф дөньяви мотивлар белән яши. Ул вакыттагы югары катлау өчен хас булган мөнәсәбәтләр, интригалар, сүз уйнатулар анда юк диярлек. Һәр фикере ачык, аңлаешлы итеп әйтелә, халык әдәбияты традицияләрендә бирелә. Шәһәр мәдәнияте, дини тәрбия, Аллага сыгыну кебек китаби үгетләр анда күренми. Әсән Кайгы шигырьләрендә стихияле милли тәрбия хакимлек итә.

Шагыйрьнең тормыш тәрбиясе — тирә-як. Чагыштыру объекты сыйфатында сайланган җәнлекләр, кошлар кешегә бик якын. Автор тудырган табигать төрлелеге адәмнең күңел халәтен, гамәлләрен, уңай һәм тискәре сыйфатларын тасвирлауга хезмәт итә:

Эсти китсәң кем димә,
Бере тойгын табылмас;
Карендәшең җаманлап,
Үзеңә туган табылмас.

Сүз иң яхшы лачын — тойгын (ак лачын) — каз йә аккош ала торган ау кошы турында бара. Мондый лачын бик сирәк булган һәм бары ханнарда гына очраган. Шагыйрь, ак лачынны эзләп китсәң, таба алмассың, дип, туганыңны яманласаң, үзеңә башка туган таба алмассың, дигән фикер әйтә. Дөньяда идеаль кешеләр юк, туганың яхшымы ул, яманмы — барыбер синеке булып кала.

Инде адәмнең икенче бер сыйфатына — гаделлегенә карата Әсән Кайгының фәлсәфәсен карап үтик:

Гаделлекнең билгесе —
Белә торып бормаса.
Акыллының билгесе —
Үткән эшне кумаса.

Бу юлларда, кешенең ялгышын төзәтеп, аны дөресләгән инсан гына гадел була ала, дигән фикер ята. Акыллылык билгесе ул — элекке ялгышлардан котылып, кылган гамәлләреңә нәтиҗә ясап гомер итү. Әсән Кайгы — җәмгыятьтәге тискәре күренешләр белән көрәшү тарафдары булган:

Бу заманда ни гарип?
Ак чәнечкеле кылган гарип.
Җакшыларга әйтмәгән
Асыл татлы сүз гарип.

Шагыйрь карашынча, чәнечкеле дала кылганының файдасызлыгы, акыллы кешеләргә әйтелмәгән татлы сүз бер үк дәрәҗәдә бәяләнә.

Әсән Кайгының ахырзаман җитү, кешеләрнең үзгәрүе, бозылуы турындагы шигыре аның фәлсәфәче буларак тагын бер ягын ача:

Мондан соң хили-хили
заман булыр,
Заман азып, заң тузып,
җиһан тулыр,
Карагайның башына чуртан чыгып,
Боларның дәүраны тәмам булыр.
Ул көндә карендәштән хәйер китәр,
Ханнан — көн, карагайдан
чабыр китәр,
Улың-кызың руска бу дәм булып,
Хәйран ил — Идел-йортым
шунда китәр.

Җыраунын бу шигырендә Идел буе, Идел-йорт язмышы, аның киләчәге турында борчылу ята. Әсән Кайгы Идел-йортка киләсе афәтләрне алдан, Казанда яшәгән чагында ук күргән, чөнки ул күршедә генә зур куркыныч өлгереп килүен, акыл иясе буларак, алдан ук тоеп торган. Шушы киләчәк аны куркыткан булса кирәк. Бәлки, Казаннан китүенең дә төп сәбәбе шул булгандыр.

Дәвамы бар ■

ТУКАЙ ТУРЫНДА ИСТӘЛЕКЛӘР

Вафа Бәхтияров

ДУМАДА ТӘМЛЕ ЙОКЫ

1908 елны Казанда шәһәр идарәсенә сайлау үткәрелә. Бу сайлауда да күп еллар Казан шәһәр идарәсендә гласный булып торган Шәмсевәли байны сайлыйлар. Бу кеше татар байлары арасында урысча аңлый, аз булса да сөйләшә белүчеләрнең берсе, иске фикерле, үзен бик зур кеше итеп танучы бер карт иде. Беркөн Тукай, мин, Агиев[1] — өчәүләп Кабан күле (хәзерге Комсомол урамы) буйлап барганда, яңа сайланган Шәмсевәли Гыйззәтуллин үз йортының (номеры — 16/1) капка төбендә бер кеше белән сөйләшеп тора [иде]. Болар турына килеп җиткәч, мин:

— Шул инде яңа сайланган Шәмсевәли Гыйззәтуллин, — дидем.

Без күргәндә башында энҗеле кәләпүш, өстендә көмеш төймәле озын казаки иде. Шул күрүдән соң, безнең тиктормас Тукай түбәндәге шигырен язды:

Качан ләкте миңа бу язгы сайлауда гласныйлык;
Югары мәртәбә килде — олуглык һәм дә важныйлык.

Керештем әһле ислам файдасын саклар вә якларга,
Яңа көч берлә башладым гырылдарга вә йокларга.

АЛТЫ ЕЛЛЫК ОБРАЗОВАНИЕ

Тукайның Казанда торган дәверендә Казан яшьләре арасында Солтан Рахманколый дигән бер яшь җегет бар иде. Бу җегет Реальный училищеның (хәзерге пединститут йорты) алтынчы классын бетереп, укуны ташлый. Тәрҗемә эшләрен[ә алына] һәм вак сәүдәгәр, бай бәтчәләрнең йомышчысы булып йөри. Пивнойдан пивнойга йөреп, эчүчеләрнең кәефләрен табар өчен мандолина уйнап, эчүчеләр хисабына эчеп йөри, һәм башкалар...

Тукай бу кызганыч җегетнең мондый хәлдә йөрүен үз күзләре белән күреп бу шигырен язды:

Бул кеше: бай бәтчәләрнең калдыгы хәмерен көтеп,
Алты еллык образованиеңне йөрмә селкетеп.[2]

Башы журналның 4 нче санында.

[1] Фәхрелислам Агиев — профессиональ татар балалар язучысы, мөгаллим, журналист, нәшир.

[2] Солтан Габделмән улы Рахманколый (Рахманколов) (1888-1916) «Сәяси яктан ышанычсыз» табылып, Реальный училищедан куыла. Күрәсең, Тукайның Солтанга тәэсире бик нык булган: 1907 елда ул «бай бәтчәләрне» ташлап, язучылык эшенә керешә. Язучы, тәрҗемәче, җырчы буларак тарихта якты эз калдыра.

Бу мәгълүмат Исмәгыйль Рәмиев белән Рәис Даутовның «Әдәби сүзлеге»ннән алынды.

ОЧА ТОРГАН МУЛЛАЛАР

Галимҗан Баруди

Казанның зур байларыннан, шәһәрдә зур-зур йортларга, районнарда җир-суга, урманнарга хуҗа булган, «мәшһүр» Галимҗан мулла Баруди турында Ишмөхәммәт мулла Түнтәри (Ишми ишан) патша хөкүмәтенә донос ясый. Шул доностан соң, турыдан-туры (ягъни, милли идарә аркылы булмый), эчке эшләр министры тарафыннан Барудиның муллалык указы алына һәм мәдрәсәсендә дәрес әйтүдән-укытудан тыела. Үзен Казанда тотмаска әмер ителә.

Шул вакыйгадан соң Баруди берничә ел Истамбулда вакыт үткәрә. Петербург муллалары, «Нур» газетасы наширләре Гатаулла һәм Сафа[3] Баязитовларның ярдәмнәре аркасында яңадан Казанга кайта. Эш тәмам җайлана. Бары тик кулда муллалык указы гына юк. Бу эшне дә җайламакчы булып, Эчке эшләр министрлыгында яшерен эшләр бүлегендә чиновник һәм мулла булган[4] Сафа Баязитов белән бергә берничә тапкыр эчке эшләр министрында булалар. Ничектер, бу кызганыч бәндәләрнең эшләре барып чыкмый. Тукай бу караңгы, серле эшләрне ишетә дә түбәндәге шигырьне язып чыга:

— Райта, райта, райта, райта, райтарам!
Шул көйгә бассаң, указыңны кайтарам.

— Яхшы, рәхмәт, мин басам, сүзсез басам;
Яхшы хәтта шатлыгымнан очмасам.

— Тимпа, тимпа, тимпа, тимпа, тимпатам!
Очсана, мин җөббә чабуыңнан тотам.

---

[3] Сафа Гатаулла улы Баязитов (1887-1937) бик тирән белемле кеше булса да (ул әүвәл «Мөхәммәдия»дә, аннары Петербургта гимназиядә, соңыннан Петербург университетының шәрык телләре факультетында гыйлем алган), татар дөньясында әллә ни мәшһүрлек казана алмый. 1915 елда аны мөфти итеп куялар. 1917 елда мөфтилектән алалар. Сафа Баязитов кешелекле, ярдәмчел булса да, аны татар зыялылары ни өчендер өнәп бетерми? Күрәсең, ул милли мәсьәләдә умырткасыз булгандыр. Гаепсезгә төрмәгә ябыла, шунда һәлак була. Вафатыннан соң аклана.

[4] Редакциядә бу турыда мәгълүмат юк. «Татар энциклопедиясе» аны Тышкы эшләр министрлыгында тәрҗемәче булып эшләгән дип күрсәтә.

Әйдә, хәзрәт, ач канатың, юлда бул;
Мин вәкилмен, син указлы мулла бул.

Син яңа булсаң да, хәзрәт, искесең,
Син җәдит, ләкин ишансың, изгесең,

Ни гаҗәп, бирсә сиңа Тәңре канат;
Ярлыга биргән кеби ул җиккән ат.

Бу икәү очты Петербурга таба,
Каргалар күктә сәламли «мәрхабә»!

Очтылар хәзрәт, вәкил — күп очтылар,
Тик, тәәссеф[5], җиргә егылып төштеләр.

ГӨМБЕРТ!

1908 елда Төркиядә солтан хөкүмәтенә каршы революция була. Бу революция төрек гаскәре тарафыннан ясала. Селаник[6] шәһәрендә булган гаскәри корпуслар Шәүкәт Ниязи, Әнвәр командалыгында баш шәһәр Истамбулга поход ясыйлар. Истамбулны һәм Йолдыз сараен кулга алалар. Солтан Габделхәмит кулга алына. Утыз елдан артык [тәхет тоткан] Хәмит монархиясе бетерелә. Яңа конституция төзелеп, Габделхәмитнең энесен идарә башына утырталар (1909). Шул зур вакыйганы телеграммаларда, газеталарда укып, Тукай түбәндәге шигырьне язды:

Утыз ел хөр фикерләрне үлтерт,
Төрекләрдә азатлык тамрын корыт.
Ватан яктыртучы шәмнәрне сүндерт,
Мөселманнан бөтен читләрне көлдерт.
Утыз ел казыган баз бик тирән шул:
Менә инде Хәмитең шунда гөмберт!

БАЛДАК ТУРЫНДА ҖЫРУ

Төркия солтаны Габделхәмит үзе рухи авыру (психопат) булганлыктан, илне идарә итү эшләре Йолдыз сараендагы җарияләр башлыгы, сарай фалчысы, хәйләкәр, усал, үзсүзле, кире Мөхлимә исемле карт бер гарәп кулында була. Габделхәмит нинди генә бер эш булса да, бу хәйләкәр Мөхлимәгә фал ачтырмый эшләми булган. Кыскасы, [Мөхлимә] солтан исеменнән ил [белән] теләсә ничек идарә итә. Илне бөтенләй бөлгенлеккә китереп җиткерә. … Илебездә октябрь революциясенә кадәр Николай Икенче сараенда Распутин нинди роль уйнаган булса, Мөхлимә дә Хәмиднең Йолдыз сараенда шул рольне артыгы белән уйный.

Бу хәйләкәр, ирлек тойгысы бетерелгән («сөннәткә утыртылган») Мөхлимәнең солтан Хәмит белән берлектә революция гаскәрләре тарафыннан кулга алынганын, төрмәгә озатылганын Тукай газеталарда укый да түбәндәге җырны җырлый башлый:

---

[5] Тәәссеф — кызганыч.
[6] Хәзер Селаник шәһәре Грециядә.

Мөхлимәләр балдагы төрек халкын алдады.
Алдаласа алдаласын, үкенечкә калмады.[7]

КОРЪӘН ЯЛАУЧЫ БОЗАУЛАР

1908 елның җәендә Иранда хөкүмәт үзгәреше ясала. «Идарәи мәшрутия» (Идарә Конституциясе) игълан ителә. Шулвакыт Иранда шаһ-падишаһ булган Мөхәммәт Галидән яңа конституциягә кул куйдырыла һәм Гали яңа конституция[гә таянып] ил [белән] идарә итәргә ямин-ант итә, сүз бирә.

Милли собрание — парламентка сайлаулар була. Берничә тапкыр халык тарафыннан сайланган парламент полковник Ляхов командасында булган урыс казаклары көче белән таратыла. Иранда булган шул вакыйгаларны укып, тик-тормас Тукай түбәндәгеләрне язып чыга:

Җөгралмадым, җиталмадым, тоталмадым үрдәкне;
Иран халкы онытмыйдыр шаһтан күргән «хөрмәт»не.

Ник бүген барча бозау Коръән үбә, Коръән ялый? —
Хәзрәти шаһ, бел ки, биш-алты йәмин йоткан бүген.

ЭТ ӨЕРЕ

Октябрь революциясенә кадәр Казанга һәм илебезнең башка шәһәрләренә күпләп-күпләп бәдәлчеләр (кеше өчен хаҗга йөрүчеләр) килә торган иде. Бу хәерчеләр «изге» җирдән төрле туфрак, балчык, әллә нинди сулар китереп, халыкка саталар. Авыруларны өшкерәләр, төкерәләр. Сөю, сөйдерү өчен язулар, сөйдерү-көйдерү өчен бөтиләр язып тараталар. Үзләрен изге җирләрдән, Мәккә, Мәдинә шәһәрләреннән килгән, Аллага якын, изге кешеләр итеп күрсәтәләр. Аш мәҗлесләренә, туйлардан калмый йөриләр. Мәҗлесләрдә Коръән укыйлар, изге җирләрдә булган хәлләрне, төрле вакыйгаларны сөйләп, халыкны ышандыралар. Бу паразитларның башлыгы — татар, Мәккәдә торучы Морад исемле бер хәерче. Морад бервакыт «Русия мөселманнарны» исемендә бер китап та язган иде. Бу ялганчы паразитларның халыкны алдап акча җыюларына Тукай түзми, түбәндәгеләрне яза:

Хәтфә калфак киштәдә, эшләнәдер Бистәдә;
Морад кебек теләнчене күрәлмассың төштә дә.

Бәдәлчеләр, мәккәчеләр йөри Казан шаулатып;
Бер сөяккә унлап эт бар, чәйнәшәләр даулашып.

Ике туры ат җиктердем, берсен сыңар тәртәгә;
Баш хәерче Морадлары чыкмый ята Мәккәдә.

[7] Бу юллар Габдулла Тукайның «Авыл җырлары (беренче көлтә)» әсәреннән. Язу тарихларын төрле итеп күрсәтсә дә, «Коръән ялаучы бозаулар» бүлегендә Вафа Бәхтияров янә шушы ук шигырьдән өзек китерә. Моны автор әсәрләрдәге теге яисә бу юлларның (тулаем шигырьләрнең түгел!) язылу тарихына игътибар итә, дип аңларга кирәк, күрәсең.

Франц Иосиф һәм Фердинанд куәтсез, ярдәмчесез солтанның җирләрен тартып ала. Le Petit Journal тышлыгы. 1908 ел

КОМСЫЗ АВСТРИЯ

1908 елның җәендә Австрия-Венгрия императоры [Франц] Иосиф Төркиянең иң бай [вилаяте] булган Һәрсәк-Боснияне (хәзерге вакыт Югославиядә)[8], Төркиянең көчсез чагын туры китереп, сугышсыз, кан коймый гына гаскәри көч белән басып алып, Австро-Венгриянең бер кисәге дип игълан итә. Шул хаксызлыкны Тукай күрә дә шул ике юл шигырь яза:

Ни сәбәптән өрмиләр этләр, тынычланган җиһан?
Боснияне йотканда Австрия тончыккан бүген.

ЧУКЫНГАН ИБРАҺИМ

Казанда Айтуганов фамилиясендә бер бай бар иде. Йорты хәзер дә бар әле. Тукай урамы, «Чаткы» кинотеатрының[9] күршесе, № 62.

Бу байның Исмәгыйль, Ибраһим исемле ике улы бар иде. Бу бай үлеп китә. Аталарыннан соң, бу икәү төрле юллар белән аталарыннан калган бөтен байлыкны туздыралар. … Болар ел саен ике тапкыр, яз-көз айларында Мәскәүгә яки Петербургка киенер өчен генә бара торган булганнар. Татар халкын яратмыйлар. «Казан портнойлары матур итеп, килештереп тегә белмиләр. Татарлар культурасыз, былчырак, шакшы халык», — дип сөйләп йөриләр. Татар арасында тормыйлар, урыслар арасында торалар. Бигрәк тә Ибраһим шулай була. Берничә еллар үткәч, болар бик авыр хәлгә килеп төшәләр. Байлык бетә. Эш белмиләр. Исмәгыйль татар байларының төрле йомышларын үти, агент булып йөри. Ибраһимы? бик аптырагач, урыс карагруһларына, миссионерларына сатылып, ул вакыттагыча әйткәндә, «рәсми рәвештә чукына». Карагруһлар бу бәндәгә үлгәнче ай саен 30 сум акча түләргә сүз бирәләр.

Тукай бу сатлыкҗанның шундый хәлгә килүен ишетә дә, шул ике юл шигырьне яза:

Ай туганда тусаңчы, айдай нурлы булсаңчы;
Яшьләр йөзен кызартканчы, каралтканчы үлсәңче!

АЛТЫН ТАРТА

1908 елда «Вакыт» газетасы идарәсеннән Казан яшьләренә берничә кешегә хат килә. Алар «Вакыт», «Шура», «Чүкеч» идарәләренә хезмәткә чакырыла. Дөресе … Фатыйх Кәримовның … картаеп бара торган сеңелләренә укымышлы кияүләр кирәк була. … Чакырылучыларның берсе шагыйрь Тукай була. Бу яшьләрнең берсе дә күнми, каршы җавап та язмыйлар. Иң соңыннан Борһан Шәрәф … Оренбургка күчеп китә.

Тукай шушы вакыйгадан соң түбәндәге җырны җырлады:

Безнең урам аркылы ага суның салкыны;
Тарта Казанның яшьләрен Рәмиевләр алтыны.

---

[8] Хәзерге вакытта Босния һәм Герцеговина мөстәкыйль дәүләт.
[9] Хәзерге вакытта Габдулла Тукай исемендәге кинотеатр.

АТА КҮРКӘ

1908 елның җәендә Казанның «Бәянелхак» газетасында бер игълан басылып чыга. Игъланда болай язылган була: «Зур ата күркә өйдән чыгып китеп югалды. Кем табып китерсә яки күргәнен килеп белдерсә, ул кешегә бер сум акча бирелә! Адрес: Ак мәчет мәзине Габделбәдигъ».

Тукай шул игъланны «Бәянелхак» газетасында күрә дә, әллә нәрсә булган кебек кызыксынып, шаркылдап көлә. Шуңа карап, кызык-кызык сүзләр, төрле-төрле анекдотлар чыгара. Берничә көннән соң түбәндәге җырны җырлап йөри башлый:

Башыңдагы чабатаңның сиксән сигез серкәсе;
Бу дөньяда шөһрәт алды Бәдигъ мәзин күркәсе.

Ялгышмасам, [Тукай] «Яшен», «Ялт-Йолт» көлке журналларының берсендә шул Бәдигъ мәзиннең ата күркәсен Аурупа илләренә дә сәяхәт иттереп, Париж шәһәренә китереп чыгара. Париж шәһәренең төрле мәйданнарында сәяси нотыклар сөйләтә. … Ахырда бу ата күркәне, күркәлектән чыгарып, Госдума депутаты Садри Максуди итеп күрсәтә.

ЮГАЛГАН УКАЗ

Бозаулык шәһәренең имамы Галиәсгар Гафуров (Чыгтай) шул вакытның алдынгы, укымышлы һәм тирән мәгълүматлы таңчыларыннан иде. Шулвакыт татар газеталарына туктаусыз язып тора иде. 1908 елда Г.Гафуровның «Исабәт» исемле китабы басылып чыга. Бу «Исабәт» Ислам диненең кайбер хөкемнәренә каршы төстәрәк язылган иде. Искелекне сөючеләр бу эшкә каршы торып, дини идарәгә һәм хөкүмәткә донос ясап, Г.Гафуровның указын (муллалык язуын) алдыралар. Г.Гафуров яңадан указын кайтарып алу теләге белән берничә тапкыр Уфага, дини идарәгә барып кайта. Г.Гафуровның указ артыннан йөрүен Тукай ишетә дә «Мәҗрух указ» («Җәрәхәтләнгән указ») дигән шигырен язып чыгара[10].

АЯК АСТЫНДАГЫ БАЗ

Казанда Һади Максуди тарафыннан чыгарыла торган «Йолдыз» газетасы, күп таралу теләге белән, динче татарларның рухларына карап, Ислам дөньясы турында төрле хәбәрләр һәм фәлсәфәләр сата; Төркия турында, бигрәк тә Болгар сугышы турында ялган хәбәрләр тарата. Ислам илләренең алга китүләре, аларның культурасы турында язып торуына Тукай чыдап тора алмый, түбәндәге шигырен язып чыгара.

Бераз йолдызчылар бардыр киң күктән йолдыз эзлиләр,
Түбәнгә күз дә салмыйлар, һаман күкләрне күзлиләр.

Салалар фәлсәфәләр, уралар дин хикмәтән.
Аяк астындагы базны күрмиләр шул хәлдә гафләтән[11].

Максуди бу эшкә бик күңелсезләнеп, кеше аркылы үпкәләвен дә белдерде.

Дәвамы бар ■

[10] Тукай Чыгтайның «үкенү»еннән «Авыл җырлары»нда да көлә: «Җаңгыр җава сибәләп, төймә-төмә төймәләп, / Чыгтай мулла үкереп җылый, «тәүбә, тәүбә, тәүбә»ләп».
[11] Гафләт — наданлык.

ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

Сәхифәне филология фәннәре докторы, профессор ЗӨФӘР РӘМИЕВ алып бара.

БЕЛИНСКИЙ Виссарион Григорьевич (1811-1848), урыс фикер иясе, язучы, тәнкыйтьче, публицист. Тукай аның турында Уральскида, урыс сыйныфында укыган чакта ук ишетсә дә, әдәби-эстетик һәм иҗтимагый карашларыннан хәбәрдар булмаган, күрәсең. Гыйльметдин Шәрәф истәлегеннән күренгәнчә, Казанга килгәч, ул шәһәрдәге урыс уку йортларында укыган яисә шундый уку йортларына керергә омтылган, урыс әдәбиятын яхшы гына белгән татар егетләренең Белинскийны (ягъни, заманында Пушкинны тәнкыйтьләгән кешене!) гаепләп сөйләүләренә, аны Писарев белән чагыштырып бәхәсләшүләренә тап була һәм башта үзен бу даирәдә уңайсыз хис итә («сахра малае» кебек тоя). Ләкин бераздан аларның мәгълүматлары әллә ни тирән булмавына төшенә («Алар минем алда учительдән алып кайткан шул көндәге сабакларын сөйләшеп йөргәннәр икән»).

Белинскийның (шулай ук Чернышевский, Добролюбов, Писаревларның) «Тукайга идея тәэсире булганлыгы» турында беренче мәртәбә И.Г.Пехтелев яза. И.Нуруллин фикеренчә, Тукай Уральскида чакта әле аларны укымаган. Аңа бөек урыс тәнкыйтьчеләренең әсәрләре белән Казанда гына «теге яки бу дәрәҗәдә танышырга» туры килгән. И.Нуруллин Белинский нигезләгән эстетик мәсьәләләр (реализм, халыкчанлык, әдәбиятның иҗтимагый роле, тәнкыйть принциплары) Тукайга зур йогынты ясаган, әдәби-эстетик карашлары тәмам формалашуга әһәмиятле роль уйнаган, дип саный.

Зөфәр Рәмиев ■

Әдәбият:

Пехтелев И.Г. Пушкин, Лермонтов, Тукай. К.,1949. – 128 с.; Нуруллин И. Тукай эстетикасы. К.,1956. – Б.66-67; Шәрәф Г. Тукай тугърысында истә калганнар // Тукай турында хатирәләр. К.,1976. – Б.76-77; Гордлевский В.А. Г.Тукай и русская литература // Слово о Тукае. К., 1986. – С.62.

КАЛӘМДӘШЛӘР ИГЪТИБАРЫН ТОЕП...

30 сентябрь, 1980 ел
Татарстан Язучылар союзының шагыйрьләр секциясе чираттагы утырышка җыела.

Утырышта катнашалар: Хәсән Туфан, Нури Арслан, Фәрваз Миңнуллин, Илдар Юзеев, Равил Фәйзуллин, Рәдиф Гатауллин, Әхмәт Рәшитов, Шамил Маннапов, Мөдәррис Әгъләмов, Мансур Вәлиев, Рашат Низамиев, Рәшит Әхмәтҗанов, Җәүдәт Дәрзаманов, Рәфикъ Юнысов, Кави Латыйпов, Әхмәт Гадел, Хәйдәр Гайнетдинов, Рәүф Зәйнуллин, Роберт Миңнуллин, Марсель Галиев, Рөстәм Мингалимов, Роберт Батулла, Тәүфикъ Әйди, Илсөяр Ганиева, Ләис Зөлкарнәев, Ркаил Зәйдуллин, Асия Минһаҗева, Нәбирә Гыйматдинова, Айрат Садыйков, Газинур Моратов, Ләбиб Леронов, Энҗе Гыйрфанова, Әмир Мәхмүдов, Салисә Гәрәева, Булат Сөләйманов, Зөлфәт, Разил Вәлиев, Ринат Мөхәммәдиев, Венера Ихсанова, Фирдәвес Әһлиуллина.

Көн тәртибе: Салисә Гәрәева һәм Булат Сөләйманов иҗатларын тикшерү.

Кичәне секция җитәкчесе Рәдиф Гатауллин (Рәдиф Гаташ) алып бара. Беркетмәне теркәп баручы — шагыйрь Әхмәт Рәшит.

1. САЛИСӘ ГӘРӘЕВА ИҖАТЫН ТИКШЕРҮ

Шагыйрә Салисә Гәрәева иҗаты турында Рәшит ӘХМӘТҖАНОВ сөйли:

— Салисә Гәрәева белән бер чордарак яза башладык, алтмышынчы еллар башында. Һәм шулвакытта ул үзенең поэзиясе белән йөрәккә үтеп керде. Шигырьләре — эчкерсез, самими, музыкаль, образларга бай. Урал турындагы шигырьләре дә бик әйбәт тәэсир калдыра. Беренче китабы, «Уралым», юмарт булмаса да, җылы тәнкыйть тә ишетте. Үзем дә яратып укыдым. Салисәне Язучылар союзы члены булырга лаек, дип саныйм.

Рәдиф ГАТАУЛЛИН:

— Инде сүзне Салисәнең үзенә бирик.

Салисә ГӘРӘЕВА:

— Мин Уралда, Чиләбе шәһәрендә яшим. Профессиям буенча журналист. Өлкә татар-башкорт әдәби берләшмәсен җитәклим. Беренче җыентыгым — 20 еллык иҗатым нәтиҗәсе. Шигырьләрне Чиләбедәге урыс шагыйрьләре тәрҗемә итә, алар газета-журналларда, күмәк җыентыкларда да басылып чыга. Иҗатта да, тормышта да эчкерсез, фальшсыз буласы килә. Без әдәби

Илдар Юзеев

Нури Арслан



Хәсән Туфан

берләшмәдәге иптәшләр белән татар әдәбиятын пропагандалау буенча да Уралда эш алып барабыз. Казаннан читтә булсак та, бәйләнешләр өзелми — дуслар белән дә, туган республика белән дә. Татар әдәбияты белән бер аяктан атларга тырышабыз. *(Шигырьләр укый.)*

Рәдиф ГАТАУЛЛИН:

— Хәзер, иптәшләр, Салисәнең иҗаты турында фикер алышыйк.

Нури АРСЛАН:

— Иҗатына килгәндә... Салисә үзенең туган ягыннан, Минзәләдән, Казаннан китсә дә, иҗат итүеннән туктамады. Урал турында да шундый матур шигырьләр яза белде, ул туган ил горизонтларының гаять киң икәнен күрсәтте. Шигырьләре табигый, ясалма түгел *(мисаллар китерә)*. Йә, кайсыбыз болай әйтә белде?

Икенче ягы, бик оригиналь ягы шунда аның иҗатының — шигырьләре хатын-кызларга гына хас нәфислек, нечкәлек, эчкерсезлек белән аерылып тора *(мисаллар китерә)*.

Бу шигырьләр чын шигърият, чын художество әсәрләре:

Күкрәкләре шыткан үсмер кызлар
Атлый тәүге яшьлек язына.

Мин Салисәгә моннан 20 еллар элек өметемне баглаган идем. Аклады ул минем өметләрне. Салисәнең рәссамлык сәләте дә бар. Бу инде нур өстенә нур. Беренче җыентыгын бик яратып, ләззәтләнеп укыдым. Башка язучылардан да җылы фикерләр ишетеп торам. Бу да әһәмияткә ия. Шагыйрә иҗатын дәвам итә. Ул безнең арада булырга тиеш.

Рашат НИЗАМИЕВ:

— Нечкә мәхәббәт шигырьләре яза белүе белән бергә, Салисә иҗатында ир-атларча кыю да. Саф мәхәббәтне ул характер дәрәҗәсенә күтәрә ала. Бу өлкәдә алга таба да эшләр, чөнки Салисә — лирик шагыйрә.

ЗӨЛФӘТ:

— Безнең халык ил буйлап таралган, талантларыбыз энҗе кебек сибелгән. Чиләбе, Урал дигәндә, без Салисәне, Камил Мостафинны искә төшерәбез. «Уралым»да миңа бигрәк тә мәхәббәт лирикасы ошады. Монда олы сөю бик табигый һәм нечкә бирелгән. *(Китапны күрсәтә)*. Бу китапны мин бик теләп, яратып укыдым. Салисәне СССР Язучылар союзына тәкъдим итәм.

Энҗе ГЫЙРФАНОВА:

— Салисә белән без Чиләбедән, бер әдәби берләшмәдә кайнашабыз. Салисә иҗаты турында сөйләгәндә, аның поэтик осталыгы турында ассызыклап әйтергә кирәк, образлы фикер йөртү, шиксез, шигъри таланты бар. Ул оештыру сәләтенә дә ия.

Хәсән ТУФАН:

— Мин Салисә кызымның шигырь-

Салисә Гәрәева


Булат Сөләйманов


Рәдиф Гаташ

ләрен яратып каршы алдым. Кайсы шагыйрь беләндер, хәзер анык әйтә алмыйм, Салисә шигырьләрен укыгач, без беравыздан «бу кыздан шагыйрь чыгачак», дидек. Аның иҗаты игътибарга бик лаек. Үзебезнең шагыйрәләр иҗаты турында без бик аз язабыз.

Илдар ЮЗЕЕВ:

— Беренче китабын Салисә шагыйрә буларак чыгарды. Аның китабына эчке рецензияне мин язган идем. Поэзиягә производство, эшче темасын алып керү — гаять авыр эш. Салисә моны уңышлы башкарды. Уралда яшәп, эшче темасын яктырту буенча шагыйрә бездән уздырып җибәрде.

Мин «Уралым» җыентыгы белән Салисәне СССР Язучылар союзына тәкъдим итәм. Аның иҗатына киләчәктә дә зур өметләр баглыйм.

Әхмәт РӘШИТОВ:

— Хәтерлим, Татарстан язучыларының I съезды көннәрендә Тукай клубында үткән шигырь кичәсендә Салисә шигырьләр укыды. Халык шулкадәр яратып кабул итте, кул чаптылар, залдан язулар килде. Чынлап та аның шигырьләре җанга ятышлы иде. Әле бүген укыган яңа шигырьләре дә безнең игътибарны җәлеп итә.

Рәдиф ГАТАУЛЛИН:

— Салисәнең интим лирикасын әрмән шагыйрәсе Сильва Капутикян поэзиясенә тартым, дияр идем мин. Ягымлы, эчкерсез, музыкаль, табигый агышлы алар. Урал, завод, эшчеләр темасын ул киләчәктә дә үстереп, яңа югарылыкка күтәрер, дип ышанам. Салисәнең инде яңа китабы әзер, ул иҗат итүен дәвам итә. Чыгыш ясаган иптәшләр фикеренә кушылып, мин дә Салисәне СССР Язучылар оешмасында член булырга лаек, дип саныйм.

Шамил МАННАПОВ:

— Без Салисә белән Казан университетында бергә укыдык, әдәби түгәрәкләргә бергә йөрдек, әдәбиятка бер чорда килдек. Аның шигырьләре гражданлык тойгыларының өстенлеге, фәлсәфи уйланулар белән аерылып тора.

Мин Салисә иҗатын күзәтеп барам, яратып укыйм. Салисәне СССР Язучылар союзында әгъза булырга лаек, дип саныйм.

2. БУЛАТ СӨЛӘЙМАНОВ ИҖАТЫ ТУРЫНДА

Докладчы Шамил МАННАПОВ сүз ала:

— Кешеләр — агачлар кебек. Кайберләрен күчереп утыртасың да, алар тамырланып үсә башлый. Булат та шундый. Ул Себердә, Төмән өлкәсендә яши. Казанда һәм Мәскәүдә белем алды. Себер егетенә олы шагыйрьләребезнең дә игътибары күп булды. Себер кешеләренә

Әхмәт Рәшитов

Зөлфәт


Мөдәррис Әгъләмов

хас тырышлык, үҗәтлек белән иҗат итә Булат. Аның «Таңнар фонтаны» дип исемләнгән беренче шигырьләр җыентыгын укучылар җылы каршы алды. Без татымаган җимешләр монда. Халык рухы ныклыгы чагыла. Без аның белән Себердә, Иртыш буенда йөрибез. Булат туган ягының матурлыгын образлар аша ача. Самотлор, нефтьчеләр, факеллар. Уңышлы шигырьләре күп булса да, әле аның чын шигърият булып җитмәгәннәре дә бар. Эзләнүчән шагыйрь. Җиңел юмор да бар анда. Равил Фәйзуллин, Ренат Харис шигырьләренә охшаган шигырьләре дә бар. Башкаларны кабатламасын иде. Фикер кыска, эчтәлеге бай булсын. Себер егете Казаннан китсә дә, татар шагыйре буларак, мул җимеш бирер, дип ышанабыз.

Рәдиф ГАТАУЛЛИН:

— Инде сүзне Булатның үзенә бирәбез.

Булат Сөләйманов шигырьләр укый. Үзе турында, әдәбиятны пропагандалау эшен алып баруын, халык арасында чыгышлар ясавын әйтеп үтә.

Рөстәм МИНГАЛИМОВ:

— Булат Сөләймановны 1962 елдан беләм. Университеттан бирле. Булат әдәбиятка гашыйк. Озак формалашты ул. Сәбәпләре дә бар аның. Тормышны белә Булат. Ул төбәктән килүчеләр булды — югалдылар. Булат югалмады, көрәште, язды, җыентык чыгарды. «Юность» журналы да аның шигырьләрен бастырды. Мәскәү шагыйрьләре дә белә аны, яраталар. Булат — җир шагыйре, мәшәкатьләре күп аның. Нәшриятларны да кысмый ул, яза бирә. Җитдиләнергә җае бар шагыйрьнең. Язучылар союзына алырга кирәк, дигән фикерне куәтлим.

Мансур ВӘЛИЕВ:

— Без «Идел»дә *(альманах — Л.Л.)* чыгардык Булатны. Шигърияттә ике юнәлеш белән бара ул: Себер тормышы һәм мәхәббәт лирикасы *(мисаллар китерә)*. Бу китап — иҗат юлын билгели торган китап *(мисаллар китерә)*. Язучылар союзына член булырга лаеклы Булат.

Хәсән ТУФАН:

— Бу егеткә нык ярдәм итәргә кирәк. Бездән китеп, яу килгәч Казанны коткарырга килгән Себер татарлары вәкиле ул. Тубыл елгасы буйлары, Иртыш, Урманбаш авылы. Әйтергә теләгәнем — ярдәм итәргә кирәк егеткә. Югалмасын иде шагыйрь. Җылы күңел белән арабызга алырга, ярдәм итәргә иде. Стилистик яктан.

Әхмәт ГАДЕЛ:

— Шагыйрь тыйнак кеше булырга тиеш. Булатта ул сыйфат бар. Саф, намуслы кеше. Шигырьдә дә үз фикерен тыйнак кына әйтә ул. Китабын сөенеп

укыдым. Җитлеккән шагыйрь. Безнең арага алырга кирәк. Ул үзебезнең культурага тартылды, үзләштерде, җиңеп чыкты. Әйбәт дус ул. Казанга тирән мәхәббәт белән яши. Үз халкының патриоты. Язучылар союзы члены булырга лаек.

Мөдәррис ӘГЪЛӘМОВ:

— Китабын нәшрияткa тәкъдим иткәндә төп докладчы мин идем. Әйбәт шигырьләре күп аның. Булат — шагыйрь. Шагыйрь бар. Аның яңа китабы әзер *(мисаллар китерә)*. Булатны 15 ел буе күзәтеп барам, техникада аксаган чаклары бар, ләкин ул — шагыйрь *(мисаллар китерә)*. Салмак, акыллы итеп яза Булат.

Илдар ЮЗЕЕВ:

— Булатның тыгыз фикерле шигырьләре бар. Булат, кеше буларак та, шагыйрь буларак та үсештә. Себер характерын ачу өстендә тагын да эзләнер әле Булат. Ул яктан Якуб Зәнкиев китап язды. Бай тарих! Гражданлык тойгылары белән язарга кирәк. Булатка өмет зур.

Рәдиф ГАТАУЛЛИН:

— Булатны күптән беләм. 1961 елдан бирле шигырьләре басылып бара. Иҗатында актив. Китабына да игътибар булды. Яңа әйберләре күп. Таләпчәнлекне арттырырга кирәк булыр. Безнең яктан да таләп зур булыр.

Иптәшләр! Тавышка куям: кем дә кем Салисә Гәрәева белән Булат Сөләймановны Язучылар союзына кабул итәргә дигән тәкъдимне хуплый — кулларыгызны күтәрегез.

Тәкъдим бертавыштан хуплана.

Карар: Салисә Гәрәева һәм Булат Сөләймановны бертавыштан СССР Язучылар союзына тәкъдим итәргә.

Председатель Р.Гатауллин
Секретарь Ә.Рәшитов

Беркетмәне журналга
***Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

ХАТЛАРДА – ЮЛЛАР, ЮЛЛАРДА – ЕЛЛАР

Ләбиб Лерон

Архивымда Татарстан Язучылар берлегенең 1960-1980 еллардагы эшчәнлегенә кагылышлы документлардан торган байтак папка бар. Мин аларны, Татарстан Язучылар берлеген Бауман урамындагы Матбугат йортыннан Комлев (хәзерге Мөштәри) урамындагы ГИДУВ бинасына (14 йорт) күчерешкән чакта, кирәксезгә чыгарылып, идәнгә ташлап калдырылган чүп-чар өеменнән табып алган идем. Беркөнне шул папкаларны актарып, документлар белән танышып утырганда, ике хатка юлыктым. Алар ике чордашкаләмдәшнең — Тәүфикъ Әйди (1941-2001) белән Булат Сөләймановның (1938-1991) бер-берсенә язган хатлары булып чыкты. Мин бу ике әдип белән заманында күпмедер дәрәҗәдә таныш идем, үзләре белән якын дуслар ук булмасак та, ара-тирә күрешкәләп, үзара аралашып яшәдек, һәрдаим дустанә мөнәсәбәттә булдык. Үз вакытында икесенә дә ихлас күңелемнән шигъри багышлаулар яздым: Булат абзыйга — 1988 елда илле яше тулу уңае белән котлау шигыре («Казаннан җилләр исмәсә…»), Тәүфикъ абыйга — 1992 елда «Казан утлары»ның 70 еллыгы уңаеннан дүртьюллык эпиграмма:

Язмыш өзгәләп ташлаган
Җепләрне табып бәйли:
Училап сибелгән татарны
Бөртекләп җыя Әйди.

Шунысы кызык: әлеге күренекле шәхесләребезнең биографиясендә бер уртак үзенчәлек бар — алар икесе дә язучы яисә шагыйрь булып танылганга

кадәр бик күп һөнәр үзләштергән: әйтик, Тәүфикъ Рамазан улы — китапханәче, ташчы, милиция хезмәткәре («Божра» дигән детектив повестен язуда авторга шушы һөнәре этәргеч булмадымы икән әле?), слесарь һәм аппаратчы, укытучы, методист, әдәби хезмәткәр, Булат Вәлиулла улы исә — йөкче, бетончы, маляр, китапханәче, балта остасы, нефтьче-оператор, слесарь-сантехник, әдәби хезмәткәр.

Хатлардан аңлашылганча, язмышның ачысын-төчесен шактый татыган бу ике әдип бер-берсен яхшы белгәнгә охшый, шул хатлардан чыгып гоман кылсак, аларның язышып хәбәрләшүләре бер-ике генә булмагандыр, дигән фикергә киләсең.

Булат Сөләйманов — Тәүфикъ Әйдигә

Сәлам, Тәүфикъ дус!

Хатыңны һәм җибәргән справка кәгазен алдым. Ләкин, кызганычка каршы, бик соң иде. Бүген — 15 нче октябрь һәм миңа, Союздан «Сиңа хат бар», дип шылтыраттылар. Сәбәп бер генә. Мин эшләгән бюропропаганда үзе аерым бер йортта урнашкан. Ә Союз — Дом Советовта, икенче җирдә. Мин ул җиргә (Союзга) бик сирәк барам. Ә эш урынымда көн саен булам һәм шунда ук яшим дә. Әгәр дә Бюрога җибәргән булсагыз, вакытында аладыр идем, бик барасым килгән иде.

Тәүфикъ!

Син әдәби консультант булып вакытлыча гына эшлисеңме, әллә урнашыпмы? Законлы эш урының булса, бик шәп булыр иде. Безгә үзебезнең егетләр булуы хәерлерәк.

Аннан минем сиңа бер үтенечем бар. «Идел» альманахын җибәр әле, 2 данә, быелгысын. Казанга килеп чыксам, бер гөрләшеп алырбыз. Җәй очрашканда сез каядыр китеп бара идегез, шуның аркасында гөрләшеп булмады. Ярар, әле соң түгел, алда гомер бардыр әле безнең.

*Мөсәгыйт абыйга (Хәбибуллин. — **Л.Л.**) һәм Лирон абыйга (Хәмидуллин. — **Л.Л.**) сәлам әйт. Ни өчен килә алмаганымны аңлат. Ярар, үзем хат язармын.*

Кабат сәлам белән, Булат.
15.10.1976 ел

Тәүфикъ Әйди — Булат Сөләймановка

Булат дус!

ВЛКСМ Өлкә комитетына ышанып, сезгә чакыру соңрак җибәрелде. Килә алмавыгыз кызганыч. Син үзең комсомол кушуы буенча үз хисабыгызга килерсең, дип уйлаган идек, ә алар әйтмәгән, ахры.

Семинар уңышлы узды. Программасын җибәрәм. Башкортстан, Ульян өлкәсе, Мәскәүдән егетләр бар иде. 100ләп кеше җыйдык.

Мин вакытлыча эшлим, яхшы теләкләреңә рәхмәт.

Булат, син анда татарча язучы авторларны барла инде. Мәктәпләрдә булганда игътибар ит, өмет — өлкән класс укучыларында. «Яшь ленинчы», «Ялкын»да басылучы якташларыңны эзләп тап. Сүз алып барырлык кешеләр очраса, шәхси семинарга чакырырбыз. Укучы булса, үзең алып килерсең. Синең Төмәндә, уңайлы урында утыруыңнан татар әдәбиятына да файда тисен.

«Идел»не китап-почта кибете җәмгысе 10 данә җибәрер. Син аны татар әдәбиятын сөючеләргә автограф белән сатып бирерсең.

Булат, без «Идел»не айлык журналга әйләндерү артыннан йөрибез. Шуңа күрә аны хәзер үк укучылар белсен, сорасын иде. Җирлек әзерләргә кирәк. 1977 елга ике сан планлаштырыла.

Төмәндә татар әдәбияты сатыламы? Сатылса, ул кибет «Идел» альманахына да заказ бирсен иде. Темпланда «резерв» дип кенә куелган, кереп сөйләшә алмассыңмы? Синдә темплан бармы? Хат язгалап тор.

Уңышлар теләп, сәлам белән:

Татарстан Язучылар союзының консультанты — Т.Әйди.

25.10.1976 ел ■

ФУАТ АГА ЯДКЯРЕ

Наилә Гәрәева
Мәскәү

Быелның гыйнварында аңа, XXI йөзгә туры килгән нәүбәттәге Яңарыш чоры вәкиленә, 87 яшь тулыр иде... Әмма дөньялыкның үз кануннары: Язмыш галиҗәнаплары боерып, 2010 ел аны арабыздан алып китте. Узган җәй каберенә һәйкәл куелды (авторы – яшь сынчы Фәнил Вәлиуллин). Әлеге чарада Фуат ага Мансуровның туганнары, танышлары, Татарстан Республикасының һәм Мәскәүнең күренекле җәмәгать вә сәнгать эшлеклеләре, маэстроның иҗатына баш игән башка бик күп кешеләр катнашты.

Бронза дирижёр таякчыгын күтәргән хәлдә тынып калган. Чү! Борчымагыз! Илһам килгән вакыт! Челтәрләп эшләнгән чардуганга Сергей Рахманинов ноталары сибелгән… Хәзер, оркестрга ым кагып, кулы белән генә ишарәләсен дә… илаһият дөньясына күмелербез…

КЕМ ИДЕГЕЗ СЕЗ, МАЭСТРО?

Фуат Шакир улы Мансуров — тулы бер дәвергә тиң шәхес, аны, ихтимал, тулы бер Галәмгә тиңләсәң дә мөмкиндер. Бу галәмдә саннар теориясе тирә-юньгә моң тараткан оркестр гармониясе тарафыннан дөресләнә… Ул — шахмат тактасындагы король, тау түбәсен яулаган ак барс, дирижёрлык таякчыгын канат итеп бөтен дөньяны урап чыккан үткен күзле бөркет… Ялкынлы, дәртле музыкант буларак, Фуат Мансуров — буйсындыручан рационалист һәм ягымлы романтик та, ул тыңлаучыларга оркестр аша иң нәзберек җилнең исеп куйган тавышын, берничә йөз метр биеклектә, тау очында, таш катламнары арасында үскән эдельвейсның исен дә җиткерә алырлык куәткә ия. Шул ук вакытта, искитмәле рәссам да — кызына бүләк ителгән гаҗәп кызык «елак төлке» рәсеме, кайбер мәгълүм шәхесләрдән көлгән дустанә шаржлары… Күп телләр белгәнгә күрә, ул бар җиһан белән уртак сүзгә килә алды, һәр халык белән аның үз телендә сөйләште; берничә уен коралында уйный белгәнлектән, һәр музыкантны аңлады, һәркайсына хәл кадәри ярдәм кылырга тырышты. Ничәмә оркестрлар белән җитәкчелек итте, бөтен дөнья буйлап сәхнә тотты! Дача төзегән вакытта, гап-гади кешедәй, рәхәтләнеп бүрәнә юнудан да тайчынмады, тантаналы чакларда (юбилеенда, мәсәлән), Бөек Маэстро мантиясен ябынып, горур төстә күренә дә белде.

Фуат Мансуров бик сөйкемле, мөлаем, көләч шәхес, эчкерсез, шаян

Анна Пипич фотосы

әңгәмәдәш, искитмәле хикәяләүче иде, ул һичкайчан да һавалы булмады, борын чөймәде, һәрнәрсәдән файда гына эзләргә омтылмады, фәкать көй дөньясында яшәде, анда йөзде. Шул ук вакытта, профессиональ музыкага кагылышлы мәсьәләдә аяусыз дәрәҗәдә таләпчән, үз сүзендә нык торучан була белде. Музыка аның асылы, яшәвенең мәгънәсе иде... Ул сәнгатьнең әлеге гүзәл өлкәсенә караган барлык бүләкләрне, премияләрне алып бетерде, хәтта Халыкара Фәннәр Академиясенең академигы исеменә лаек табылды. Шунысын искәртү мөһим: Россия дирижёрлары арасында бу исемгә ирешкән бердәнбер кеше ул.

Фуат Мансуров кырык ел буе Россия Дәүләт Академия Зур театры оркестрын, Татарстан Республикасының Дәүләт симфоник оркестрын җитәкләде, шушы аралыкта куелган концертлары, чыгышлары аны данга күмде, исемен бөтен дөньяга яңгыратты. Бөек музыкант һәм легендар шәхес буларак, Фуат Мансуров исеме бүген дә хәтердән китми, телдән төшми.

Әмма бу триумф нәрсәдән башланды соң? Аның тамырлары кайда? Әлеге сорауларга җавап табар өчен, маэстроның тормышындагы фактларга нигезләнеп язылган ошбу бәянга мөрәҗәгать итик...

ЯСМИН ҺӘМ МУЗЫКА

Татьяна, янбакчага чыккач, тәрәзә төбендә бөгәрләнеп яткан малайны күреп таң калды. «Тәтием, нишлисең син монда?» — дип сорады. Якынгарак килгәч, күрде: биш яше тулар-тулмас нарасый йокыга киткән икән. Куркытмаска тырышып, сак кына, иңнәренә орынды ул, әмма сабый селкенмәде. Шуннан соң малайның йөзен сыйпап алды. Тегесе иренеп кенә күзен ачты, каршысында таныш булмаган ханымны күреп, тертләп куйды: «Ой... Кайда мин? Музыка... Кайдадыр музыка ишеткән идем кебек... Ә-ә-ә... Изрәп киткәнмен, ахры...» Бу вакытта Татьяна Николаевна Расторгуева яшәгән агач йортның ачык тәрәзәсеннән агылган җыр өзелде, «тәлинкә» уйнап бетергән, күрәсең — әле генә Массненың «Элегия»сен башкарган Фёдор Шаляпин тынып калган.

Искитмәле җылы кич иде бу... Караңгы төшеп килә. Җәйге челләдә җылынган һәм төрле-төрле үсентеләр, үләннәр, чәчәкләрнең хуш исе белән баетылган һава сабырлык, тынычлык, рәхәтлелек тойгысы тудыра иде. Шушы баш әйләндергеч исләр белән илаһи көйләр кушылмасыннан әсәрләнеп, Фуат янә ясмин куаклары арасына елышты, сихерләнгән сыман, ачык тәрәзәдән агылган музыка иленә кереп китте. (Сабый чагында ук җанына сеңеп калган бу хисләр, бу исләр һичкайчан аның исеннән чыкмаячак, киләчәктә дә ясмин чәчәген ул музыканың матдиләшкән рәвеше итеп күрәчәк, шуңа инанып яшәчәк.) Көн дәвамында җил куып хәлдән тайган нарасый, музыка тылсымына бирелеп оеп китсә дә, йокы куенына чуммаска тырышты, күзләрен зуррак ачты... әмма керфекләренең авыраеп, күз кабакларының йомылганын сизми дә калды, көй ерайгады, ерагайды, отыры эреп юк булды... Татьяна килеп уятмаса, шулай күпме вакыт узар иде икән?

Фуатның элгәре дә монда килгәне бар иде. Нәрсәдер тартамы соң, нәмәгълүм, вәләкин ул көн дә тылсымлы рояль тавышы, Шаляпин, Карузо, Нежданова, Головин, Собинов кебек күренекле җырчыларның җырлавы агылган тәрәзә төбенә килеп укмашырга гадәтләнде. Музыка аның булмышына үтеп керде, җанын иркәләде, сөйде.

«Синең исемең ничек? Фуатмы?» — дип сорады Татьяна Николаевна, беркадәр иелә төшеп. Малай шул арада кызарып, «әйе» дигәндәй баш какты. «Сине югалтканнар иде бит... «Фуат! Фуат!» дип кычкырганнарын ишетмәдеңмени? Йә, табылганыңа рәхмәт... — Ханым шулай сөйләнәсөйләнә, нарасыйны җитәкләп, Ман-

Кечкенә Фуат (уңда) энесе һәм апасы белән. 1940 нчы еллар

суровлар торган йортка юл тотты. — Бу яшьтән үк музыка белән кызыксынган балаларны күргән юк иде әле. Гадәттә трай тибү белән мәш киләсез... Беләсеңме, син теләгән вакытта килә торган бул. Мин сиңа бик күп кызыклы хәлләр сөйләрмен. Затлы музыка тыңларбыз».

Алҗауданмы, кыенсынуданмы, Фуат җавап кайтармады. Әмма аксөякләр затыннан булуы күренеп торган бу гүзәл ханымның тәкъдиме күңеленә хуш килде. Нинди матур бит ул, әнә: кара озын итәктән, ак блузкадан, алтын чәчләре баш өстендә җыелып куелган, йөзе нур бөрки... Теләмәгән җиреңнән ризалашырсың!

Озакламый алар кирәкле йортка килеп җитте. Баксаң, бер-берсеннән әллә ни ерак та яшәмиләр икән: урамның каршы ягында, дүртме-бишме өй аркылы гына... Сабыйны әүвәл куркып калган, ә аннары куанычыннан нишләргә белмәгән ата-анага тапшырып, Татьяна Николаевна китәргә ашыкты. Шулай да, Фуатны тагын бер кат кунакка чакырырга онытмады.

Әнисе: «Улым, син кайда идең? Без сине югалттык! Кем сине китерде?» — дип каршылады аны. «Хәзер эләгәчәк» дигән куркуы да булгандыр, соңарып кайтканга үзен гаепле дә сизгәндер, күрәсең, Фуат нибары: «Мин анда... музыка тыңладым», — дип кенә җавап кайтарды. Шулвакыт малайның күзләрендә ут очкыннары балкып куйганын ата-ана сизми калмагандыр, шөт. Сабый түшәккә сузылып яткач та озак вакыт йоклап китә алмый боргаланды, ишеткәннәрен яңадан хәтергә төшерде: колагында оркестр уйнады, Шаляпин, Нежданова җырлады! Татьяна Николаевна үзенә чакырды ич... Фуат, эченнән куанып, үзе өчен: «Киләчәкмен! Һичшиксез, киләчәкмен! Музыкага киләчәкмен...» — дигән нәтиҗә чыгарды.

«Отвори потихоньку калитку и войди в тихий садик, как тень...» Хәләл җефетен озатып, Татьяна Николаевнаның җырлый-җырлый савыт-саба сөртештергәләве иде. (Аның ире — элеккеге патша армиясе офицеры. Язмышлары шулай язылып, Казакъстанга, Алматы шәһәренә килеп чыга алар.) Кинәт кемнеңдер ишек шакыганы ишетелде. Татьяна урамга бакты. Беркем юк. «Колагыма чалынгандыр, ахры», — дип, хуҗабикә яңадан эшенә керешмәкче иде, кабат ишек кактылар. Кыюсыз гына. Әмма озак итеп. Татьяна Николаевна ашыгып килеп ишекне ачып җибәрсә, ни күрсен: бусагада кичәге танышы басып тора лабаса! Оялып бөрешкән иреннәрендә елмаю күрсәтеп, итагатьле генә исәнләшкәч,

малай: «Менә... мин килдем... чакырган идегез бит...» — диде. «Әлбәттә, әйдә, эчкә уз, — диде Татьяна, алъяпкычын салышлый. — Кәефең ничек? Әти-әниең артык ачуланмадымы?» Һәм, җавабын да ишетеп тормастан, зур бүлмәгә дәшеп алды. Фуат кызыксынып тирә-юньне күзәтеп чыкты: бүлмә уртасында кара рояль тора, янәшәсендә — борынгы диван һәм ике кәнәфи, читтәрәк — язу өстәле, өстәлдә — яшел абажурлы лампа, берничә бронза сын... Дивар төрле-төрле фотосурәтләр белән чуарланган: озын мыеклы, хәрби киемле абыйлар, аклы-каралы күлмәкле апалар. Татьяна Николаевнаны шунда ук таныды ул. Әмма калганнарының кем булуы турында сорарга кыенсынды: «Туганнарыдыр, мөгаен», — дип уйлау белән генә чикләнде. Киштә тулы китап, нота кәгазьләре... Тәрәзә төбендәге кечкенә өстәлгә челтәрле эскәтер ябылган, аның өстендә алагаем зур чәчәккә охшаган «алтын бүрәнкәле» граммофон «утыра». Кырыена пластинкалар тезелешкән. «Менә кайдан агылган икән ул сихри көйләр!» — дип уйлап куйды Фуат, канәгать елмаеп. Беркадәр онытылып торганнан соң, һушына килгәндәй, урыныннан кузгалды, салкын йөгергән кара рояльнең капкачына сак кына орынды, аннары бармакларын клавишларга тидерде: «Каралар, аклар, тигезләр... Ничек ялтырый үзләре!» Аяк очына басып, эчкә үрелде: «Кылы никадәр күп икән! Санап бетермәле түгел!» Бу хәлне читтән генә күзәтеп торган Татьяна Николаевна, ниһаять, яратып кына: «Ә син уйнап кара...» — диде. Фуат түгәрәк урындыкка утырды, аның кечкенә, нәзек бармаклары, сәер авазлар чыгарып, клавишлар буйлап йөгереп узды. Кызык, һай кызык нәрсә икән бу! Озакламый, эшен бетереп, Татьяна Николаевна да килеп җитте. Малай яудырган исәпсез күп сорауларга («ник клавишлар төрле төстә?», «педальләр нәрсәгә кирәк?» һ.б.) җавап биреп үтте, төп ноталар белән таныштырды: «Һәр авазның үз йорты бар. Ике кара клавиш тәрәзә хасил итә, аннан «ре» нотасы карап тора, ә тәрәзәнең ике кырыенда «до» һәм «ми» ноталары борын төрткән. Өч кара клавиш — «соль» һәм «ля» ноталары басып торган балкон ул, янәшәсендә — «фа» белән «си» таптана». Фуат, апасы сөйләгәнне бүлдермим, дип, тын да алырга куркып утырды. Беркадәр вакыттан соң Татьяна Николаевна П.И.Чайковскийның, Р.Шуманның, Э.Григның балалар өчен язган әсәрләрен уйнап күрсәтте, кечкенә Фуатның болай да кызыксыну утында янган йөрәгенә ут өстәде. Малайның күз алдында «Агач солдатлар», «Убырлы карчык», «Тургай», «Кыш бабай», «Кыю җайдак», «Кошлар», «Күбәләкләр» кебек әсәрләрнең музыкаль образлары терелде.

Фуат үзенең өр-яңа дөньяга аяк басканын аңлады. Татьяна апасының рәхмәте белән, малай алдында бүген ул дөньяның барлык ишекләре ачыла төшкән иде.

Бу йортта бик сирәк кешеләрдә генә була торган граммофон аша бар җиһаннан җыелган иң яхшы, иң сирәк «тәлинкә»ләрне, алардагы искитмәле җырларны тыңларга мөмкин иде! Өстәвенә, Татьяна Николаевна рояльдә шундый шәп уйный белә, бик гыйлемле, бөек композиторлар турында сорасаң, бертуктаусыз, озак сәгатьләр буе сөйләргә мөмкин. Кыскасы, классик музыка белән Фуат бик иртә танышты, шулвакыттан ук Лист, Брамс, Бизе исемнәрен күңел киштәсенә салып куйды, моңарчы колагына да чалынмаган дирижёрлар Леопольд Стоковский, Артуро Тосканини турында ишетте.

...Берничә телдә иркен сөйләшкән Татьяна апасы Фуатка француз теленнән дә дәресләр бирә башлый. Татарча белән казакъчаны яхшы белгән килеш (дөрес, урыс теленә төшенеп җитмәгән хәлдә), ул тиз арада французчаны да үзләштерә. Алга китеп, шунысын искәртик әле: күптеллелеге аңа киләчәктә фәкать ярдәм итәчәк, ул кайда яшәмәсен, кая бармасын —

һәр җирдә һәр кеше белән аның туган телендә аралашачак һәм шушы сыйфаты белән дә җирле халык арасында абруй-мәртәбә казаначак.

Фуат, үсә төшкән саен, Татьяна Николаевна гаиләсендәге мәгърифәтлелекне, интеллигентлылыкны ныграк аңлый барачак, үзе үскән гади татар эшчеләре белән Расторгуевлар арасындагы аерманы ныграк тоячак: аның бичара ата-анасы тормышның очын-очка көч-хәл ялгап гомер сөрә ләбаса, нужа чабудан сөйрәгән чакта аларга музыка, сәнгать турында уйлану кая ул!.. Шуңа күрә, тормышындагы чираттагы хәлиткеч адымны да Фуатка Татьяна Николаевна ясата: ул, малайда талант орлыклары күреп, аны үзе җитәкләп диярлек музыка мәктәбенә укырга кертә, талантлы мөгаллим, алман милләтле Отто Оттович Узинг карамагына тапшыра. Ул вакытта бердәнбер «азат» уен коралы виолончель булганлыктан, малайны шул сыйныфка алалар. Үзгә инструментның буш чагы туры килсә, кем белә, Фуат бәлки, трубада, барабанда уйнар иде... Хәер, аның нәрсәдә уйнавы бу очракта, ихтимал, артык әһәмиятле дә түгелдер. Иң мөһиме: биредә классик музыканы тыңларга гына түгел, ә үзеңә дә уйнарга мөмкинлек бар ич! Шул бәхет түгелмени? Музыка дөньясының ишекләре тагын да киерелебрәк ачыла. Дөрес, булмышывөҗүде белән җиргә береккән әтисе генә улының бу «җенләнүенә» шикләнеп карый: «Шул да булдымы ир-ат эше? Һичьюгы, милиционер бул... — дип шаярта ул. Аннары, җитдиләнеп: — Менә математика, ичмасам, шәп нәрсә! Син университетны шул юнәлештә тәмамларга тиешсең», — дип өсти. Чыннан да, Фуат әтисенең сүзен табан астына салып таптамый, математика белгечлеген дә үзләштерә. Бу вакытта егетнең кем булып җитәсе тәгаен аңлашылмый әле: математикмы, музыкантмы, башкасымы? Аны һәрнәрсә кызыксындыра, ул нәрсәгә тотынса, шуны булдыра...

Ә менә ясмин белән музыка Фуатны мәңгегә үзенә бәйләп куя. Хуш исле ясмин чәе аның иң яраткан эчемлегенә әверелә, сөйгән хатын-кызларына кыйммәтле ясмин хушбуйлары бүләк итәргә гадәтләнә ул һәм, билгеле, һичкайчан музыкадан аерылмый. Татьяна Николаевнаның тәрәзә төбендә шау чәчәктә утырган ясмин сыман, Фуатның күңелендәге музыка гөлләре дә үрелеп-үрелеп үсә, үзенең җанын-калебен матурлап кына калмыйча, тирә-юньдәге вазгыятьне дә гүзәл якка үзгәртергә, ямьләндерергә керешә...

НОКТА КУЯР АЛДЫННАН

Фуат Мансуров каберенә Троекурово зиратында таш куелган көнне күккә бихисап ап-ак күгәрченнәр очырылды. Шуларның берсе, гомум күчтән аерылып, һәйкәл өстендә бөтерелде, аннары «ниһаять, тукталыр урын таптым» дигәндәй, бөек музыкантның бронза иңенә кунды һәм озак кына аннан очып китәргә теләмәде. Нәрсә бу? Очраклылыкмы? Әллә мистикамы? Кем белә... Кечкенә чактан яхшылыкка, игелеккә, пакьлеккә омтылып үскән ак җаннар үлемнән соң да һәммә тереклекне үзләренә шулай тартып тора, күрәсең.

*Урысчадан **Рүзәл Мөхәммәтша** тәрҗемәсе.* ■

Ихтимал, татар әдәбияты белән күпмедер таныш кеше Әмирхан Еникинең «Гөләндәм туташ хатирәсе» исемле әсәрен, укып ук булмаса да, һичьюгы, ишетеп беләдер. Бер көн туып, икенче көнне үләргә мәҗбүр күбәләктәй, бик кыска гомер эчендә җилпенеп, канат очларындагы ялтыравыклы бәхет тузанын кагып өлгерергә ашыккан Салих Сәйдәшев (әле яшь музыкант, мөгаллим генә) белән Гөләндәм Солтанованың (сәүдәгәр кызы) мәхәббәт тарихы бу. Кызыклы сюжетка корылган бәянның башыннан алып ахырына кадәр әдәби каһарманнар белән бергә яратып, куркып, борчылып утырсаң да, әсәрнең иң зур интригасы барыбер ахырга кала...

Сәйдәшнең беренче мәхәббәте

Рүзәл Мөхәммәтша



Салих Сәйдәшкә 18 яшь. 1918-1919 нчы еллар

Инде нокта куйдым, дигән җиреннән автор, «Берничә генә соңгы сүз» язып, мәңгелеккә үз иҗат җимешенә бәйләп куя: *«Бу әсәр Казаннан читтә яшәгән бер ханымның кечкенә генә истәлеге нигезендә язылды. Кызганычка каршы, минем үземә аны күрергә туры килмәде — мин эзләп барганда, ул инде дөньяда юк иде (1963 елны вафат булган). Кызы Ләлә ханым белән очрашкач, ул миңа әнисенең Салих Сәйдәшне еш кына искә төшерүен, аның көйләрен пианинода яратып уйнавын, ә үләр алдыннан исә Сәйдәш музыкасын ишетергә теләвен сөйләп бирде. Билгеле, бу әсәрне язганда мин истәлек иясенең исемен үзгәртеп алуны кирәк таптым»*[1].

Чигәгә төбәп атылган ут сыман, бер-бер артлы дистәләгән сорау башка суга. Бу — автор уйдырмасы гына түгелмени? Алайса, әсәр ни дәрәҗәдә документаль соң? Гөләндәмнең чын

[1] Әмирхан Еники. Әсәрләр. Биш томда. 3 том. — Казан: Татарстан китап нәшрияты. — 2002. — Б.399.

Фатыймаи-Зөһрә. 1917-1918 нче еллар тирәсе

Д.Нәүрүзова коллажы

исеме ничек? Кем ул? Кайдан? Казаннан киткәч (китсә?!), кайда яшәгән? Нигә Сәйдәш турында истәлекләр язарга уйлаган? Алар ни рәвешле Әмирхан Еникинең кулына барып эләккән? Мондый уйларның очы-кырые юк!..

«Безнең мирас» журналының почта әрҗәсенә Салих Сәйдәшев музееннан хат килеп төшкәч (әле нинди хат, диген — «Гөләндәм туташ хатирәсе» әсәренә нигез булган кулъязма!), күңел төбендә оеп яшәгән бу сораулар савытыннан ташыган сөт сыман янә күпереп чыкты. Билгеле, шунда ук музейга чаптым. Кулъязманы гарәп имлясыннан кирилл хәрефләренә күчергән Гөлназ ханым Җиһаншина белән күрешеп сөйләштем. Янә бер кат музей буйлап (чү, алай гынамы икән? Сәйдәшстан буйлап ук түгелме?) сәяхәт кылдым. Кадерле аһәңсазыбызның рухына орынгандай булдым...

Билгеле, бу кулъязманы моңарчы да укыганнардыр. Аның белән, Әмирхан агадан кала, ким дигәндә тагын бер кеше — Салих Сәйдәшев музеен оештыруда турыдан-туры катнашкан һәм, гомумән, бөек композиторыбызның һәм матди, һәм рухи мирасын барлауда гаять зур көч куйган зат — Дилбәр ханым Сәинова-Әхмәрова таныш булырга тиеш. (Җөмләдән, ул Шиһап Әхмәровның (Салих Сәйдәшевнең җизнәсе — Әминә апасының ире) килене, Үзбәк Әхмәровның җәмәгате дә.) Ник дисәң, аның шулкадәр яратып, җылы итеп язылган китабында[2] әлеге кулъязмадан өзекләр китерелә. Ләкин хатирәләрне ни сәбәпле тулаем җиһанга чыгарырга уйламаганнар? Нәмәгълүм. Шәхсән үзем һәр сәнгатькярнең, әдипнең иҗаты гына түгел, тормышы да, уңышлары белән бергә уңышсызлыклары да, кыскасы, әлеге шәхескә бәйле һәрнәрсәне кызык һәм әдәбият тарихы өчен файдалы, кирәкле дип санаганга, бу хәлне зур ялгышлык, хата дип кабул иттем. Әмирхан аганың «Татарстан» журналына биргән бер интервьюсы[3] тулысынча шушы темага багышлануга карамастан, кулъязма анда да тәкъдим ителмәгән. Артык еракка киткәнче, шуңа күз салыйк әле. (Гөлназ ханым Җиһангирова, кече күңеллелек күрсәтеп, безгә әңгәмәнең күчермәсен тапшырды.) Олпат язучыбыз болай дип искә төшерә: *«Ул истәлек С.Сәйдәшев үлеп, бераз вакыт үткәч минем кулга килеп керде. Күп кенә кешеләрнең Салих турында яза башлауларын ишеттем. Бездә берәр отышлы тема табылса, шуңа тотыналар бит. Мәсәлән, Муса Җәлил белән шундый хәл булды.*

Мин, киресенчә, ашыкмаска булдым, бу кампаниягә катнашасым килмәде. Истәлекне дә иясенә кире җибәрдем. Аның авторы Ташкентта яшәүче бер ханым иде. Без аның белән башта хатлар да алышкан идек. Күп еллар үтеп китте. Мин яңадан истәлек авторын искә төшердем. Аның үзен барып күрәсе килде. Адресы да бар иде, ләкин мин аны Ташкентта таба алмадым, үкенечкә каршы, ул вафат икән инде... <...>

Минем үземне «Гөләндәм хатирәсе»н язарга этәргән сәбәпләрнең берсе — Салихның яшь кенә туташны әнә шул югары даирәгә алып керүен күрсәтү иде. Шуннан соң ул (Гөләндәмнең кызы. — Р.М.) минем кулыма бер альбом китереп бирде. Шуны актарган вакытта тышсыз гади генә бер дәфтәр килеп чыкты. Бу — истәлекнең копиясе. Казанга килеп, кире киткән истәлекнең беренче нөсхәсе булып чыкты ул... Ханым миңа бу дәфтәрне алырга рөхсәт

---

[2] Салих Сайдашев. Страницы жизни и творчества композитора. — Казань: Татарское книжное издательство. — 2009. — 214 с.

[3] «Хатирәләр» яңарганда...» Татарстанның халык язучысы Әмирхан Еники белән Казан дәүләт педагогика институты аспиранты Әлфия Мотыйгуллина әңгәмәсе. Татарстан ж., №3-4, 1994. — Б.92-94.

Татар дәүләт Академия театры коллективы. Икенче рәт, сулдан икенче – Кәрим Тинчурин; өченче рәт, сулдан өченче – Салих Сәйдәшев. 1927 ел

итте. <...> Ул истәлек миндә. Ханым әнисенең рәсемен дә бирде. Шушы табышлар кулыма кергәч, хатирәмне әкренләп яза башладым. <...> Ташкенттан алып кайткан мәгълүматлар Казанда торган йортларын эзләп табарга ярдәм итте. Өй Касыйм хәзрәт мәчете артында урнашкан, урта кул сәүдәгәр йорты иде. Гөләндәм шунда туып-үскән, Салих шунда килеп йөргән.

Шуннан соң күрше-тирәдә яшәүчеләрдән: «Нинди кешеләр иде? Тормышлары нинди иде?» — дип сораштым. Гөләндәмнең үзе турында: «Бик матур, бик сөйкемле кыз иде, гомумән, бик оригинально — күзләре зәңгәр, чәчләре кара иде», — дип сөйләделәр».

Кулъязманы укыганда Әмирхан ага Еникинең чыганак материалга никадәр якын килеп иҗат итүе, хатирәләрдәге бер генә өтернең дә төшереп калдырмавына таң каласың: ул, уналты битлек истәлекне чүпрә салып кына ике йөз битле бәянга әверелдергән гүя! Бер карасаң, һични өстәмәгән дә кебек, бары матурлаган, бизәгән генә...

Инде табышмакларны чишәр вакыт җиткәндер. Беренчедән, «Гөләндәм»нең чын исеме — Фатыймаи-Зөһрә. Ул, чыннан да, әсәрдәге кебек, Әхмәтҗан Солтанов исемле сәүдәгәрнең кызы. Аның әнисе, чыннан да, әсәрдәге кебек, Сембер ахунының кызы. Дөньяга юксылларның бөек юлбашчысын «бүләк итәчәк» шәһәрдә урыс интеллигенциясе арасында үсеп, алдынгы карашлы хатын булып җитешкәнгә күрә, ул, билгеле, кызын да үз үрнәгендә тәрбияләүне максат итеп куя. Шул рәвешле, Әхмәтҗан ага йортында 18 яшьлек (гомернең бәйрәмгә тиң мизгеле!) музыкант, мөгаллим Салих Сәйдәшев пәйда була...

«Иске» дөньяның нигез ташлары какшап, мәңгелеккә дип төзелгән илнең (безнең туфракта һәр дәүләт шулай төзелә), андагы тормыш-көнкүрешнең, җир тетрәгәндәй, түбәсе чатнаган, диварлары җимерелгән көннәр бу... Коры җирнең алтыдан бер өлешенә терекөмештәй авыр алсу томан төшеп, һавада кан исе аңкып торган чаклар... Җиһан «Ура!» һәм «Долой!» тавышла-

рыннан тетрәп тора! Шундый шартларда — иминлек, тынычлык харәбәләре өстендә, моңарчы азмы-күпме анык чамаланган киләчәк солдат итеге астында калган вакытта, контраст рәвешендә, бар тәшвиш-вәсвәсәләргә үч итеп, ике яшь йөрәктә мәхәббәт хисе ялуы гаҗәпме?

Гаҗәп түгел. Әмма куркыныч...

Әй-йа, яшьлеккә курку хасмыни? Шуңа күрә без ни әсәрдә, ни истәлекләрдә тирә-юньдәге Ватандашлар сугышын, Казанның әле аклар кулына бирелеп, әле кабат кызыллар кулына кайту мәрәкәсен күрмибез, сизмибез. Без фәкать пианиноның таң җиледәй бәгырьне сыйпап, күңел кылларын тарап узганын гына тоябыз, без әсәрнең дә, истәлекләрнең дә башыннан ахырына кадәр милли моңнарда йөзәбез, беренче чирканчык алган профессиональ татар музыкасы дулкыннарында чайкалабыз һәм... мәхәббәт учагында янабыз: каһарманнар белән бергә ләззәт кичәбез, куанышабыз, сагышланабыз, борчылабыз... өметләнәбез...

Язмышның, өйрәнчек каләм иясе кебек, сюжет линиясен һич мантыйксыз рәвештә ялгыш, кирәкмәс юлга борып җибәрү гадәте барлыгын исәпкә алсак, бу күгәрченнәрнең дә сукмаклары аерылачагы, аларның һичкайчан кавышмаячагы, бер-берсенә насыйп яр булмаячагы шаккатырга тиеш түгел шикелле. Фатыймаи-Зөһрәне әти-әнисе бай егеткә кияүгә бирергә карар кыла. Салих сөйгәнен үзе белән бергә качарга чакыра. Кыз ризалаша, әмма... әмма... Язмыш турында яңа гына ни дидем әле?

Мин, «Гөләндәм туташ хатирәсе»н укып чыккач та, заман кадерләп үстергән прагматиклык агачының ачы бер җимеше буларак, гөнаһтан-фәләннән курыкмыйча: «Әйе, шулайдыр инде... Качарга ният итеп, кача алмагандыр, — дип каш җыерган идем. — Калын янчыклы кияүне кем дә кем ыштансыз сыерчык сыман сайрап торган буш кесәле музыкантка алыштыра инде? Кызлар һәр чорда шул ук кызлар кана!» Ә менә Фатыймаи-Зөһрәнең ошбу язмасын укыгач, «бердәнбер дөрес» фикерен тапкан күңелгә корт төшә...

Сәйдәшнең беренче мәхәббәте...

Язмамны шулай дип атадым бит. Ай-һай, хөрмәтле автор иптәш, болай дип әйтергә дәлилләрең саллымы? Күктән алган фикерең түгелдер бит? Ышанып әйтәсеңме? Чынлапмы?

Билгеле, мин ул вакытта яшәмәгән, Салих ага белән аралашмаган, аның артыннан күзәтеп йөрмәгән... Вактөяк гыйшыйк-мыйшык хисе, бәлки, аңарчы да яшь йөрәкне кытыклагандыр. Әмма иманым камил: Фатыймаи-Зөһрә Салих Сәйдәшевнең беренче зур, чын мәхәббәте булса кирәк; Салих Сәйдәшев тә Фатыймаи-Зөһрәнең иң беренче (бердәнбер дә булырга бик мөмкин), иң зур мәхәббәтедер...

Чү! Тәртипләп...

Композиторыбызның беренче хатынын — Валентина Мухинаны — өзелеп яратуы шиксез. Бу елларда ул очынып йөри, армый-талмый, илһамланып иҗат итә, музыка яза — «Казан сөлгесе», «Сүнгән йолдызлар», «Таһир-Зөһрә», «Зәңгәр шәл»... Зенитта чагы! Бөтен СССР буйлап татар театры гастрольләре гөрли, тамашачылар елга булып спектакльләргә агыла, «Салих Сәйдәшев концерты» дигән афиша заллар тутыра... Әмма, кызганыч ки, күкләр Валяга озын гомер бирми, бала тапканда каны бозылып, гүзәл хатын бакыйлыкка күчә. Иң күңелсезе, шушы хәл Сәйдәш тормышындагы барлык фаҗигаләргә юл ача: киләчәктә тагын ике баласын югалтачак ул, зур трибуналардан сүгеләчәк, театрдан куылачак, үлеменнән соң онытылуга дучар ителәчәк (мәсәлән, 60 һәм 65 яшьлек юбилейлары үтә тыйнак рәвештә Композиторлар берлегендә генә үткәрелә, чакыру тексты гади машинкада гади почта кәгазенә бастырыла), Казан консерваториясендә сакланган архивы юкка чыгарылачак...

Хатын-кызлар мәсьәләсендә дә гел уңышсызлык көтәчәк аны. Валентинадан соң Сафия Алпаева исемле кассиршага өйләнәчәк ул, билгеле, Сафия ни аны, ни аның иҗатын аңламаячак. Салих ага аерылып, йортсыз-җирсез калган бер артистны үзенә кертәчәк тә, соңрак әлеге артистны хатыны өстендә тотып, үзе йортсыз-җирсез калырга мәҗбүр булачак. Өлкәнәйгәч, тагын бер өйләнеп караячак. Асия Казаковага. Ләкин аның белән дә тормышы рәтләнмәячәк, ханым тиз арада җәмәгатенең кем икәнен дә онытып, барлык игътибарын, вакытын үзенә һәм Фәрхәт исемле малаена багышлаячак. Салих ага 1954 елда Мәскәүгә операция ясатырга барачак. Ярдәм итәргә, күз-колак булырга дип ияреп барган Асия ханым, ни гаҗәп, үз вазифаларын ташлап, кайтып китәчәк... Операциядән айныган Сәйдәш, персоналны борчырга теләмичә, үзе аякка басачак, әмма әллә абынып, әллә башы әйләнеп, егылачак, шуннан хәле кискен начараячак һәм бераздан Казанга күренекле аһәңсазның үлеме турында хәбәр кайтып ирешәчәк...

Үтә сабыр, итагатьле, әдәпле зат, ул һичкайчан башына төшкән борчуларын кешегә күрсәтми, көрсенер урында — елмая, үкереп елар урында — көлә һәм барлык сагышын, кайгысын, хәсрәтен эчкә батыра, эчкә батыра... Шуңа да, төрле хисләрдән тулы калебенең бервакыт шартлап, чәчрәвекләренең илаһи моң булып нота кәгазьләренә түгелүе, рояль телләренә кунуы, миллионлаган-миллионлаган йөрәккә үтеп керүе — үтә табигыйдер, мөгаен.

Җиһан кадәр җиһанда япа-ялгызы калган шушы елларда (1926-1954) нәрсә яшәтә аны? Тәүге мәхәббәте түгелме? Ихтимал, ул Валентинаны да юксынгандыр, аны да күрәсе килгәндер, әмма, нишләмәк кирәк, җир куенына бер кергән кешене кире кайтарып булмый шул. Ә Фатыймаи-Зөһрә бар... Ул исән... Бик еракта булсын, әмма исән! Ул да аны сагынадыр! Ул да аны яратадыр! Кеше табигате гаҗәп нәрсә бит: берәр якыныңның мәңгелеккә гарешкә ашканын аңлау шул ук якыныңның мәңгелеккә берәр кая, әйтик, чит илгә, Америкага китүен аңлауга караганда авыррак, җәрәхәте тирәнрәк. Югыйсә, теге очракта да, бу очракта да син аны мәңге күрмәячәксең! Китте! Бетте! Әмма икенчесендә, аз да түгел, күп тә түгел — өмет кала... Кайтыр, барырмын, күрешербез, дигән өмет. Сәйдәшне дә, миңа калса, шушы өмет яшәткән. Һәм... аның бу өмете акланган да. Сукмаклары аерылганнан соң төгәл утыз ел гомер узгач (!) кабат очраша алар. 1949 елда. Салих Сәйдәшевнең соңгы гастрольләре. Шул «соңгылык»ны сизгәндәй, Ташкентта ул үзе Фатыймаи-Зөһрәне эзләп таба. Күрешәләр. Икесе дә яшисен яшәгән. Олыгайганнар. Буй җиткән балалары бар. Икесе дә толлар: Фатыймаи-Зөһрәнең ире утызынчы еллар тегермененә эләгә... (Нәкъ менә шушы фактны игътибарга алып, мин «Гөләндәм» дә гомер буе Салихка карата булган мәхәббәтенә тугрылык саклагандыр, дип гөманлыйм. Янә Әмирхан Еникинең «Берничә генә соңгы сүзе»н искә төшерик әле: *«...ул миңа әнисенең Салих Сәйдәшне еш кына искә төшерүен, аның көйләрен пианинода яратып уйнавын, ә үләр алдыннан исә Сәйдәш музыкасын ишетергә теләвен сөйләп бирде...»*) Үзе әүвәл кинотеатрда пианиночы булып эшли, аннары балалар бакчасында музыкаль белем бирә — кыскасы, мөгаллименең тырышлыгы юкка китми.

Бу очрашуда ни-нәрсә сөйләшкән алар? Яшь чакларын искә төшергәннәрме? Тинчуриннарны хәтергә алганнармы? «Шәрык» кичәләрен сагынганнармы? Ниһаять, тормышларыннан зарланганнармы? Язмышларын каһәрләгәннәрме? Әллә... тәкъдиргә күнгәннәрме? Кулъязма Салих Сәйдәш сүзләрендә кинәт кенә өзелә. Ихтимал, без бу сорауларга һичкайчан җавап тапмабыз... ■

Салих Сәйдәшев – хәрби музыкант, капельмейстер. 1920 нче еллар башы

«СӨЙЛӘ, ГӨЛГЕНӘМ...»

Фатыймаи-Зөһрә истәлеге

Салих Сәйдәшев музеенда сакланачы экспонатлар арасында бер кызыклы гына кульъязма бар. Инде саргаеп беткән дәфтәр битләрендә карандаш белән язылган гап-гади сүзләр күренекле композиторыбызның тормышына, аның образына үзенчәлекле һәм әһәмиятле төсмерләр өсти. Бу – Әмирхан Еникинең «Гөләндәм туташ хатирәсе» бәянына нигез булган Фатыймаи-Зөһрә Солтанованың уналты битлек истәлекләре[1]. (Музей документларында экспонат «көндәлек» дип йөри, ләкин эчтәлеге буенча язманың нәкъ менә истәлек булуы күренеп тора, Әмирхан Еники дә мәгълүм интервьюсында[2] шуны ассызыклый.) Дәфтәрне музей төзелгән дәвердә язучы үзе музейга тапшырган. Истәлекләр карандаш белән татар телендә (гарәп имлясында) язылган. Текст кирилл хәрефләренә күчерелде, әдәби тел орфографиясенә туры китерелде, стилистикасы үзгәрешсез калды. Танылмый торган урыннарга күпнокта куелды. Контексттан якынча чамалап булырлык сүзләр шакмак җәя эчендә бирелде.

---

[1] Милли музей исәпкә алу-теркәү номеры — НМ РТ В-19273/12.
[2] «Хатирәләр» яңарганда...» Татарстанның халык язучысы Әмирхан Еники белән Казан дәүләт педагогика институты аспиранты Әлфия Мотыйгуллина әңгәмәсе. Татарстан ж., №3-4, 1994. — Б.92-94.

Беренче бит

Салих безгә килә. Мин аның пианинода уйнаганын һәрвакыт яратып тыңлыйм. Ләкин [без] таныш түгел. 1918 елның көзе. Яфраклар коела, коеп-коеп яңгырлар ява, һава ачулы кеше шикелле ... кара болытлар, ачы җилләр. Шундый көннәрнең берендә кичке аштан соң әти миңа карады да: «Беләсеңме, мин нәрсә уйлыйм...» — диде. Мин куркып киттем. Мин: «Нәрсә уйлады микән?» — дим эчемнән. «Мин Салих берлә сөйләштем, ул сине өйрәтә татар көйләрен пианинода [уйнарга]», — дигән булды. «Дәрес вакытында мин үзем булам. Атнасына ике мәртәбә», — диде. Мин, эчемнән сөенсәм дә, сөенгәнемне белдермәс өчен: «Үзегез беләсез, миңа барыбер», — дидем. Үзем сөендем! Шулай берничә көннәр үтте. Менә беркөн кич мине әти чакырта. Мин Салих килгәнен белгәнем юк, мин йөгереп залга барып кердем. Үзем дә оялып киттем. Әти миңа карады да, көлемсерәбрәк: «Салих, менә бу минем кызым Фатыймаи-Зөһрә», — диде. Ул башын иде. Мин дә баш идем. Алдыма төшкән чәч толымнарымны артыма алып ташладым. Күземнең кырые белән генә карадым. Салих әтигә карады да: «Мөмкинме?» — диде. Әти мөмкин кылгач, ул минем кайда музыка дәресе алганымны сорады. Һәм ноталарымны карарга рөхсәт сорады. Ноталарымны карап [чыкканнан соң], бер нотаны алып бирде. Мин уйнадым. Ул карап тора. «Яхшы уйныйсыз, сезгә җиңел булыр өйрәнергә», — диде.

Икенче бит

Ул шул көннән дәрес бирә. Һәр дәрес биргәндә атам үзе карап утыра. Минем атам бик иске фикерле бер кеше, ләкин музыканы бик ярата, шуның өчен мине Салихтан өйрәтергә булды. Ул Салихны һәм аның иптәшләрен чакырып күп вакыт аларны кунак итә һәм үзенең яраткан көйләрен уйнарга куша.

Шулай вакыт үтә, карлар ява, кыш җитә. Шулай дәрес вакытында Салих нота күрсәтә: «Менә карагыз», — ди. Үзе бер кулы берлә яза, бер кулы берлә уйный. Яза: «Минем сезнең берлә сөйләшәсем бар, кайда сезне күрә алам? — ди. — Төшендегезме, бу нота гади?» Мин, әти сизмәсен дип: «Төшендем», — дим. «Төшенгән булсагыз, күрсәтегез миңа», — ди. Мин язам: «Мин беркайда да сезне күрә алмыйм. Миңа болай язмагыз. Беләсезме, әти күрсә нинди күңелсез булыр!» — дим. Ул тагын: «Көтәм. Кайда? Кайчан?» — ди. Мин җавап бирмим. Мин ул кичне һаман уйлыйм: «Миңа нинди сүзе бар икән?» Икенче көнне, музыка дәресеннән чыксам, Салих тора. Мин әйтәм: «Нишләп торасыз бу җирдә?» — дим. «Мин сезне көтеп торам, — ди. — Кичерәсез[3] мине, күрәм, сезнең минем берлә сөйләшәсегез килми». Мин әйтәм: «Беләсез, әгәр безнең болай очрашуыбызны әтием белсә, сез мине музыкадан мәхрүм итәсез. Мин сездән [өйрәнеп] яхшы уйный башлаган идем». «Сез фәкать шуннан гына куркасызмы?» — ди.

Өченче бит

Мин әйтәм: «Юк, мин сезнең һәрвакыт миңа дәрес бирүегезне телим, — дим. — Һәрвакыт таныш булып калырга телим», — дидем. Ул авыр гына сулап куйды да: «Төшенәм, әгәр сезнең әтиегез музыка яратмаса, мин [аның] өенә аягымны да атламас идем. Сезгә минем кирәгем — фәкать музыка өйрәнер өчен генә, ә мин ... мин бүтәнчә уйлаган [идем], мин ялгышканмын», — [диде]. Мин әйтәм: «Нигә сез шундый фикердә үз турыгызда? Мин сезнең музыкагызга һәм үзегезгә бик зур бәһа бирәм, — дим. — Әти дә шулай», — дим. Ул, әзрәк җанланып китеп, минем ике кулымнан тотып: «Сабыр иткән морадына җиткән, шу-

[3] «Кичерегез» мәгънәсендә.

Татарстан радиосының беренче хезмәткәрләре (сулдан уңга): әдәби мөхәррир Исмәгыйль Усманов, музыкаль мөхәррир Салих Сәйдәшев, диктор Гадел Кутуй. 1928 ел

лай бит ә? — диде. — Иртәгә театрга барасызмы? — дип сорады. («Соңгы сәлам»[4].) Мин: «Барабыз», — дидем. Ул вакытларда татар театры элеккеге Проломный, хәзерге Бауман урамында, «Большой театр»да[5] иде. «Соңгы сәлам»дә Казанның бер бай кешесенең вакыйгасын сәхнәгә куялар. Кәрим Тинчурин — баш рольдә. Хатыны ролендә — Өммегөлсем Болгарская. Урыс кызы ролендә — Фатыйма Ильская. ... Бик яхшы постановка. Минем яхшы [дип] исемдә калган. Салих, дәрескә килгәндә, миңа хат язып килгән. Хатны ноталар арасына куйды. Мин алмасам, әти кулына төшә, шуның өчен бик тиз хатны алып яшерәм. Салих миңа күзе белән рәхмәт ишарәсен белдерә.

Дүртенче бит

Хатка шулай язылган: «Фатыймаи-Зөһрә! Кичерәсез, мин сезгә үземнең таныш кына түгел, дус [ук булуымны] телим. Мин сезнең берлә сөйләшергә теләдем. Ләкин сез миңа башкача карыйсыз, ә минем карашым сезгә бер, һаман бер: мин сезгә мөгаллим, сезне пианинода [уйнарга] өйрәтүче Салих булып кына каласым килми. Ачуланмагыз, мин сезне яратам, бер мөкаддәс як ярату берлә яратам. Мин сездән җавап көтәм. Сез миңа җавап бирерсез, дип уйлым. Мин сезнең берлә бергә булыр өчен һәр авырлыкны күтәрергә риза. Минем сезгә тагын бер үтенечем [бар]. «Шәрык» кичәсе була, сез шул «Шәрык» кичәсендә җырласагыз [иде]. Сез бит яхшы җырлыйсыз! Мин уйныйм пианинода. Менә шулай, үзегез җырлаган шикелле, «Мәдинәкәй» көенә. Бөтен яшьләр катнаша. Курыкмагыз, әтиегез белмәс. Мин сезне иртәгә көтәм. Шунда сөйләшербез. Сезне ярата торган Салих. 1919 ел».

Мин хатны укып нишләргә дә белмим. Әти ишетсә, мине үтерәчәк. Әни

[4] Спектакль исеме. Кәрим Тинчурин пьесасы буенча куелган. Беренче мәртәбә 1917 елның 17 ноябрендә уйнала.
[5] Хәзерге Качалов театры.

дә риза булмас. Нишлим? Риза булмасам, үземнең катнашасым килә. Икенче көн без Салих берлә күрешәбез. ... «Миңа ачуланмадыгызмы? Җавап бирә аласызмы?» — ди. Мин әйтәм: «Салих, сез беләсез бит, безнең, татар кызларының ихтыяры — ата-аналарында», — дим.

Бишенче бит

Ул әйтә: «Юк инде, моннан соң һәммәнең ихтыяры үзендә булачак, моны безгә бөек Ленин әйтә», — ди. «Бу турыда башка вакыт сөйләшербез, — дим. — Салих, мин сәхнәгә чыгарлык җырлый алмыйм». «Сөйләмәгез, мин беләм, бик яхшы җырлыйсыз».

Ике көннән соң ул мине репетициягә алып бара, Солтан Габәши берлә таныштыра. Минем җырлавымны ошаталар. «Борынгы татар көйләреннән «Мәдинәкәй» һәм «Кара урман», шул ике көйне хәзерлим», — дигән булам. ... Бер репетициядә язучы Фатих Әмирхан берлә таныштыра. Кәрим Тинчурин берлә таныштыра.

Шулай итеп «Шәрык» кичәсе җитә. Минем ул вакыттагы хисләремне ничек тә язып төшендерә алмыйм! Бер куркам, бер шатланам. Шундый күңелле үтә «Шәрык» кичәсе. Минем әтигә әйтмичә. Шулай көннәр үтә. Менә язгы кояшлар матур карый, тамчылар тама башлый. Ул ... миңа үпкәли. «Сез минем соравыма җавап бирмәдегез, мин көтәм», — ди. Мин ул вакытларда, бердән, яшь; икенчедән, атамнан шундый куркам. Фикерем тар. Дөньяга хәзерге яшьләр шикелле карый алмаганмын, эчке тойгыларымнан кичәргә мәҗбүр булганмын. Миңа Салих охшаса да, мин үземне тыярга кирәк икәнлекне беләм. Ул вакытларда наданлык, искелек яшәгән, мин шул искелеккә, наданлыкка чолганып калган халык эчендә яшим, шул чикләрдән үтә алмыйм.



Фатыймаи-Зәһрә кулъязмасының бишенче бите

Алтынчы бит

Менә җәй җитә. Һәм бәйрәм җитә. Мин ничә көннәр авырыйм. Әнинең абыйсы килгән бәйрәмгә. Гает көн. Мин Салихтан хат алам. Ул яза: «Мин сезне сагындым. Театрга килгән «Зөләйха» дигән драма, беренче [мәртәбә] сәхнәгә куела», — ди. Бу пьеса [шул турыда]: Иван Грозный, Казанны алгач, татарларны көчләп урыс диненә кертә, халык телендә әйтсәм, чукындыра. Урыс исемнәре бирә татарларга. Кызларны, яшь хатыннарны урысларга иргә бирәләр. Шулар эчендә ярлы авыл хатыны Зөләйха була. Өммегөлсем Болгарская уйныйдыр иде. Аның урыс ире ролендә — Мохтар Мутин. Яхшы пьеса. Ул миндә бик яхшы [тәэсир] калдырды.

Минем кәефем бер дә булмаса да, көчкә торып әнинең абыйсы берлә театрга киттем. Салих килеп күреште. Бәйрәм [белән] тәбрикләде. Театр башланды. Шулай мин театр карап бетердем. Театр беткәч, абый үзе каядыр иптәшләре [белән] бара, мине атка утыртып җибәрә. Минем артымнан икенче ат белән Салих куып җитә һәм рөхсәт сорый мине озатырга. Без аттан төшәбез. Кич матур.

Җиденче бит

[Салих]: «Мин бик күңелсез хәбәр ишеттем. Сезне иргә бирәләр икән», — диде. Мин аны үзем дә сизеп тора башлаган идем. Әнинең абыйсы килүенең сәбәбе шул: бер бай кешенең баласына димли. Ул егет атам янына эш берлә килә, Казанга килгәндә безгә төшә. Мин бик каршы әйттем, бик җыладым. «Сез мине бәхетсез итәсез, үзегез дә бәхетле була алмассыз», — дидем.

Минем шулвакыт тамагыма каты бернәрсә тыгылды. Мин җыламас өчен үземне тыярга тырыштым. «Мин әнигә әйттем: «Әгәр мине ул егеткә бирсәгез, мине Иделдән табарсыз. Мин үлсәм үләрмен, ләкин аныкы булмам», — дидем. [Салих]: «Чынлап әйтәсезме?» — диде. Мин: «Әйе», — дидем. «Минем бер дә кәефем юк, озатыгыз тизрәк», — дидем. Салих минем ике кулымнан тотып: «О, сез кызусыз, шундый кайнар, сез янасыз», — диде. «Сез минем гөлгенәм, бергенәм», — диде. Дөрестән әйткәндә, минем шулвакытта аның кочагына егыласым, иркәләнәсем килде. Ләкин мин [бу хәлнең] мөмкин түгеллеген шунда [ук аңладым]. Минем күз алдына атам килеп басты. Яки уртабызда [пәйда] булган шикелле булды. «Мин авырыйм шул, — дидем, — әйдә тизрәк кайтыйк». Ул мине озатты. Мин шуннан соң тагы байтак авырып яттым. Мине шулвакытта әни иргә бирергә җыенып йөргән икән.



Фатыймаи-Зөһрә кулъязмасының җиденче бите

Сигезенче бит

Безгә килүе дә шуның өчен икән. Ә ул егет Казанныкы түгел икән. Минем әнием дә Казанныкы түгел. Мин ул егетне беләм, ул безгә әти янына эш берлә һәрвакыт килә. Минем үземә бер сүз дә әйтмиләр. Мин эчемнән шулай уйлыйм: «Әгәр шул егеткә бирәбез, дисәләр, качармын, бер эштә чыгара алмасам, Иделгә үземне ташлармын», — дип. Мин шулкадәрле яратмый идем ул егетне!

... Кышлар тәмам булды. Шулай ук минем пианинода уйнавымны да туктаттылар. Әни миңа: «Кунакка барабыз, абыеңнарга», — диде. Мин: «Минем бер дә барасым килми, мин Казанда калырга [телим]», — дим. «Мин синнән сорамыйм «Каласың киләме, юкмы?» дип, мин сиңа җыенырга кушам», — ди. Нинди күлмәкләремне алырга, ягъни шуңарга охшаган боерыклар бирде. Мин никадәр теләмәсәм дә, минем ихтыярым үземдә түгел. Мин ул көнне ашарга да төшмәдем, башым авырта, дип яттым, еладым. Миңа, ничектер, киләчәгем караңгы төн шикелле күренде, мин шунда адашып калган кеше шикелле булдым. Мин сизәм: мине иргә бирергә тиешләр. Ләкин минем барасым килми! Мин уйлыйм: «Әгәр качып китсәм, кая барырга?»

Тугызынчы бит

Минем ул вакытта дөньяга карашым ни өчендер бик тар. Мин генә түгел, ул елларда татар кызлары һәммәсе шундый [иде дияргә] мөмкин. Әгәр Салихка әйтсәм, бәлки ул ярдәм итәр качарга? Юк, мин ничек аңа

әйтим? Юк. Яхшы, мин шул Иделгә үземне ташлыйм, дидем. Шулай, мин җыенырга мәҗбүр булдым. Ул егет үзе килде, дүрт тройка алып килгән, абый килгән. Мин тагын: «Бармыйм!» — дип әнигә еладым. «Мин беләм, сез мине иргә бирмәкче буласыз», — дим. Ул миңа: «Вакыт җиткәч, кызларны иргә бирәләр», — ди. Ул минем сүземә әһәмият тә бирмәде. Ул, бердән, әти сүзеннән чыга алмый, икенчедән, ул шул гомер [буе] татар кануннары, кызын бай җиргә бирү, кода-кодача булып йөрү — шуның ише хыяллар белән [яшәде]. Ул минем сүземә әһәмият бирмәде һәм төшенмәде. Кызы бәхетле булачакмы-булмаячакмы, мин яратаммы ул кешене, юкмы — ул вакытларда ата-аналарның [монда] гаме юк [иде]. Кияү бай булса, яхшы мәһәр бирсә, кода-кодача булып йөрерлек кеше булса — шул тәмам.

Менә иртәгә китәбез. Мине нәрсә көтә? Мин белмим. Атлар җигелде, булды, китәсе нәрсәләрне ташый башладылар. Уен тавышы — гармун, скрипка, мандолина [ишетелде]. Көй уйнап җибәрделәр.

Унынчы бит

Мин аптырап калдым. Мин ... күтәреп чыгып бара [торган] асрауга карадым да: «Кайда уйныйлар?» — дидем. «Безнең белән Салих абыйлар да баралар, бер атта алар», — диде. Мин, никтер, сөендем. Әти үзе бармый. Бер тройкада — абый. ... Бер атта — әни, бала караучы һәм балалар. Бер атта — мин, әнинең апасының кызы һәм бер гармунчы кыз. Безне әти озатып калды.

Ул вакытларда Идел аркылы ... пароходта атлар берлә [бергә] чыгарга [иде]. Без Иделне аркылы чыктык. Югары Ослан ягына суны чыккач кына, Салих сикереп төште дә, без [күрештек]. ... Ләкин ул бик күңелсез. Атлар акрын гына кузгалып киттеләр. Тагын уйнап җибәрәләр. Очсыз-кырыйсыз Идел. Аның өсте тын, күкрәгән киереп пароход бара. Үзенең теләгенә җитәргә тырышкан кеше шикелле, шул киңлектә алга бара. Акчарлаклар очалар. Бер ягы — урман, күм-күк, ямь-яшел чирәм ... төрле матур чәчәкләр. Мин уйлыйм: нинди бәхетле бу акчарлаклар! Алар теләгән җирләренә баралар. Аларга һичкем хуҗа түгел. Мин нинди бәхетле булыр идем, акчарлак булсам. Шуннан соң Салихның сүзе исемә төшә: «Моннан соң һәркемнең ихтыяры үзенеке булачак, моны безгә бөек Ленин әйтте». Һәркем үз теләгәне белән яшәячәк, мин дә шулай яшәрмен, юк, бервакытта да ... ул егетнең хатыны булмам!

Унберенче бит

Минем йөрәгем [үзгә кешедә]. [Мин аның] хатыны, юк, мин үзем яраткан кешенең сердәше, дусты булырмын, дим. Шулвакыт минем битемә нәрсәдер тиеп китә. Мин йокыдан уянган кеше шикелле сискәнеп китәм. Мин утырган атлар белән Салих утырган атлар бергә баралар. Ул миңа чәчәкләр ташлый. Бер чәчәк минем битемә килеп бәрелгән икән. «Сез нинди тирән уйга калдыгыз?»

Без кунак ашы вакытында атларны да ... үзебез дә ял итәр өчен, бик матур бер урыс авылына туктадык. Иделнең бер зур тармагы. Без туктаган хуҗаның бик зур алма, кура җиләге, слива, карлыган, шуңа охшаган күп җиләк-җимешле агачлары бар. Бакчаның арты суга барып тоташа. Безгә бакчада ашарга, эчәргә хәзерләделәр. Без бик озак ашап-эчеп утырдык. Салихлар гармун, скрипка, мандолина уйнадылар. Салих ни өчендер күңелсез. Аның һәрвакыт матур ... күзләрендә бер моңлылык, нарасыйлык бар. Ашап-эчеп туйганнан соң, бер өч-дүрт [сәгатьтән] ... кичкә таба юлга чыгарга [ниятләдек]. Шулай [килешенгәч] ... ял итәргә таралдылар.

Уникенче бит

Без дә өйгә кердек, ял итәргә. Бераздан безнең хезмәтче кыз акрын гына минем яныма килде дә: «Менә моны Салих абый бирде», — диде. Әни яткан [иде]. ... [Хезмәтче кыз барып] карады. Әни ... йокыга киткән, диде.

Кечкенә записка: «Мин сине көтәм, бакчаның ахырында, су буенда. Чыкмасаң, үпкәлим». Башка сүз юк. Мин әллә нишләп киттем. Хезмәтче кызым әйтә: «Мин үзем саклармын, бар чык. Апа җаным, сине бит шушы бай егеткә бирергә көчлиләр. Барма, җаным, бу мәхәббәтсезгә! Яраткан кешеңә ябышып чык», — ди. Мин, чыгып, кеше күрмәсен, дип ашыгып-ашыгып барам. Салих арлы-бирле йөреп, көтеп тора.

Ул да дәшми торды. Мин дә дәшмим. «Беләсеңме, нәрсә... Мин хәзер биек ярның башында. Аз гына атласам, [егылып] төшәсе... Син шуңа разыймы?» Мин әйтәм: «Мин риза түгел, әгәр мине кияүгә бирсәләр, мин үземне Иделгә ташлыйм. Ләкин мин аныкы булмам», — дим. Аның күзләренә шатлык йөгерә. «Беләм, кичер мине. Мин сине сөям. Әйдә, качабыз. Курыкма, җаным, без Әстерханга китәрбез. Миңа анда эш бар. Син уйлама байлык дип. Байлыктан бәхет тапмассың, байлыкка ышанма, байлык юк булачак. Бәхет бер-береңне яратуда, эшләп, кулга-кул тотышып яңа тормыш ясауда!» — ди.

Унөченче бит

Мин әйтәм: «Мин төшенәм, ләкин нишләсәм мөмкин?» — дим. «Бер нишләмисең. Качабыз! Курыкма, гөлгенәм! Мин музыка язармын. Бергә булсак, без бәхетле булырбыз. Менә, кара шушы матурлыкларга, кара су буендагы каен агачына: нинди матур ул, ул бит үзе генә түгел, алар бит икәү! Искән җил белән алар бер-берсен иркәлиләр. Кара әнә ул очкан кошларга, әнә алар берсен-берсе калдырмыйлар, алар бергә очалар, алар хөр. Менә без дә синең белән шулай хөр яшәрбез! Мин сиңа энҗе-бриллиантлар бирә алмыйм. Мин сине сөям, саф мәхәббәтемне, йөрәгемне бирәм. Шуннан кыйммәтле нәрсә юк дөньяда! Әгәр мин шул байлыкларга кызыгып, шул юлга кызыгып, шул юлга атласам, сиңа бу тормыш юлында күп кыенлыклар күрергә туры килер. Җавап бир, — диде. — Мин [монда] әллә нигә килмәс идем. Мин синең өчен хәзер алар алдында, аларның күңелен ачар өчен уйнарга риза булдым — телләремне кысып! Мин бу дуракларның түбәнчелекләренә тик синең өчен, сине күрер өчен [түзәргә] риза булдым», — диде.

Ундүртенче бит

Мин әйтәм: «Салих, син күрәсең, мин разый түгел, мин бармыйм ул кешегә. Мин сезнең белән китәргә разый. Ләкин ничек? Әгәр белсәләр яки тотсалар? Сез мине ... әтиемнән сорагыз, әтием сезне ярата», — дим. [Ул]: «Әтиең мине сораганны уйнаучы Салих дип ярата. Кызына кияү булырга тиеш кеше дип хисапламый. Аны син яхшы төшенәсең. Минем байлыгым юк, минем байлыгым — музыка», — диде. «Мин тырышырмын качарга», — дим. Без шулай аерылыштык.

Кояш батар алдыннан юлга чыктык. Кояш баеды, әкрен генә ай чыкты, күкне матур йолдызлар басты. Һава тын, матур. Табигать ял итә, аның тынычлыгын ... исеп куйган җил генә боза. Атлар алга чабалар. Без шулай таң сызылганда барып җиттек. Мин дүрт көн Салихны күрмәдем. Алар ирләр ягында. ... көн Идел буена хозурга чыктык. Салихлар да чыкты. Күз берлә генә исәнләштек. Салих берлә сөйләшкәннән соң мине һичбер нәрсә кызыктырмый, һичберсе сөендерми. Камышлык матурлыгына карап уйга чумам: «Әйе, бәхет хөрлектә, мин качам. Әлбәттә, качам! Хәзер һәркем үзенең ихтыяры белән яшәячәк. Шулай булгач, миңа да шулай киңлеккә, хөрлеккә чыгарга кирәк», — дим. Шуннан соң минем башка әллә нинди күңелсез уй-

лар килә. Әнинең иске фикерлелеге, үзенең әйткән сүзеннән кайтмый торган гадәте барлыгы мине [ризасызлата?] ... уемның ахырына җитә алмыйм.

Без, берәр атна кунак булгач, кайтып киттек. Кайтканда өч тройка: берсендә — әни, берсендә — Салихлар, берсендә — мин. Без Салих берлә тагы бер яланда ял иткәндә күрештек.

Унбишенче бит

Ул миңа карады да: «Вәгъдә бирә алмыйсыңмы? Без кайткач та мин, өч көн үткәч, һәммә эшләремне рәтлим дә, сине күл буенда көтәрмен. Һичнәрсә алма, бәхет чүпрәк берлә... — Ул минем кулымдагы беләзегемне тота, әйтә: — Менә бу нәрсәләрдә түгел, — ди. — Бәхет бер-береңне яратудадыр», — диде. Мин өч көннән соң һичнәрсә алмый күл буена чыгарга һәм качарга вәгъдә бирдем. Ни өчендер мине, йөреп кайтканнан соң, бик [ашыктыра?] башладылар, мин: «Ул егеткә бирсәгез, үземне Иделгә ташлыйм, ләкин бармыйм», — дидем. Мине һичкайда чыгармыйлар. Бу ел укымаска да, пианинода да өйрәнмәскә, [диләр]. ... Һичкая чыгармыйлар. Мин шулай да качу фикереннән кайтмадым. Мин берничә көннәрдән соң хат алам. «Мин сине бүген көтәм, һәммәсе хәзер», — дип яза. Мин шул көнне, өйдә һәммә [кеше] йоклаганнан соң, үз бүлмәмнән чыгып, кара яктан чыгарга уйлап, ишеккә барам. Ишек бикле. Ачкыч һәрвакыт [ишек] өстендә буладыр иде. Ачкыч урынында булмаса, ачкыч тора дигән җайны [җирне?] карадым. Юк. Барам ... якка барам — бик. Иртәгә ачкычны кая куйганнарын карарга булдым. Иртәгесен хезмәтче кызыбыздан сорадым: «Ишекләрне төнгә бикләп, ачкычларны кая куясыз?» — дидем.

Уналтынчы бит

Шул көннәрдә безнең күршедә бер кыз үзенең яраткан егете берлә качты. Шул вакыйгадан соң әти ишекләрне бикләп, ачкычларны үз бүлмәсенә алып керә икән. Мин ... ашарга да теләмәдем. Көндез дә мине чыгармыйлар. Мин Салихка язып бирәм: «Мине саклыйлар, һич чыга алмыйм», — дип. Ә ул миңа яза: «Дөньяда мөмкин булмаган эш юк, син үзең теләмисең», — ди. Шулай мин чыга алмадым.

Күп тә үтми, мине иргә бирәләр. Миннән сорамыйлар. Мин тагын еласам да, файдасы юк. Минем ир булачак кеше — гали, мәгълүматлы, чибәр генә бер кеше. Тормышка чыкканнан соң, мин аны [Салихны] күргәндә, ул минем берлә исәнләшмәде. Без [ирем белән] беркадәр вакыттан соң Казаннан киттек. Мин шуннан соң аны күрмәдем.

Ничәнче ел икәнен хәтерләмим, бик күп еллар үтте, күп сулар акты. Мин торган квартирда аны яхшы белүче бар [иде]. Бер сөйләшкәндә мин әйтәм: «Мин дә яшь вакытта [аның белән] таныш идем», — дидем.

[Тагын күпмедер вакыт узгач], Салих Ташкентка килә. Мин ишеттем. Ләкин барып күрешергә уйламадым, уңайсызландым. Мин торган йорт хуҗасы Салихны чакырган. Миңа әйткәне юк. Хозяйкам керде дә: «Әйдә, миндә кунак бар», — [диде]. Мин: «Рәхмәт, кермим», — дидем. Без шулай ... торганда: «Мөмкинме?» — дигән тавыш ишеттем. Мин күзләремә ышанмадым — Салих! Ул мине күргәч ике кулларын сузды. «Их! Минем гөлгенәм, бергенәм! — диде. — Мин сиңа үпкәле, ләкин һич ул үпкәне саклый алмыйм», — дип, минем ике кулымнан тотып: «Үзгәргәнсең», — [дип өстәде]. Ул минем хуҗа хатыныма таба әйләнде дә: «Кичерәсез, безне бераз гына үзебезне калдырыгыз», — диде. Ул тагы [әйтте]: «Үзгәргәнсең, ләкин күзләрең һаман шулай сөрмәле, мин ятратканча карыйлар. Сөйлә, гөлгенәм! Сөйлә...»

Кереш сүзне һәм текстны басмага Салих Сәйдәшев музее хезмәткәре ***Гөлназ Җиһангирова*** *әзерләде.*

Фоторәсемнәр Салих Сәйдәшев музееннан алынды. ■

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

ҖАЕК *тар.* – *Урал елгасының* борынгы исеме. Птолемей (я.э.га кадәр II нче гасыр) аны Daiks дип телгә ала, Византия тарихчысы Менандрда (VII гасыр) – Дзайх, Ибн Фазланда – Джайк, Гильом Рубрукта – Daiks/Ягак (1254). Бу төрки атама «киң» («җәенке») мәгънәсенә ия, дип уйлыйлар. Ибн Батута заманнарында бу елганы *Олы су* дип тә атаганнар, аның аркылы көймәләр өстеннән күпер салынган булган. *Җаек шәһәре* – хәзерге Уральск. Пугачёв кузгалышын бастырганнан соң, Яик/Җаек елгасының исеме, Екатерина II әмере белән, Урал атамасына алмаштырыла һәм бу патшави гаделсезлек бүген дә дәвам итә.

Башкорт телендәге *Йайык* атамасы рус теленнән алынган (аларда ул *Яик* дип атала), ягъни башкортлар бу елганы соң белгәннәр булып чыга. Казакъ телендә – *Жаик (Акжаик)*.

ҖАМИ ҖАМ *ф.* – Иран хорафатында хәмерне уйлап табучы *Җәмшид җамаягы* (бокалы), *җам-и Җәмшид*. Бу тылсымлы җамаякка карап бөтен галәмдәге хәлләрне күреп булган, имеш. Гакыл һәм гыйлемлелек билгесе. Күңел тынычлыгы, күңел рәхәтлеге символы итеп тә карала («Суфичылык серләре»). Суфиларда – хакыйкатьне аңлаганның кальбе. Башкача *Җәмшид касәсе* дә диләр, шулай ук *җам-и җиһани нәгъма* дип атау очрый. *//Ачып Фәрһад ишекне, эчкә керде, Һәм анда нурлы бер касаны*

күрде. Ачыклыкта –Кояшның охшашы ул, Кояш түгел, ә Җәмшид касасы ул. Күренә җир үзәге — эч ягында, Тугыз кат күк күренә тыш ягында. Галишер Нәваи.

Тагын кара: ***Җәмшид.***

ҖАН *ф.* – Кот, рух; күңел; тын, сулыш; энергия. Аңлатмалы сүзлектә җанга: *«...тәнгә тереклек бирә һәм тәннән башка да яши ала дип каралган, тереклек иясенең психик процессларын чагылдырган мәңгелек башлангыч»* дигән билгеләмә бирелә. «Җан» сүзе гарәпкә фарсы теленнән кергән. Грек телендә – *психе*, латинчада – *анима*, борынгы мисырлылар аны *пта* дип билгеләгәннәр.

Риваятькә караганда, Аллаһ кешеләрнең җанын кисәкчәләрдән яраткан. Бу кисәкчәләр дә үзләренең тәңресе итеп Аллаһны таныганнар, ә Аллаһ аларга химаясен вәгъдә иткән.

*Дәвамы. 2014 елның 3 нче санынннан басылып килә.

Борынгы татарлар кешенең җанын *өрәк* дип атаганнар.

Аерым даирәләрдә хатын-кызның җаны булмый, дигән хорафатчыл караш таралган. Ләкин Коръән-Кәримнең «Бал кортлары» сүрәсендә түбәндәге аять бар: *«Изге гамәлләр кылган хак мөэминнәр – ирәк ир булсыннар, кирәк хатын булсыннар – аларга хуш тереклек бирербез, вә аларга кылган гамәлләренә бәрабәр әҗерен бирербез»* (16:97).

Кешенең җанын Газраил фәрештә ала.

Йокыда вакытта кешенең җаны тәненнән аерылып чыгып китәргә дә мөмкин һәм бу вакытта кеше төш күрә, дип исәпләнелә.

Суфиларда кешенең җаны «бәрзәх» дигән башка дөньяда яши, дигән караш бар. Уңайлы шартлар булганда җаннар үзләре яраткан кешегә төштә яки өндә күренергә мөмкин, имеш.

Ибне Рөшд кешенең җаны үлемсез була алмый, ләкин кешелек үлемсез, коллектив акыл буыннан-буынга күчә, дип санаган.

Әл-Газалиның: *«Кеше җанының иң югары функциясе – хакыйкатьне аңлау»,* дигән сүзләре билгеле.

Һиндстандагы нәкышбәндия борадарлыгы суфилары кешенең җаны *(нәфесе)* гадәттә кендек астында урнашкан була, дип саныйлар. Ул сары төстә, имеш.

Урта йөзләр төрки шагыйре Шәмсетдин: кешенең җаны *«өч йөз алтмыш тамырда, түрт йөз кырык сөнгәктә тора»*, – дип яза. Бу саннарны ул тыйб буенча китаплардан алган булса кирәк.

Борынгы төркиләр җанны кошка охшатып, кеше үлгән вакытта бу кош аның авызыннан очып чыгып китә, дип уйлаганнар. Мәҗүсилек, шаманизм чорында *очу/очмак* сүзе үлем белән бәйле мәгънәгә ия булган. Җан кеше тәне читлегендәге кош кебек һәм аның бу читлектә (яки савытта) күпме торачагын берәү дә белми. *«Тәндә җаным ничә көн миһман икәндер, белмәдем»*,– ди Һибәтулла Салихов. *«Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңлем кошы, Шат яратса да җиһанга ят яраткан тәңресе»* – бусы Габдулла Тукай сүзләре. Шәйхзадә Бабич җанның «тән зинданын»нан котылып, күккә, асманга очып китүен тели: *«Чык, җаным, тән зинданыңнан, күккә оч, ямьлән генә, Җиргә төшсен, ал шәфәкъҭәй алланып, шәүләң генә».*

Диалектта җан тарту — тын алу, сулау *//Җаннарыбызны тартмый тырабыз инде тилибизырга карап.*

Җаным, җаныкаем, җанашым (җанкай-җанаш) – мәгъшук-мәгъшукага әйтелә торган сүзләр. *«Сабыйлар аша җан пакьләнә (дәвалана)»* Г.Тукай «Тәнгә – мунча, җанга – юк» дисә дә, балалар өчен иҗат иткән әсәрләре аның да җанын пакьләндергән, дип уйларга кирәк.

Түбәндәге шигъри юлларда исә «җан» сүзе «зат» мәгънәсенә ия: *«Җирдә шул ук таныш тамаша: /Матурлыкны бар итүче белән /Юк итүче җаннар талаша».*

«Җан биргәнгә юнь биргән» фразеологизмын Нәкый Исәнбәт түбәндәгечә аңлата: *«Бәла-җәфадан арынып чыга алуыңа куанып әйтелгән әйтем. Мәкаль урынында да килә.»* Ләкин, күрәсең, хикмәт башкада: биредәге «юнь» сүзе чуашча «җан» (*«чун»*) мәгънәсенә ия булыр. Ягъни асылда бу гыйбарә ассимиляция заманнарының бер чагылышы булып, Алла тарафыннан татарга да, чуашка да җан бирелгәнлеген аңлата (тигез хокуклылык принцибы).

ҖАРЫК ҖОЛДЫЗ – Тимер Казык йолдызы, Котып йолдызы (Полярная звезда). *Җарык/ярук* – «Якты» мәгънәсендә. Атама Әстерхан яклары сөйләшеннән.

ҖАСУС *г.* – Шымчы, күрек; шпик, шпион; яшерен полиция агенты, совет чорында – *сексот* (секретный сотрудник, кайбер чыганаклардан 1951 елда СССРда мондый «совет җасуслар»ының саны 10 млн га җиткәнлеге күренә). *Җасус* сүзе рус теленә *соглядатай* дип тә тәрҗемә кылына. *//Мәккә мөшрикләре Мәдинәдәге мөселманнар арасында коткы-курку таратыр өчен, Нуаем исемле кешене җасус итеп җибәрә.* И.Дөнмәз тәфсиреннән. *Җасус әлкулүб* – йөрәк шымчысы (суфичылыкта үз күңелеңне, кальбеңне күзәтүгә, контрольдә тотуга карата әйтелә). ■

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1915 елның май ае

Текстны һәм искәрмәләрне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Укучы яшьләребез

Коммерция училищесында укучы Газиз Морасов бу ел мөселманнардан берүзе генә училищены алтын медаль илә тәмам итте. Бу ел торговая школаны бетергән 16 шәкертнең икесе мөселман булып, мөселманнарның икесе дә (Хәбибуллин илә Бикбаевлар) мәктәпне беренче дәрәҗәдә похвальный лист илә тәмам иткәннәр.

Кояш. — 1915. — №695. — 3 май.

Мөселман хәстәханәсеннән

Мәҗрухлар вә авыру гаскәриләр тәрбиясе өчен мөселманнар тарафыннан ачылган мөселман хәстәханәсенең кроватьлар саны, хәстәханә идарәсе карарыннан ике-өч көн үткәч тә, 75кә җиткерелгән иде инде. Җәмгыяте хәйриянең соңгы мәҗлес карары буенча якын көндә кроватьлар саны 80гә тулачак.

Соңгы вакытларда хәстәханә идарәсенә түбәндәге иганәләр кылынган: мөселман хәстәханәсендә тәрбияләнүче Тамбов губернасыннан Хәмзә әфәнде Маматказиннан 2 кисәк 164 аршын мадаполам[1] — күлмәкләр тектерер өчен, унике сум акча тектерү хакы өчен һәм ун данә кәләпүш; Мөхәммәдгали әфәнде Мастуковтан 70 данә французские булки, Газизҗан әфәнде Галиевтан 30 данә кәләпүш — киткән солдатларга биреп чыгарыр өчен; подвалчы[2] Әхмәдҗан әфәнде Галиевтан 80 данә йомырка.

Дарелфөнүн [университет] тәмам итү

Яшь язучыларыбыздан Газиз әфәнде Гобәйдуллин бу ел Казан дарелфөнүненең тарих вә тел бүлеген тәмам итте. Казан дарелфөнүне янындагы археология җәмгыяте, бу ел Болгар хәрабәләренә үзенең әгъзаларын җибәреп, яңа тикшеренүләр үткәрәчәк. Бу экспедициягә әгъза буларак Газиз әфәнде дә чакырылган.

Кояш. — 1915. — №701. — 11 май.

Кызлар мәктәбендәге выставка

Мөхбирегезгә Фатиха ханым Аитова җитәкчелегендәге кызлар мәктәбе шәкертләре кулы белән эшләнгән әйберләр выставкасын күрергә туры килде.

Бу мәктәптә бер кыш эчендә эшләнгән әйберләр белән зур ике бүлмә вә аларның бөтен диварлары тулы. Бу нәрсәләргә караганда, мәктәптә хатын-кыз өчен иң зарур булган һәртөрле эчке вә тышкы күлмәкләрдән башлап җәйге вә яз, көз өчен булган тышкы күлмәкләр тегүгә кадәр тегү-кисү өйрәтелгән вә ир күлмәкләре тегү күрсәтелгән. Күптөрле чигешләргә, тегеп кую ысулы белән үрнәк вә бизәк ясауларга дикъкать иттерелгән бәйләү эшләренең бик күптөрлесе өйрәтелгән булуына галәмәт булып торган нәсәләр дә күп. Бәйләп

[1] Мадаполам — гадәттә эчке кием тегәргә китә торган ак киҗе-мамык тукыма.
[2] Подвалчы — читтән килгән сәүдәгәрләрнең малларын үз өенең идән астында саклау белән шөгыльләнгән кеше.

ясалган кечкенә генә капчыктан (ридикюль) башлап, бәйләгән шәлләргә кадәр күзгә чагылып торалар. Болар арасында дикъкатькә алырлыгы да бәйләнгән шәлләр булырга тиеш ки, бу нәрсәләр үзләренең арзанлы матдәдән булуларына карамастан, күзгә нәфис вә матур булып күренәләр.

Мәктәптәге кул эшләре В.С.Моисеева ханым вә ярдәмчесе Мәрьям Госманова туташ тарафыннан өйрәтелеп киленә икән. Эш өйрәтүдә тәдриж[3] ашыру ысулы тотылганлыгы бу мөгаллимәләрнең кул эшләрен өйрәтүне яхшы ук чибәр куйганлыкларын белдерәдер. Кул эшләрен яңа өйрәнә башлаган туташларның альбомнарында ямау салу, туры бөгү, садә генә бәйләүләр, җиңел генә чигеш үрнәкләренә очрала. Ахырында ефәк әйберләр тегү вә ефәк белән чигү, өске киемнәр кисү вә тегүләргә ирешелгәне күренә. Югарырак дәрәҗәдәге сыйныфлар эшләгән әйберләр эшләүчеләренең куллары эшне яхшы ук нәфис итәргә алышынган икәнен күрсәтә алалар. Болардан Хәдичә Сәгъдия эше — ефәк җирлеккә ефәк белән чигеп ясалган кыр тавыгы вә тегелгән костюм, Шәмсенәһәр Җаббарованың кул эше — чигеп ясалган диванлык мендәр, Фатима Галиеваның ефәк җирлеккә ефәк белән чигелгән гөлләре, Хәлимә Бикмөхәммәтова чиккән костюм, Рәбигә Сәгъдиева кулы белән чәчәкләр чигеп тегелгән кофта — аеруча дикъкать белән эшләнгән нәрсәләрдер. Бу мәктәп шәкертләре сугыш ихтыяҗына да ярдәм итәргә өлгергәннәр. Выставкага куелган әйберләрдән башка алар кулы белән мәҗрухлар ихтыяҗына 40 данә халат, 75 сорочка, 205 сөлге, 100 мендәр тышы, 30 пәлтә, 40 кальсон, 60 матрас, 100 күлмәк, 200 капчык, 100 яулык тегелеп бирелгән. Җәмгысе — 1000 данә әйбердер.

Кояш. — 1915. — №702. — 12 май.

Сабан туе

Сабан туеның 3 нче көне 29 нчы майда, җомга көн булачак. Бу көн Сабан туе программасына әлегә кадәр Русиядәге сабантуйларында булмаган 30 кеше бергә аркан тартышу, бүрәнә өстендә сугышу кебек яңа номерлар кертеләчәк булганлыктан, җомга көнгә Сабан туеның бик кызык булачагы көтеләдер.

Кояш. — 1915. — №714. — 27 май.

Сабан туеның соңгы көне

Иртәгә Сабан туеның актык көнедер. Әүвәлге ике көннәрендә Сабан туе кирәк тәртиплелеге вә кирәк программасының киңлеге илә халыкны үзенә бик күп җәлеп иткән һәм барган халыкны канәгать итеп, көткәннән артык ызбур алынган иде. Шуның өчен Сабан туеның бу актык көне дә бик күп халыкны җәлеп итәр, дип уйлана. Җәмгыяте хәйриябезнең хәлен игътибарга алган, бу елның чыгымлы ел икәнен яхшы аңлаган Казан халкы, әлбәттә, милли бәйрәмебезнең бу актыкка көнен дә күтәрешер, дип куәтле рәвештә өметләнәбез.

Бу көн Сабан туена губернатор Боярский җәнаплары да җәмгыять тарафыннан чакырылачак. Сабан туеның актык көненә җәмгыяте хәйрия бөтен Казан имамнарын чакырырга карар биргән. Сабан туе көндезге сәгать 2дә башланадыр.

Кояш. — 1915. — №715. — 28 май. ■

---

[3] Тәдриҗ — акрын-акрын алга бару, дәрәҗәләп үсү.

АЛЪЯПКЫЧ

(ТР Милли музее фондларыннан)

Алъяпкыч сүзе «алга ябу» сүзеннән алынгын. Татарларда ул эш киеме буларак кына түгел, ә бәйрәм киеме буларак та киелгән. Яшь киленнәр булачак ирләренә үзләре сугып чиккән «кияү алъяпкычы» бүләк иткән. Печән һәм урак вакытларында хатын-кызлар алъяпкычтан кала тагын кулларына җиңсәләр кигән. Аш бүлмәсендә дә ак яулык һәм алъяпкыч булган. Аны төрледән-төрле бизәкләр белән чигеп бизәгәннәр. Бигрәк тә тамбурлап чигү кулланышта булган.

Руфия Мөхетдинова *әзерләде.*

безнең мирас №5 май 2015

Мирасворд

Рөстәм Мингалим поэмасы

Рейхстагка беренче булып байрак кадаган татар егете

Теләк, омтылыш (иск.)

Купшы, кәяз

К.Тинчурин драмасы

АКШ штаты

Калашников автоматы (аббр.)

Кыргызстан каласы

Бу, шушы (иск.)

Ләм балыгы

Кыргыз эпосы

Озынча зур ястык

Төш вакыты, көн уртасы

Советлар Союзы Герое Асаф Габдрахманов туган шәһәр

... Либкнехт

Мөселман календаре буенча җиденче ай

«Елан ...» романы (Т.Әйди)

Сынау

Нота

Бер мачталы борынгы судно

«Гүзәлем ...» повесте (Ч.Айтматов)

Сафта тигез, салмак атлап йөрү ысулы

Г.Әпсәләмов романы

Җәфа, газап

Абыйның хатыны

... Гыйззәт

Аллага якын, изге кеше (иск.)

Борынгы шагыйрьләрдә еш очрый торган сүз

Конрад ... (немец тарихчысы)

Аңлатма, ачыклама (иск.)

Мәчет каланчасы

Ягулык

Җайдак утыргычы

1906 елда Казанда чыккан газета

Урта Азиядә сугару каналы

Рәис Габдулла төзеде.

4 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Султан уңга: турсык, Каюм, изү, ас, нечкә, нар, Маан, фәрд, Асия, нус, роль, сый, ирү, Филүс, Ябынчы, Риан, куык, Кант, «Ялав», лазем, Прага, инеч.

Өстән аска: нифак, Гафури, «Аклан», Рәсүл, таҗик, үртәвеч, Идриси, нукәр, ак, Емельян, юача, чулпы, Камская, нык, ар, әнис, Нур, «Зар», сынчы, Ге, Абай, ыктымат.

Хәйрулла паёгы

Нәби Дәүли
(1910-1989)



Хәйрулланы больницага китереп салдылар. Ул бик каты ыңгырашып ятты. Янына әледән-әле сестра килеп тора. Йә укол кадый, йә дару эчерә... Ә авыру һаман ыңгыраша: «Ах, үләм, үләм!» — ди.

Беркөн Хәйрулла үзен-үзе белештермәс хәлгә килде. Кинәт өстеннән юрганын ачып җибәрде дә торып утырды. Тирә-якны күзәтеп чыкты. Бер түшәмгә, бер кулларына күз төшерде.

— Ничә көн ятам мин монда? — дип сорады ул аннан палатадагылардан. Аңа үз-үзен белештермичә өч көн ятканлыгын әйттеләр. Шуннан соң ул, әкрен генә сузылып, тумбочка тартмасын ачты һәм кинәт гаҗәпләнгән сыман:

— Интересный икән монда тәртип! — дип куйды.

Шул арада сестра килеп җитте.

— Менә сиңа мә! — диде ул, Хәйрулланы күреп. — Кичә «үләм, үләм» дип яткан кеше бүген танымаслык булган, алыштырып киткәннәрмени... Димәк, кризис үткән. Болай булгач, тиздән савыгырсыз...

Хәйрулла, күзләрен йома төшеп, йөзен чытты:

— Савыгырсың... сездә...

Сестра гаҗәпләнде:

— Нигә алай дисез?

Хәйрулла тагын тумбочкага карап алды.

— Мин бит ничә көн ашамадым. Ә тумбочканы ачып карасам — бушлык. Валчык та юк, ичмасам!

— Димәк, аппетитыгыз да ачылган. Бу инде терелеп өйгә кайтырга бер генә адым калган дигән сүз...

— Шул шул, — диде Хәйрулла, — сезгә безне тизрәк озатырга гына кирәк. Ә калганы чёрт с ним!

— Туктагыз әле, — диде сестра,

тагы да гаҗәпләнә төшеп, — мин сезне аңлап җиткермим бугай…

Хәйрулла бу юлы да кашларын маңгай өстенә күтәрде:

— Мин, — диде ул сестрага, — өч көн ашамадым…

— Хәлегез шундый иде шул. Тиздән төшке аш бирелер, туйганчы ашарсыз…

— Анысын мин үзем дә беләм…

— Эш нәрсәдә соң?

Хәйрулла сүзен дәвам итте:

— Мин өч көн ашамадыммы? Өч көнлек паёгым калдымы?..

— Әллә сез узган көннәр өчен сорыйсызмы? — диде сестра, шаккатып.

— Нигә сорамаска, — диде Хәйрулла. — Миңа ул власть тарафыннан куелган паёк бит. Раз так, син аны давай миңа сполна!

Сестра Хәйруллага узган көннәр өчен аш бирелмәвен аңлатырга тырышып карады. Ләкин Хәйрулла үзенекен такылдый бирде:

— Миңа паёк бирелгәнме? Бирелгән. Мин аны ашарга тиешме? Тиеш!

Сестра аңа узган көннәр өчен паёкны бирергә мөмкин булмавын аңлатып маташкан арада, палатадагы бер авыру иптәш, үз тумбочкасын ачып, тулы ике пакет алды да Хәйрулла янына килде.

— Борчылмагыз, иптәш, — диде ул, — менә биредә бер дистә йомырка, бер кило сохари җыелган икән. Мин барыбер бүген чыгам. Ә сез — авыру кеше. Ашагыз, тазарыгыз…

Аннары бер сәер елмаю белән өстәде:

— Сезнекедәй авырудан самый файдалы дарулар инде болар.

Хәйрулланың йөзе ачылып китте. Ул бүләкләрне алып рәхмәт әйтте дә бер сохарины кетер-кетер кимерә башлады.

Аргы почмактан бер бала күтәрелде. Ул да бер төргәк алып килде.

— Менә, абый, өйдән пәрәмәч китергәннәр иде. Докторлар миңа әлегә ярамый, диделәр. Бәлки, сез ашарсыз.

Хәйрулла төргәкне ачып карамыйча гына тумбочкага тыгып куйды.

— Ә без аны врачлар күзеннән ераграк яшерик!

Шуннан соң ул, баягы пакетның берсен ачып, йомыркаларны тумбочка өстенә тездә дә санап чыкты, аннары бер стакан алып килде, аңа берьюлы өч йомырка сытты. Стаканны күз турысына күтәреп карады да:

— Кара, дүрт йомырка сытсаң, полный стакан була икән, ике йөз грамм, значит, — диде.

— Ә син тагын берәрне кәкет, — диде кемдер.

— Бу юлы өчесе дә җитеп торыр, мин бит әле авыру кеше, — диде Хәйрулла һәм, стаканга тоз салып, кашык сабы белән болгатты да голт-голт итеп эчеп җибәрде. Артыннан пәрәмәч капты.

— Берсәк тамак ялганды, малайлар, — диде ул, корсагын сыйпап.

Озак та үтмәде, төшке аш китерделәр. Хәйрулла ашарга ашыкмады. Башкалар алдына аш куелгач, үзенең порциясен аларныкы белән чагыштырып карады. Шунда гына аңа берьюлы ике порция бирелгәнлегенә ышанды.

— Что же, болай да ярый, — диде ул. — Ашаган саен икешәр порцы бирсәләр, бурычларын түлиләр, значит. Өч көннән соң без квита. Закон!

Ашап туйгач, Хәйрулла бөтен палатаны яңгыратып кикереп куйды.

— Кунактан чыктыкмыни! — диде аннары авызын сөртә-сөртә.

Көндезге аштан соң авырулар янына туган-тумачалары килә башлады.

Хәйрулланың хатыны палатага кереп тормады. Ул, тәрәзә каршына гына килеп, Хәйрулласын чакырып кул изәде. Хәйрулла, әтәч кебек очынып, тәрәзә төбенә кунаклады. Аннары форточкага башын тыкты да:

— Миңа ашарга китереп йөрмәгез. Биредә курорттагы кебек сыйлыйлар, — диде. Аннары тагы да катырак итеп:

— Карагыз аны, мин авырый дип, тавык суя күрмәгез, үз кулым белән суярмын, — диеп кычкырды.

(«Юмор һәм сатира» китабыннан, 1966) ■

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
елъязмасы / май

500 ел элек (1515)
Казан ханбикәсе Сөембикә (1515-1557) дөньяга килә.

210 ел элек (1805)
Таҗетдин Ялчыголның «Тәварихы Болгария» әсәре дөнья күрә.

150 ел элек (1865)
20 майда журналист, язучы-сатирик Шакир Мөхәммәдев (1865-1923) дөньяга килә.

110 ел элек (1905)
21 майда күренекле актриса Галия Кайбицкая (1905-1993) дөньяга килә.

95 ел элек (1920)
27 майда Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты һәм Халык Комиссарлары Советы Автономияле Татарстан Совет Социалистик Республикасын төзү турында декрет кабул итә.

85 ел элек (1930)
Мәскәүдә татар телендә «Ударниклар» исемле журнал чыга башлый. Журналның җаваплы редакторы — Муса Җәлил.

ТАПП (ул вакыттагы татар язучылары оешмасы) шагыйрь Һади Такташны ике айга Донбасска иҗади командировкага җибәрә.

70 ел элек (1945)
СССР Халык Комиссарлары Советы янындагы Югары мәктәп эшләре комитеты һәм Сәнгать эшләре комитеты Казанда консерватория ачарга карар чыгара.

50 ел элек (1965)
«Совет әдәбияты» журналында Шәйхи Маннурның «Муса» романы басыла башлый, Аяз Гыйләҗевнең «Үги ана яфраклары» хикәясе дөнья күрә.

25 ел элек (1990)
Язучы Фәүзия Бәйрәмова Германиядә «Төрек-ислам берлеге» җәмгыятенең III корылтаенда катнаша. Моннан тыш, ул әлеге җәмгыятьнең аерым шәһәрләрдә эшләүче бүлекчәләрендә татарлар турында лекцияләр укый, Хайдельберг университеты укытучылары һәм студентлары белән очраша.

ШАМИЛ НИГЪМӘТУЛЛИН

«Август узды».
Киндер, майлы буяу

Шамил Габдрахман улы Нигъмәтуллин 1951 елның 4 гыйнварында Буа районының Күл Черкене авылында дөньяга килә. Казан сәнгать училищесын (1975), Суриков исемендәге Мәскәү сәнгать институтын, Ю.Королёв җитәкчелегендәге монументаль-декоратив нәкышь остаханәсен (1981) тәмамлый. Ул — Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы (1990), Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1999). Аның әсәрләре Россиянең һәм чит илләрнең шәхси вә дәүләти тупланмаларында саклана.

Шамил Нигъмәтуллин 2004 елның 1 февралендә Казанда вафат була.

«Иртәгә бәйрәм».
Киндер, майлы буяу

www.beznenmiras.ru

БЕЗ – МИРАСЛЫ ХАЛЫК!

«БЕЗНЕҢ МИРАС» БЕЛӘН БЕРГӘ БУЛЫГЫЗ!

Икенче ярты еллыкка почтада язылу бәясе – 498 сум.
Редакциядә язылу бәясе – 380 сум.

4 612750 670172

«Безнең мирас» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» (Бауман урамы, 29/11) кибетеннән, Г.Тукай музеендагы киосктан (Г.Тукай урамы, 74) сатып алырга мөмкин.